ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№03 (386)
МАРТ 2024

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

МӘХӘББӘТКӘ ЧИКЛӘР ЮК

№03 (386)
МАРТ 2024

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН

ЭЧКЕРСЕЗ БҮЛӘК

Җир йөзендә тормыш шулай корылган: яз гасырлар дәвамында тереклек ияләренә өмет алып килә. Яңаруга, савыгуга, бәхеткә, мәхәббәткә... Быел да яз үз кыйбласына тугры – ихластан, берни таләп итми, җавап көтми бирә ул безгә бу өметне.

Безнең эш – кем, нинди, ничә яшьтә булуга, дәрәҗә, байлык һәм башка шундый билгеләргә карамый, барыбызга да бирелә торган бу олуг табигать бүләген кабул итеп алу, аның кадерен белү. Ләкин бүгенге ыгы-зыгылы тормышта язны кадерләү түгел, күрми дә калабыз кебек. Туннарны ераграк алып куярга, өс-башны, аяк киемен алмаштырып өлгерсәк ярый – ә аннан тагын бетмәс-төкәнмәс ашыгыч эшләргә кереп чумабыз...

Бу очракта ни дияргә була? Ашкынулы XXI гасыр, игътибарыбызны әллә кайларга җәлеп итеп, бер-бер артлы килгән ел фасылларын күреп өлгерергә дә ирек бирми. Ләкин замана ыгы-зыгысыннан арынып, күз кырые белән генә булса да язгы табигатьне, аның ямен күреп аласыз икән, туктагыз, иркенләп сулыш алыгыз, бу мизгелне истә калдырырга тырышыгыз, әлеге кәеф сезгә җәйгә кадәр җитәчәк: март умырзаяларының нәфис чәчәкләреннән алып май сиреньнәренең җете төсләренә кадәр. Тирә-якны яшеллеккә, гөлгә күмеп, күңелләребезгә шифа, өмет өстәп, ямьле яз килсен!

Сезнең язгы редакциягез

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Оксана Бирюкова, Гомәр Даутов,
Илдус Заһидуллин, Айдар Шәйхин, Луиза Янсуар
Фотографлар: Александр Ефремов, Алсу Шакирова,
Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Кытай белән бизнес алып бару эксперты
Аида Демьянова гаиләсе.
Фото Аида Демьянова архивыннан

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: А–0370
Басарга кул куелды: 19.03.2024
Чыгу көне: 25.03.2024

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2024 елның яртыеллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1212 сум 00 тиен китереп бирешлә,
1175 сум 40 тиен соратып алганда.
2024 елга ТР буенча язылу бәясе:
2423 сум 92 тиен китереп бирешлә,
2350 сум 66 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 103 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик ТАТАРСТАНДА

ТАТАР РАЗВЕДЧИГЫ

АКШта аның гөрләп торган бизнесы, Нью-Йоркта фатиры
һәм чибәр хатыны була… Гаҗәеп җиңел, аралашучан, зыялы
шәхес Америкада «үз» кеше санала, дуслары арасында дәүләт
департаменты, финанс министрлыгы, башка ведомстволар
хезмәткәрләре була. Мех кием тегү фирмасының тыйнак
кына хуҗасы безнең АКШтагы резидентураның җитәкчесе
дигән уй беркемнең дә башына килә алмый. Хатыны Хелен
да АКШ компартиясе лидеры туганының кызы була. Развед-
чик Исхак Әхмәров* аша Советлар Союзы АКШның сугыш
елларындагы, Тәһран конференциясе алдыннан булган
планнары, атом бомбасы ясау буенча үтә яшерен проектын
гамәлгә ашыруы турында кыйммәтле мәгълүматлар ала.
Ярлы крестьян гаиләсендә туып-үскән, кайчандыр Казанда
Мәгариф халык комиссариатында эшләгән тыйнак кына та-
тар егете профессиональ разведчикка әйләнә. Ул Рихард Зор-
ге, Ким Филби, Рудольф Абель белән бер рәттә тора. Дөрес,
әлеге атаклы разведчиклардан аермалы буларак, чынлыкта
аның кем булуы ачылмый кала.

© «Татарстан» журналы

*Оператив псевдонимы Юнг

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Язны көтәбез
Су басулар безгә нәрсә белән яный

8. Кайтаваз
Йолдыз авылы кышны ничек чыккан

10. Партнерлык (ислам) финанслары кырында,
яисә Кешбэк хәләл була аламы

22. Игелек кылу вакыты
Шәфкать һәм юмартлык аша ничек яхшылык эшләргә

игелекле эшләр

24. Киләчәк Уеннары
Дрон узышларында ничек артта калмаска

30. Виртуаль велоузыш серләре
Түбәннән татар кызы ни өчен испан командасы данын яклый

40. Һәр нәрсәдә гармония күрү
Хатын-кыз бизнесы ирләрнекеннән ничек аерыла

52. Гамьле әңгәмә
Җитәкче булу нәрсә ул

56. Фидакарьләр
Сәйдә Аппакова белән әңгәмә

мәңгелек кыйммәтләр

62. Тарих
Батыр йөрәкле Чистай кызы

66. Онытылмас исемнәр
Кем ул Камил Якуб

70. Китап киштәсе
Яшәү мәгънәсен белсәк, үзгәрер идекме?

80. Татар авыллары
Торнаязга торналар кайчан килә

88. Ай кәефе
Рәссамнар мәктәптә кунакта

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Фото: zvezdaweekly.ru

Акыллы гамәлләр



21.02

Владимир Путин, РФ Президенты, – Казанда, Киләчәк Уеннары ачылышында:

– Без иң зур, кызыклы халыкара спорт ярышларының югары дәрәҗәдә оештырылуы белән һәрчак горурланабыз, һәм аларның күбесе нәкъ менә монда – Казанда уздырылды. Казан каласы, Татарстанның үзе кебек үк, Киләчәк Уеннарының эчтәлегенә дә, рухына да тулысынча туры килә. Үзенчәлекле, күпмилләтле, төрле халыкларның мәдәниятенә бай кала ата-бабалар мирасын кадерләп саклый, һәм шул ук вакытта яңалыкка һәрвакыт ачык, тәвәккәлләп, иң катлаулы, өр-яңа проектларга алына һәм аларны югары дәрәҗәдә башкарып чыга.

Игелекле эшләр

21.02

Александр Лукашенко, Беларусь Республикасы Президенты, – Казанда, ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашу вакытында:

– Бәлки, тышкы вазгыятьнең безне бер-беребезгә якынаерга мәҗбүр итүе яхшырактыр да. Без тигез урында бәхәсләшүдән туктадык, дусларыбызның алай ук күп булмавын (бәлки әле чын дуслар бөтенләй юктыр да) һәм үз бәхетебезне үзебезгә төзергә кирәклеген аңладык.

Мәңгелек кыйммәтләр

21.02

Садыйр Жапаров, Кыргызстан Республикасы Президенты, – Казан Кремлендә, ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашу вакытында:

– Кыргызстан Республикасы белән Татарстан арасында хезмәттәшлек мәсьәләләрен тикшерү өчен шәп мөмкинлекләребез бар. Безне төрки тамырлар, уртак традиция һәм әхлакый кыйммәтләр, мәдәният һәм тел ягыннан охшашлык бәйли. Шулар бәрабәренә Кыргызстан белән Татарстан арасында элемтәләр көчәя бара. Без әлеге үзара файдалы хезмәттәшлекне югары бәялибез.

Фото: РФ Президентының рәсми сайты, tatarstan.ru, Кыргызстан Президентының матбугат хезмәте

игелекле эшләр

акыллы

мәңгелек кыйммәтләр

гамәлләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Язгы ташуларны Татарстан **ничек** каршы ала

Йолдыз авылында **нинди** үзгәрешләр булган

Кешбэк **ничек** хәләл була ала

ЯЗГЫ ТАШУ ЯКЫНЛАША. АГЫП КИТМӘБЕЗМЕ?

Евгения Чеснокова

Тулысынча су астында калган мәйданда җәяүлеләр кичүен аңлаткан юл билгесе генә калкып тора. Социаль челтәрләрдә шундый фотолар йөри башлады. Фото астындагы язулар да кәефне күтәрерлек түгел: быел язын Казанны шундый хәл көтәргә бик мөмкин. Кеше буеннан ике-өч тапкыр биегрәк кар көртләренә карагач, чыннан да борчыла башлыйсың: болар барысы да эри башлагач, нәрсә булыр икән?

Соңгы тапкыр Казанны моннан бер гасыр диярлек элек - 1926 елда шулай су баскан. Георгий урамы буйлап көймәдә йөзүче шәһәр халкының фотосурәтләре сакланган. Шул чактагы хатирәләрдән күренгәнчә, 1926 елның маенда Казансу шулкадәр ташып ярларыннан чыккан ки, хәтта шәһәрдә дамбалар җимерелгән, трамвайлар хәрәкәте туктатылган. 51 урам су астында калган. Су якынча 15 метрга күтәрелгән. 2,5 меңнән артыграк йортка зыян килгән, ун меңләп кеше фатирыннан күчерелгән...

Фото: pastvu.com, zpravda.ru, 16.mchs.gov.ru, pxhere.com

Кызыклы факт: Казанның меңьеллыгына Георгий (ул чакта Свердлов) урамының исемен Петербург урамына үзгәртеп яңартканда, аның җәяүлеләр йөри торган өлешенең үзәгенә карасу төстәге таш түшәгәннәр – Питер проектчылары фикеренчә, бу Нева елгасын символлаштырырга тиеш булган...

ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛ КӨТЕЛМИ...

– 1956 елда Куйбышев сусаклагычы төзелгәч, судан саклау өчен, Казанны дамбалар белән уратып алганнар, – дип сөйли КФУның Икътисад, идарә һәм финанслар институтындагы табигатьне төзекләндерү һәм судан файдалану кафедрасы мөдире, профессор Нәфисә Минһаҗева. – Әлеге дамбалар шәһәрне су басудан әле бүген дә ышанычлы саклый.

Шуңа күрә быел башкала үзәгендә көймәдә йөрергә туры килмәячәк. Мөгаен. Әмма Казан – бөтен Татарстан түгел әле ул. «Республикадагы быелгы вазгыять чыннан да гадәттәгечә түгел», – ди ТР Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе Гидрометеоүзәге башлыгы Феликс Гоголь. Һәм мисалга мондый саннар китерә: декабрьдә республикада еллык уртача күрсәткечләрнең 153 процентына тәңгәл явым-төшем теркәлгән. Гыйнварда исә әлеге күрсәткеч – 206 процентка, февральнең беренче декадасында исә 286 процентка тәңгәл булган. Һәм әле явым-төшем тагын көтелә, кар тагын явачак.

Моның өстенә, РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе мәгълүматлары буенча, республикада елгалар челтәренең тыгызлыгы Россиядә иң югарылардан: Татарстан территориясенең 6,4 проценты су белән капланган. Елгаларның саны гына да өч меңнән арта, буа, күл һәм сусаклагычлар исә бихисап.

– Ихтимал, язгы ташу шактый мәшәкатьле булыр, – ди Феликс Гоголь һәм төгәллек кертә: күп нәрсә марттагы һава торышына бәйле булачак. Әлеге һава торышының нинди булачагын исә метеорологлар хәзер үк әйтә алмый. Ташуның рәсми фаразын март уртасында гына вәгъдә итәләр. Ә бит язның беренче аеның башы әле тагын карлы сюрпризлар белән «сөендерергә» мөмкин.

– Чыннан да, күп нәрсә язның ничек килүенә бәйле булачак, – ди Нәфисә Минһаҗева. – Әгәр ул әкренләп һәм озак килсә, әйтик, төннәрен суытып, көндезләрен җылытып һәм шулай берничә тапкыр кабатланып, кар катламы калын булгач, су басулар барыбер бераз булачак, әмма кайбер җирләрдә генә. Ә инде яз тиз һәм иртә килсә, ташулар да күбрәк көтелә. Әмма әле тагын туфракның туңу дәрәҗәсен дә исәпкә алырга кирәк. Минем күзәтүләремчә, кар туңмаган җиргә яуды. Димәк, ул яз көне дымны күбрәк сеңдерәчәк. Гаять зур кар көртләре үзләре дә, җылыткан саен катыланып, тыгызланып утырачак.

Һәм әле тагын шуны да истән чыгармау мөһим: былтыр кышка кергәндә, безнең елгалар бик саеккан иде, чөнки Куйбышев сусаклагычында су кытлыгы бик көчле булды.

ОКЕАНДАГЫ АЙСБЕРГ ШИКЕЛЛЕ...

Республиканың күп районнарында «зур ташу» турында ишетеп кенә белмиләр. Яшел Үзәндә, мәсәлән, 1979 елда Иделдәге куәтле язгы ташуны күпләр хәтерли (ул елны кыш бик суык килеп, җир бик каты туңган була). Иделдәге боз апрель азагына кадәр эрергә уйламый да. Аннары исә кисәк җылыта башлый. Берничә көн эчендә минуслы температурадан кинәт кенә 22 градуска кадәр җылыта. Һәм боз кузгала.

«Бозлар айсберг кебек иде, – дип сөйли бер кеше җирле газета хәбәрчесенә. – Су артканнан-арта бара, юлында очраган бөтен нәрсәне ватып-җимереп, алга ыргыла». Боз, пычак төсле, имән-карамаларны төбеннән кисеп ташлый, дача йортларын җимерә, көймәләр бәйләнгән чылбырларны өзә. Елгада моңарчы күрелмәгән хәл: йортлар, агачлар ага, ә бераз астарак мародерлар мал җыя – агып килгән корылмаларны тотып алып, моторлы көймәләрдә башка җиргә күчереп куярга ашыга. Кайбер бакчачылар шул рәвешле бөтен мөлкәтләреннән колак кага.

Шундый имеш-мимеш тә йөри: янәсе, ул чакта Чебоксар ГЭСы ашыгыч рәвештә балласттан котылган. Әлеге вакыйганың шаһитләре әйтүенчә, су югарыдан бик куәтле килә, Иделдә исә Васильево каршында бозлар барысы бергә тыгыла һәм агым аска таба китә алмый.

Авиация ярдәмгә килә. «Мирный микрорайоны янәшәсендә вакытлыча мәйданчык

Боз киткәндә ел саен елгаларда шартлату эшләре башкарыла.

көйләнә. Шуннан бомба төялгән вертолетлар елга ягына оча», – дип яза «Зеленодольская правда» газетасы. Шул вакытта гына бозлардан хасил булган буа ерыла һәм су кими башлый.

ТУГАЙНЫ САКЛАУ МӨҺИМ!

Нәфисә Минһаҗева әйтүенчә, елга тугаенда суның табигый таралуына берәр нәрсә комачауласа, ярларны су басу куркынычы зуррак:

– Тугайлары тарайтылган, юкка чыгарылган, корылмалар төзелгән елга һәм кушылдыкларда, әлбәттә, проблемалар булачак. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының күп тапкыр кисәткәне бар: тугай территорияләрендә биналар төзергә ярамый. Әмма матур урынга кызыгабыз: бөтен кешенең су буенда яшисе килә! Әгәр бер хуҗа үз кишәрлеген туфрак ташытып күтәрттергән икән, димәк, аның күршеләрен су басачак. Йә су юлга агып чыгачак. Кайвакыт шундый хәл дә күзәтелә: бөтен әйләнә-тирәгә җәелгән су диңгезе уртасында бер хуҗаның биегәйтелгән кишәрлеге генә утраудай торып кала.

2020 елда мин Лаеш районы Усад бистәсендә елганың асфальт юл буйлап акканын күзәттем. Кар эрегәч, язгы ташу сулары гаять зур тизлектә аска таба ага башлады. Бәхеткә, шунда яшәүчеләр, тиз арада канау казып, әлеге агымны күлгә борып җибәрде. Шулай эшләмәгән очракта ул асфальтны тулысынча юып китәргә мөмкин иде.

Быел Казанда шундый хәл Киндерле елгасы буенда килеп чыгарга мөмкин, чөнки аның тугаенда берничә елдан бирле актив төзелеш бара. Димәк, су ташу өчен урын тарая. Шулай ук Нокса елгасыннан да сюрпризлар көтәргә мөмкин.

БАР ДА ПЛАН БУЕНЧА БАРАМЫ?

РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсендә безне: «Татарстан Республикасы территориясендә 2024 елдагы язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу хәвефен һәм алар китергән зыянны киметү буенча превентив чаралар комплексы план нигезендә, билгеләнгән вакытта башкарыла», – дип ышандырдылар.

Сүз уңаеннан, безнең белән аралашканда, коткаручылар тагын бер зур ташуны искә төшерде. 2012 елда кинәт җылыту һәм күп итеп яңгыр яву аркасында, Татарстандагы кече елгаларда вазгыять көтелгән сценарий буенча китми. Республиканың егерме районы территориясенә куркыныч яный, язгы сулар Казан кырыйларына да килеп җитә. Ул чакта боз киткәндә газүткәргечкә зыян килеп, ике меңнән артык кеше газсыз кала. Ун күпер һәм егерме чакрымнан артыграк юл сафтан чыга. Бигрәк тә Әлмәткә зур зыян килә – анда 202 йорт су басу зонасына эләгә.

Әмма, коткаручылар әйтүенчә, җирле һәм республика хакимиятләре һәм коткару хезмәтләре стихиянең көйсезләнүләренә әзер. «Ташу» оператив планы буенча ел саен районнардагы сулыкларның төпләрен һәм тамакларын чистарталар, дамба, күпер һәм плотиналарны тикшерәләр, инженерлык саклау объектлары әзерлиләр, елга үзәннәрен чистарту һәм турайту белән шөгыльләнәләр.

СИРЕНА ТАВЫШЫН ИШЕТМИ КАЛМА!

Татарстанның Кайбыч районы сайтында төп яңалык урынында көн саен оператив һава торышы куела. Һәр яз саен су басу янаган район өчен һава торышын берничә көн алдан белеп тору – бик кирәкле гамәл. Гадәттә биредә яз саен Гөбенә, Берлә һәм Ырым елгалары «шаяра».

– Бездә һәр ел саен язгы ташудан зыян күрә торган берничә торак пункт бар, – ди район башкарма комитеты җитәкчесе Алексей Макаров. – Шуңа без инде хәзер бик тәҗрибәле, төрле көтелмәгән хәлләргә һәрвакыт алдан ук әзер.

Барлык бистәләрдән дә карны читкә ташып бетерү мөмкин түгел, бу авыл районына бик кыйбатка төшә. Кар көртләре кеше буеннан өч тапкырга биегрәк икән – зур су киләсе көн кебек ачык инде. Димәк, моңа әзер тору бик мөһим. Авылларда ашыгыч хәбәр бирү системасы бар, куркыныч янаганда, сирена бик тиз арада кабына. Йорт саен кереп, кешеләрне кисәтәләр: мал-туарны югарырак урындагы корылмаларга, җиһазларны, кыйммәтле әйберләрне, баздагы ашамлыкларны икенче катка йә чормага

күчерергә кирәклеген искәртәләр. Әлбәттә, кешеләрнең үзләренә дә берникадәр вакытка күчеп тору бик яхшы булыр иде, әмма авыл халкы моңа ризалашмый. Ташу иң котырган чорда су баскан җирләрдәге халыкны күчереп тору өчен биналар әзерләнгән. Дөрес, гадәттә күпчелек барыбер туганнарына гына китеп торырга тырыша.

Ә инде боз киткәндә өемнәрдән бөкеләр тыгылмасын өчен, ди Алексей Макаров, ел саен район елгалардагы шартлату эшләренә алдан ук гариза биреп куя.

ЯХШЫГА ӨМЕТЛӘНӘБЕЗ, БАРЫСЫНА ДА ӘЗЕР ТОРАБЫЗ

Сүз уңаеннан, Кайбыч авыллары турында. Мәсәлән, кечкенә генә Берлә елгасы ярындагы Борындык авылы Татарстан коткаручыларына яхшы таныш.

РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе сайтында 2018 елгы вакыйгаларда катнашучыларның хатирәләрен табарга мөмкин. Ул чакта тыйнак Берлә бер метрдан калынрак боз өемнәре арасында кысылган куәтле су агымына әйләнә. Боз өемнәре тыгылганга, су үзән буйлап ага алмый, шуңа ярларыннан ташый һәм торак йортларга, ишегалларына җәелә. 2018 елның 10 апрелендә елга, ярларыннан чыгып, Борындыкта өч торак йортны һәм 27 йорт яны хуҗалыгын су астында калдыра. Өйләрдә су идәнгә кадәр күтәрелә. Җирле хакимият коткаручылар белән бергә хуҗаларга җиһазларны икенче катка күтәрергә, идән астыннан бәрәңгене күчерергә һәм терлекләрне күршеләргә кертергә булыша.

«Ишегалдында көймәдә йөздек, – диелгән берәүнең истәлекләрендә. – Балаларны туганнарга җибәрдек, үзебез печәнлектә утырдык. Тавыкларны да үзебез белән алып мендек. Сыерлар салда яшәде. Телевизор белән суыткычны коткарырга өлгермәдек. Өйне дә үзгәртеп корырга туры килде. Ярый әле, безгә ризык һәм су китереп тордылар».

Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре, әлбәттә инде, хәлне контрольдә тота һәм халыкны бәла-казада ялгыз калдырмый. Әмма идарәнең матбугат хезмәте биргән киңәшләрдә мондыйлары да бар: язгы ташу куркынычы янаган районнарда яшәүчеләр, аннан килгән зыянны киметү өчен, үз территорияләрен алдан ук кардан чистартырга, су китәр өчен канаулар казып куярга тиеш. Бәләкәй генә дамба ясап кую да әйбәт.

Көнкүреш кирәк-ярагын, техниканы һәм мал-туарны урнаштыру өчен, икенче катта, чормада яки хәтта өй түбәсендә яки якындагы тау башында су басу куркынычы янамаган урыннар әзерләп кую зарур. Базлардан азык-төлекне алдан ук чыгарып, эчәргә яраклы су запасы туплау кую да мәслихәт. Документларны кайгырту да мөһим: аларны полиэтилен пакетка тыгып, ышанычлы урынга яшерү хәерле – куркыныч янаганда, үзеңнең киемең астына кыстырып куярга була. Эрегән кар сулары өйгә якынлашкач, газ, су һәм электрны өзәргә, мичтәге утны сүндерергә кирәк.

Хакимият структураларына килгәндә исә, муниципаль җитәкчеләр, беренчедән, кече елга үзәннәрен, бигрәк тә басмалар турысында һәм тарайган җирләрдә, даими һәм вакытында чистарттырырга тиеш. Халыкка хәбәр бирү системасының эшләвен тикшерү мәҗбүри. Халыкны су баскан урыннардан эвакуацияләү тәртибе белән таныштыру, аларга үзләренә вакытлыча күченеп тору һәм терлекләрен күчерү урыннарын күрсәтү кирәк. Превентив чаралар арасында мондыйлары да бар: хосусый сектордагы һәр йортка кереп, анда яшәүчеләр исемлеген төгәлләштерү, бигрәк тә авыру, инвалид һәм өлкәннәргә игътибар бирү зарур. Билгеле инде, район медиклары да тулы әзерлектә торырга тиеш.

Барлык күрелгән чаралар да файдага булыр, республикада язгы ташу тыныч үтәр, дип өметләнәсе килә. Тик шулай да...

– Республика тормышына һәм икътисадына нык зыян салган су ташуларның соңгы берничә дистә елда булганы юк, – дип сөйли ТР Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе Гидрометеоүзәге башлыгы Феликс Гоголь. – Әмма быелгы кар катламының калынлыгы, шулай ук әле кышның дәвам итүен һәм тагын кар яву ихтималын исәпкә алганда, болар барысы да көтелмәгән хәлләр китереп чыгарырга бик мөмкин. Шунлыктан барыбызга да әзер булып тору зарур.

ЙОЛДЫЗ АВЫЛЫ: «ХӘЛЛӘР ӘЙБӘТ ТҮГЕЛ»

Руфия Фазылова

Ул фаҗигагә инде бер ел була. 2023 елның 7 май көнендә ике сәгать эчендә Курган өлкәсендәге Йолдыз авылының өчтән ике өлеше янып көлгә әйләнде. Нәтиҗәдә, 228 йорт юкка чыкты, аннан бигрәк җиде кешенең гомере өзелде...

Июль уртасында «Татарстан» журналы зур тетрәнүдән башы әйләнгән халык белән аралашып кайтты. Аннан соң да араны өзмәдек – Курган өлкәсендә яшәүче милләттәшләребез белән аралашып тордык. Әле кыш уртасында да вагонда яшәүче гаиләләр шактый иде.

«АХЫРЗАМАН КЕБЕК БУЛДЫ»

Йолдызга баргач та, иң беренче Рәзилә Әминова белән танышкан идек. Йолдыз урта мәктәбендә җыештыручы булып эшләүче бу ачык ханым безне үзенең йортына алып барды. Гомер буе күп итеп мал асраган Рәзилә Әминова, күңел юанычы өчен дип, җәен утыз баш каз бәбкәсе алган иде.

– Каралтыда алты үгезем бар иде, янгын безгә таба килә башлагач аларны чыгарып җибәрдем, – дип сөйләде ул чакта Рәзилә апа. – Берничә көн болында йөргәннән соң, аларны сатып җибәрдек. Ә менә этебез янып үлде. Этне дә бәйдән ычкындырган идем, күрәсең, төтеннән куркып, кире оясына кергән. Монда бит ахырзаман кебек булды... Янгын авыл башыннан, мәдәният йорты ягыннан килде. Башта безгә кадәр җитәр дип уйламадык та. Әле мин иртә белән малларны ашаттым. Аннары күршеләр кычкырды: кешеләргә өйләреннән чыгарга, күл буена барырга кушканнар. Тиз генә җыендык та чыктык. Ул да түгел, урамда төтен исенә тончыга башладык. Янгын турында ишетеп, улым Газиз шалтыратты. «Хәзер кайтып җитәм, әйберләрне булса да чыгарырмын», – диде. «Зинһар, йөрмә, улым», – дип, телефоннан кат-кат әйттем үзенә. Барыбер кайтты, ул вакытта өйне ут камап алган булган инде.

Көчле янгын басылганнан соң һәркем өенә ашыкты. Без дә улым белән кайттык, монда әле бөтен җирдә утлы кисәүләр пыскый иде. Авыз-борыннарны юеш чүпрәк белән каплап

Фотолар Гөлсимә Байтираковадан алынды, tatar-congress.org

йөрдек. Ике теплицадан кала, бөтен нәрсә янып бетте. Иң аянычы – гаилә альбомнарын бәрәңге базына аткан идем, мәрхүм ирем белән төшкән сурәтләр, балаларның фотолары – алар да янган. Ут базга да төшкән. Әнә шулай мал белән бергә бөтен истәлекләр дә көлгә әйләнде...

САЛКЫН КЫШ...

Көз башында Рәзилә апа, йортының каркасы әзер булгач, сөенеп фотолар җибәрде: «Төзүчеләр кышка кадәр йортны эшләп бетерергә вәгъдә бирде», – дип язды ул. Тик аның хыялы тормышка ашмады – декабрьдә дә мунчада яши иде әле. Ниһаять, гыйнвар башында яңа йортына күченергә насыйп булды аңа. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, төзүчеләр йортка җылылык системасын дөрес ялгамаган, батареялар эшләми булып чыкты.

– Йортым 24 гыйнварда гына җылынды, аңа кадәр электр мичләре куярга туры килде, – ди Рәзилә Әминова. – Кызым кредитка көнкүреш техникасы алып бирде. Өй эче эшләнеп бетмәгән булса да, бүген шуңа шөкер итеп яшим. Калганы акрынлап җайланыр дип, үземне тынычландырам. Аптыраудан, гаҗизлектән утырып елаган көннәрем бик күп булды...

Рәзилә Әминова янган йорты өчен дәүләттән 2 миллион 400 мең сумлык сертификат алган. Июнь аенда ул, Курган өлкәсенең дәүләт төзелеш оешмасы белән килешү төзеп, акчаның бер өлешен аларга күчерү турындагы документларга кул куйган. Аңлашылганча, өч ай эчендә салынасы йорт алты айда да сафта булмый әле.

Йолдыздагы янган йортлар урынына яңаларын төзергә Курган өлкәсенең «Аспект» белән «Табия» исемле төзелеш оешмалары алына. Тәртибе менә ничек: янгыннан соң авылга махсус комиссия килә. Алар көлгә әйләнгән йортның квадратын, анда ничә кеше теркәлгән булуын карый. Нәтиҗәдә, Курган өлкәсе администрациясе янган гаиләләргә 1 миллионнан 4 миллион сумга кадәр сертификатлар бирә. Аңа Курган өлкәсенең теләсә кайсы шәһәреннән торак сатып алырга яки янган нигезенә йорт салырга мөмкин. Сертификат акчасы кулга бирелми, шуның өчен дә кешеләр өлкәнең төзелеш оешмалары белән килешү төзергә мәҗбүр була. Халыкка барлыгы 178 шундый сертификат тапшырыла. Шулар арасында 60лап гаилә, авылда йорт салудан баш тартып, шәһәрдән торак сатып ала.

– Мин дә башта Йолдыздан 40 чакрым ераклыктагы Шадринск шәһәреннән өч бүлмәле фатир алырга уйлаган идем, – ди Рәзилә апа. – Аннан исә туган авылдан китмәскә булдым. Беренчедән, бездәге янгыннан соң шәһәрләрдә фатир бәяләре нык артты. Икенчедән, җирсез яши алмам, дип уйладым. Авылда калган гаиләләргә Курган өлкәсе администрациясе сертификаттан тыш тагын 700 мең сум акча бирә дигәч, йорт



салырга уйладым. Үкенмим үзе, туган авыл бит. Тик менә төзүчеләрнең вәгъдәләрен үтәмәүләре генә үзәккә үтте. Ноябрьгә кадәр вагонда яшәдем, су катты, хәтта матрас бозлана иде. Аннары мунчага күчендем. Әле ярый бала-чага юк, әнине шәһәргә алып киттеләр. Менә шулай тилмердем.

«ХӘЛЛӘР ӘЙБӘТ ТҮГЕЛ!»

Янгын булганнан соң авылда махсус комиссия төзелә. Аның максаты – беренче чиратта гади халыкка документларын яңартырга булышу, башка мәсьәләләрне хәл итү. Менә шушы комиссиянең җитәкчесе итеп Йолдыз урта мәктәбенең укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гөлсимә Байтирәкова билгеләнә. Йолдыз мәктәбендә 26 ел директор да булып эшләгән әлеге ханымның авылда абруе зур. Йолдызга баргач без моңа тәгаен инандык. Шөкер, Гөлсимә ханымның йорты янмаган.

– Йолдыз авылына җибәрелгән төзелеш материалларын тигезләп бүлергә тырыштык, һәр кадакны санап утырдык, – диде ул чагында Гөлсимә Байтирәкова. – Нигездә ярдәм Татарстаннан килде: кием-салым, урын-җирләр, савыт-саба... Суыткычлар, башка көнкүреш техникасын да гадел итеп бүлдек.

Йолдызның бүгенгесе белән кызыксынып, Гөлсимә ханымның телефонын җыйдым. Туры сүзле җитәкче авыр итеп уфтанды:

– И сеңлем, хәлләр әйбәт түгел. Төзүчеләр бер срокка да сыешмады. Әле дә кеше йортында, күрше авылларда яшәүчеләр байтак. Шулар өчен борчылып йөрәк бетә бугай. Авылга көн саен диярлек Курган өлкәсенең прокуратура вәкилләре килә. Хәтта узган атнада РФнең Генераль прокуроры урынбасары Сергей Зайцев та килде. Төзүче оешмаларга 15 нче мартка кадәр эшләрен төгәлләргә кушылды. Ләкин ике атна эчендә ничек дистәләгән йортны җиткерсеннәр.

– Йортлар ни дәрәҗәдә эшләнгән соң? – дим.

– Төрлесе бар. Бер йортка газын, суын кертергә кирәк, икенчесенең идәне, түбәсе юк, тәрәзә яңаклары куелмаган. Күп инде анда...

Гөлсимә Байтирәкованың абыйсы, дөресрәге, әнисенең энесе Вәлиша абый да Курган өлкәсенең «Аспект» төзелеш оешмасы белән килешү төзегән. Җитмеш дүрт яшендәге бабай эшләнеп бетмәгән йортына февраль башында күченгән. Тик әле дә өендә суы да, идән, түшәме дә юк икән.

– Абый кышны миндә чыкты, – диде Гөлсимә апа. – Җәйгә кадәр яшә, аннан күченерсең, дип әйтеп карадым. Юк, үз өендә яшисе килә. Эшләнеп бетсә бер хәл, олы кешегә бәдрәфкә урамга йөрергә дә авыр, җитмәсә, икенче төркем инвалид. Абыйга йорт салу өчен 2 миллион 680 мең сум акча бирелде. Шуңа 33 квадратлы йорт салдылар, янәсе, үзенә генә җитә. Шуны да кеше рәтенә китермәделәр. Ул акчага конфет ясап була иде!

Тагын шунысы гаҗәп: 2 миллион 700 мең сумлык сертификатка кемгәдер зур йорт, кемгәдер кечкенә йорт салганнар. Аннан бигрәк: төзелеш оешмасы авылга блок, башка төзелеш материалларын күпләп китереп аударган да, алар шунда хуҗасыз булып яткан. Елгыррак кешеләр берәм-берәм ул төзелеш материалларын ташып та бетергән.

– Тәртип юк, менә төп бәла, – диде Гөлсимә Байтирәкова. – Мисал өчен, абый акчасына алынган төзелеш материалларын аның капка төбенә китереп өйсәләр, аңа берәү дә тимәс иде. Бөтен кешедә төзелеш бара, урлыйлар инде.

«РӘХМӘТТӘН БАШКА СҮЗ ЮК»

Йолдызның кырыклап гаиләсенә төзелеш өчен дәүләттән сертификат бирелмәгән. Барысының да сәбәбе төрле: янган йорты теркәлмәгән, авылда пропискада булмаган, кемдер мәрхүм әти-әнисеннән калган өйдә яшәп яткан. Ә бездә, документың булмаса, син беркем түгел. Әнә шундый гаиләләр башта кара кайгыга баткан. Бәхетләренә, аларга хәйриячеләр ярдәм кулы сузган. Документлары тәртиптә булмаган 18 гаиләне Татарстан хөкүмәте үз канаты астына алган. Тагын «Татнефть» оешмасы үзенең хәйрия фондыннан 12 гаиләгә торак төзү өчен килешү имзалаган. Моннан тыш, Россия мөселманнары Диния нәзарәте, Чувашия мөселманнары Диния нәзарәте, Самара өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте, башка шундый дини оешмалар аерым гаиләләргә йорт салырга алынган. Нәтиҗәдә, кулында сертификаты булган авылдашларына караганда, бу гаиләләр йортларына алданрак кереп утырган!

Йолдызга баргач, хәйриячеләр ярдәм итәргә алынган гаиләләрнең берсе – Мөхәммәтнәбиевләр белән аралаштык. Авыл башында яшәгәнгә күрә, ялкын беренчеләрдән булып аларның мал-мөлкәтен юк иткән иде.

– Янган йортыбыз 1991 елда салынган иде, ә мин аны яңарттым, – дип сөйләде ул чакта гаилә башлыгы Эдуард Мөхәммәтнәбиев. – Алты кеше – әнием, җәмәгатем һәм өч бала белән йортсыз калдык. Әти күптән вафат. Әлегә гаиләбез белән күрше авылда, туганнарда яшәп торабыз. Янган нигезне чистартканнан соң гына балаларны монда алып килдек, күңелләрендә авыр тойгы калмасын дидек...

Мөхәммәтнәбиевләргә Россия мөселманнары Диния нәзарәте ярдәм иткән. Дәүләттән аларга нибары 666 мең сум акча күчкән, чөнки гомер буе шунда яшәсәләр дә, гаилә

башлыгы йортны үз исеменә теркәмәгән була. Йорт янгач, әнисенә 333 мең сум һәм үзенә 333 мең сум акча бирелгән. Шуның белән шул.

– Аллаһка шөкер, яңа йортыбызга октябрь аенда ук күчендек, җылы, якты, бик ошый, – дип, телефоннан шатлыгы белән уртаклашты Эдуард Мөхәммәтнәбиев. – Россия мөселманнары Диния нәзарәтенә рәхмәттән башка сүз юк. Ярдәм кулы сузган һәр милләттәшебезгә авылдашлар исеменнән олы рәхмәтебезне җиткерәм. Нинди авыр вакытларда ташламадылар, булыштылар.

«ТАТАРСТАНГА ТАПШЫРЫРГА ИДЕ...»

Бүген йолдызлылар менә шулай яшәп ята. Җирле халык Курган өлкәсенең төзелеш оешмалары белән килешү төзегәнгә бик үкенә, ләкин артка юл юк. Кешеләр сертификаттагы акчаларны төзелеш оешмаларына күчерү турындагы документка кул куйган.

Урынлы бер сорау туа: Курган өлкәсенең администрациясе, прокуратура нәрсә карый соң? Алар бит бу проблеманы күреп, белеп тора. Бу сорауга Гөлсимә Байтирәкова болай дип җавап бирде:

– Бүген администрациянең төп максаты – төзелеш оешмаларыннан ничек тә йортларны эшләттереп бетерү. Хәзер гаеплеләрне җәзага тартып, икенче төзелеш оешмалары тапканчы, күпме вакыт узачак. «Аспект» белән «Табия» оешмаларының җитәкчеләре халык алдында чыгыш ясады, бер ай эчендә барысы да булачак, диләр. Буш вәгъдәләр булмаса...

Бу очракта бер нәрсә генә күңелне сөендерде: җирле халык Татарстанга бик рәхмәтле. Алар вәгъдәсен үтәгән. Авыл мәдәният йортында даими рәвештә җыелышлар булып тора икән. Менә шунда үзара: «Ник ул сертификатларны Татарстан төзелеш оешмаларына бирмәдек икән, әллә кайчан җылы өйләрдә утырыр идек», – дип сөйләшәләр икән. Шушы хәлләр килеп чыгар дип кем уйлаган?! «Кайда егыласыңны белсәң, салам түшәр идең», – ди бит халык.

Марс Тукаев, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең Россия Федерациясе төбәкләрендәге татар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү буенча урынбасары:
– Йолдыз авылындагы зур фаҗигадән соң, Россиядә, хәтта чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез тиз арада йолдызлыларга ярдәм кулы сузды. 9 май көнне Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты каршысында махсус штаб булдырылды: ике көн эчендә генә дә 2 миллион сумнан артык акча җыелды. Азык-төлек, кием-салым, төзелеш материаллары – иганәчеләр, халык барысы белән дә булышты. Атна саен зур йөк машиналары белән Йолдыз авылына ул кирәк-яракларны илттек.
Татарстан төзи торган 30 йортны яңа елга кадәр төзеп бетердек. Дөрес, кайсына су, кайсына газ кертәсе калган иде. Без берне планлаштырабыз, ләкин төрекләр әйтмешли: «Өйдәге хисап базарга туры килми». Төзүчеләр белән дә, төзелеш материаллары белән дә проблема булды, тик аларны вакытында хәл иттек.
Әлеге фаҗига безнең нинди бердәм, тырыш милләт булуыбызны күрсәтте. Йолдыз авылына барлыгы 100 миллион сумнан артык ярдәм күрсәтелде, бу бит иганәчеләр биргән акча! Күрше өлкәләрдәге дини оешмалар, татар җәмгыятьләре – берсе дә битараф калмады. Курган өлкәсенә баргач: «Татарларны үрнәк итеп куябыз, ничә мең чакрым ераклыкта яшәсәләр дә, бер-берләренә ярдәм кулы сузалар», – дип безгә башка милләтләр соклануларын белдерде.

ХӘЛӘЛ ФИНАНСЛАР КЫРЫ

Әскәр Сабиров

Кешбэк хәләл була аламы? Партнерлык (ислам) финансларының чынлыгын кем билгели? Ислам ипотекасының үзенчәлеге нәрсәдә? Татарстанда бәйсез ислам банкы ачылырмы? Әлеге һәм башка сорауларга «Татарстан» журналы редакциясендә узган түгәрәк өстәлдә катнашучылар җавап бирде.

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛДӘ КАТНАШТЫЛАР:

Рөстәм хәзрәт Нургалиев, Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге директоры

Руслан Хәлиуллин, ТР Икътисад министрлыгы вәкиле

Алексей Дробот, Ак Барс Банкның цифрлы факторинг идарәсе башлыгы

Марат Садриев, Ак Барс Банкның ислам банкингы юнәлеше җитәкчесе

Ильмар Сөләйманов, «Амаль» Финанс Йорты

Әскәр Сабиров, «Татарстан» журналының шеф-редакторы

Рәшит Хәйретдинов, «Татарстан» журналының башкарма директоры

Фото: Александр Ефремов

СТАТИСТИКА ҺӘМ ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫНА КЫЗЫКСЫНУ ТУРЫНДА

«ТАТАРСТАН»:

– Ислам финанс продуктлары Рубик кубигы түгел. Алар, әлбәттә, үз урыннарын табачак, ләкин тиз арада гына артык зур ихтыяҗ туар дип өметләнергә кирәкми. Партнерлык финанслары өлкәсендә эксперимент (анда Башкортстан, Дагыстан, Татарстан һәм Чечня катнаша) турында Федераль закон үз көченә кергәннән соң ук «Татарстан» журналы оештырган түгәрәк өстәлдә катнашучылар яңа базар перспективаларын әнә шулай бәяләгән иде. Ярты ел узганнан соң, вазгыять үзгәрдеме? Бүген нинди ислам финанс продуктларын алып була?

Рөстәм хәзрәт Нургалиев, Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге директоры

РӨСТӘМ ХӘЗРӘТ НУРГАЛИЕВ:

– Мин болай дим: ислам финанслары буенча үткәрелгән экспериментның үз маяклары бар, аларга карап гомуми вазгыять турында фикер йөртергә мөмкин. Мин – ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Россия ислам институты вәкиле. Безнең исәпләүләр, аналитика шуны төгәл күрсәтә: ислам финанс продуктлары белән кызыксыну арта. Мин әйткән маякларның берсе – тәкъдим ителгән ислам продуктлары буенча Голәмәләр шурасы тапшырган карар һәм сертификатлар санының арта баруы. Уйлап карагыз: узган ел без ике генә сертификат биргән идек. Быел ике айда өч сертификат тапшырылды инде, бу өч продукт буенча Голәмәләр шурасының өч карары. Финанс продуктының ислам канунна-рына туры килүенә сертификат сорап, тагын биш-алты гариза безнең карарны көтә.

– Бу нинди продуктлар, бәлки, сөйләп китәрсез?

– Әлбәттә. Без быел ислам финанслары буенча ким дигәндә ике продуктны уңышлы эшләтеп җибәрдек, дип уйлыйм. Бу - Ак Барс Банкы химаясында ислам факторингы һәм исәп-хисап-касса хезмәте – шулай ук Ак Барс банкы тарафыннан. Тагын ике продукт каралу этабында. Мөгаен, беренче кварталда алар да хупланыр. Узган елда республикада тагын хәләл пенсия продукты старт алды. Белгәнегезчә, бездә мәҗбүри пенсия иминияте генә түгел, ирекле иминиятләштерү дә бар. Хәләл продуктлар системасы буенча ТР Милли пенсия фонды белән менә шундый хезмәттәшлек үрнәге пәйда булды.

Руслан Хәлиуллин, ТР Икътисад министрлыгы вәкиле

РУСЛАН ХӘЛИУЛЛИН:

– Болар барысы да безнең Татарстан продуктлары. Без, мөгаен, ислам (партнерлык) продуктлары буенча да, экспериментта катнашучылар саны буенча да Россиядә иң алда барабыздыр. Ә бит әле кушылырга теләгән бизнес, финанс, банк структуралары тагын бар. Гәрчә ислам финансларын үстерүдә, һичшиксез, проблемалар булса да...

– Сорау шундый: партнерлык (ислам) продуктларына ихтыяҗ бүген никадәр дәрәҗәдә? Халык, юридик затлар тарафыннан... Йөзләгән, меңләгән, ун меңләгән кеше һәм оешмамы? Төгәл статистика бармы?

– Безне көйләүче оешма – РФ Үзәк банкы. Көйләүче экспериментта катнашучыларның барысы белән дә аралаша, мәгълүмат җыя, аны туплый. Әмма монда шуны истә тотарга кирәк: экспериментта катнашучылар – коммерцияле компанияләр, закон буенча кайбер мәгълүматны ачарга ярамый, сер санала. Шунысы да аңлашыла ки, ярты ел эчендә генә зур әйләнешкә ирешү авыр. Монда, мөгаен, беренче чиратта нинди продуктлар эшләп киткәнен, экспериментта катнашучылар санының ничек артуын карарга кирәктер. Проблемаларны яшерергә ярамый. Мәсәлән, беренче айлар күпләрнең ислам финансларының нәрсә икәнен аңламавын күрсәтте. Башта кешеләргә аның асылын аңлатырга, лекцияләр укырга туры килде. Аннары ислам финанс продуктларын кайдан алырга, кая барырга кирәклеген сөйләргә. Бу эшне күпкә катлауландыра. Экспериментта катнашучылар, хәләл финанслар буенча белгечләр, шулай ук агарту эшчәнлеге белән дә шөгыльләнергә мәҗбүр. Россиядә хәзрәт хәзрәт кенә түгел, дияр идем.

ҮБ РЕЕСТРЫНДА ИСЛАМ ПРОДУКТЫН СЕРТИФИКАТЛАУ

– Билгеле булганча, партнерлык финанслары буенча экспериментта катнашучыларның рәсми исемлеге Үзәк банк реестрында теркәлгән. Ә банк, оешма әлеге реестрда теркәлсә дә, аның продукты партнерлык сертификатын ала алмаган булырга мөмкинме?

РӨСТӘМ ХӘЗРӘТ НУРГАЛИЕВ:

– Андый хәл бар инде.

– Ә бу ни дәрәҗәдә дөрес соң?

– Үзәк банк үзендә булган нормативка таяна. Бу конституцион нормалар, законнар һ.б. Ислам продуктын сертификатлау мәсьәләсе беренче чиратта ислам белемнәре, ислам теологиясе белән бәйле. Ислам теологиясе өчен җавап бирергә экспертка ислам кануннарын белү генә җитми. Ул чын дин эшлеклесе, аның компетенциясе һәм, әйтик, мөселманнар алдында җаваплылык мандаты булырга тиеш. Шуңа күрә ислам продуктын сертификатлау белән төрле төбәкләрдәге мөселманнарның дини идарәләре шөгыльләнә. Аерым алганда, Татарстанда бу ТР мөселманнары Диния нәзарәте. Әмма, дип аңлата безгә көйләүче, ТР мөселманнары Диния нәзарәте, теге яки бу продуктның хәләллеген раслаучы яки кире кагучы зат буларак, Үзәк банкка турыдан-туры интеграцияләнә алмый. Шуңа күрә дә кайбер аңлашылмаучанлыклар туа: формаль кагыйдәләр буенча экспериментта катнашучы реестрга кертелгән, тик аның продукты реаль дини кануннарга туры килмәскә мөмкин. Менә бу проблеманы, буталчыкны ашыгыч рәвештә чишәргә кирәк, дип уйлыйм. Без хәл итү юлларын күрсәттек, ләкин әлегә сорау ачык кала бирә.

– Димәк, мин, потенциаль кулланучы буларак, ҮБ реестрына кереп, анда берәр оешманы, әйтик, банкны табып, аңа ышанып, аның продуктыннан файдалана алам. Ә нәтиҗәдә, ул хәләл булмаска да мөмкин?

– Әйе, сез хәләл булмаган продукт алырга мөмкин, әгәр сез дин тотучы мөселман икән, ислам теологиясе күзлегеннән караганда гөнаһ гамәл кыласыз. Моның өчен кем җавап бирә? Үзәк банкмы? Тик Үзәк банк дини оешма түгел бит…

РУСЛАН ХӘЛИУЛЛИН:

– Мин бер нәрсә әйтә алам: бу проблема ачыкланды. Без дүрт төбәктән экспертларны җыйдык. Проблема барлык хакимият органнарына да, Үзәк банкка да, шик тудырган продуктка ия оешма вәкилләренә дә җиткерелде. Безне ишеттеләр, диалог башланды.

РӨСТӘМ ХӘЗРӘТ НУРГАЛИЕВ:

– Бу проблема хәл ителергә тиеш. Ләкин бу ничек эшләнә ала соң? Әлегә уртак фикер юк, гәрчә без хәл итү юлын тәкъдим итсәк тә. Без диалогка ачык, мөмкин булган вариантлар турында сөйләшергә әзер. Сүз уңаеннан, Татарстан Республикасына килгәндә, бездә проблема юк. Биредә базарга чыга торган ислам финанслары продуктлары ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә сертификатлау уза. Монда булган хезмәттәшләр ялганларга ирек бирмәс.

– Бу Татарстан продуктлары. Ләкин башка төбәкләрдән килгән продуктлар арасында хәләл булмаган продуктка юлыкмауга нинди гарантия бар?

– Монда алдыбызда торган мәсьәләнең катлаулы булуын исәпкә алырга кирәк. Без формалаштырырга тырышкан модель яңа, дөнья күләмендә ул юк. Ислам финанслары кайда сатыла һәм тормышка ашырыла? Кагыйдә буларак, бу – гарәп-мөселман дөньясы. Анда көйләү мәсьәләләре Конституция дәрәҗәсендә беркетелгән һәм шәригать эксперты хакимиятнең рәсми вәкиле булып тора. Аның ислам нормаларына туры килмәгән продуктны сатуны туктатырга тулы хокукы бар. Россиядәге кебек модель әлегә кадәр беркайда да тормышка ашырылмаган.

– Әгәр дә продуктның шәригать нормаларына туры килмәвен күрсәгез нишлисез? Бу фактны фаш итәсезме?

– Әлбәттә, башта сөйләшәбез. Әлеге продуктны тәкъдим иткән вәкилгә чыгабыз, хилафлык турында хәбәр итәбез һәм дөрес реакциягә өметләнәбез. Ләкин әгәр дә күпмедер вакыт эчендә хәлне яхшыга үзгәртергә теләмиләр икән, әлбәттә, фактны халыкка җиткерәбез. Мөмкин булган барлык ысуллар белән.

ХӘЛӘЛ КЕШБӘК ҺӘМ ПАРТНЕРЛЫК ПРИНЦИПЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ ИНВЕСТИЦИЯЛӘҮ

– Бүген Татарстанда ТР мөселманнары Диния нәзарәте сертификатын алган нинди партнерлык финанс продуктлары бар?

МАРАТ САДРИЕВ:

– Әле унике ел элек кенә без пилот режимында ислам ипотекасын эшләтеп җибәргән идек. Бүгенге көнгә кадәр ул уникаль продукт саналды – бары тик күптән түгел генә шундый продуктны базарга тагын бер зур банк чыгарды. Сүз уңаеннан, узган ел бездә ислам ипотекасын, аннан алдагы ел белән чагыштырганда, өч тапкыр күбрәк алдылар – бу партнерлык финансларына карата кызыксынуның булу-булмавына мисал. Безнең ислам дебет картасына да тотрыклы ихтыяҗ күзәтелә – аны инде ун меңнән артык кеше алды. Хәзер ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә партнерларыбызның дебет карталары буенча хәләл кешбәк алырга мөмкинлек бирә торган проект сертификат көтә.

Марат Садриев, Ак Барс Банкның ислам банкингы юнәлеше җитәкчесе

– Кешбэк та хәләл була аламы?

– Кешбэк кешбэктан аерыла. Традицион кешбэк, экспертлар фикере буенча, ислам кануннарына туры килми. Шуңа күрә без экспертлар белән бергә нәкъ менә хәләл кешбэк продукты уйлап таптык.

– Аерма нәрсәдә?

– Аерма шунда ки, банк үз кесәсеннән түләгәне – рөхсәт ителмәгән кешбэк. Хәләл кешбэкта исә клиент хәләл продукция өчен предприятиегә түләгән акча кулланылачак. Бу предприятиеләр безнең партнерлар һәм үз акчаларыннан кешбэк бирәчәкләр.

Башка яңа продуктлар турында. Шушы көннәрдә ТР мөфтие безгә хәләл исәп-хисап-касса хезмәте күрсәтүгә сертификат тапшырды. Аңа шулай ук хәләл карта бәйләнгән, ул клиентка исәп-хисап счетында булган акчаларны кулланырга мөмкинлек бирә. Проект финанславы продукты да эшләнә – ул төзелеш компанияләренә хәләл акча кулланып йортлар төзергә мөмкинлек бирәчәк.

– Бу продукт ничек эшләячәк?

– Без акчаны төзүчегә бирәбез, ул йорт төзи, фатирларны сата, табыш ала һәм аннары бу табышны безнең белән бүлешә. Бу, аңлавыгызча, кредит түгел, ә классик партнерлык финанславы. Кредит күпмедер вакытка, түләү һәм кире кайтарылу шартларында бирелә. Монда да вакыт исәбе бар, сроклар билгеләнгән, ә түләү – көтелгән генә, гарантияләнмәгән. Кайтарылу кебек. Ягъни теорик яктан караганда, берәр нәрсә ниятләнгәнчә барып чыкмаса, банк та югалтачак. Партнерлар финанс куркынычын да үзара бүлешә...

Ислам инвестицияләренең мондый формасын, ягъни мударабаны без лизинг компанияләренә финанслар биргәндә дә кулланабыз. Ниятебездә үзебезнең партнерлык лизинг продуктын эшләү дә бар, моның белән безнең бүлендек компания шөгыльләнә.

ИСЛАМ ФАКТОРИНГЫ ҺӘМ ГАДЕЛ ФИНАНСЛАР ТУРЫНДА

Алексей Дробот, Ак Барс Банкның цифрлы факторинг идарәсе башлыгы

АЛЕКСЕЙ ДРОБОТ:

– Клиентларыбызга әйләнештәге акчаларын тулыландыру өчен партнерлык финансы алырга мөмкинлек бирүче беренче продукт эшләнде. Барысы да 2022 елда башланды: кайбер клиентларыбызның тәэминатчылар белән проблемалары килеп чыкты – алына торган чимал, товар, җиһазлар, хезмәтләр өчен түләүләрне кичектереп торулар туктатылды. Башта түлә, аннары алырсың, янәсе. Ләкин бөтен кешенең дә болай эшләргә акчасы җитми бит. Шуңа күрә банк тәэминат чылбырын финанслау продуктын эшләде дә. Гади генә әйткәндә, без үз акчабызга җитештерүчегә кирәкле чималны сатып алабыз, аны бирәбез, ул ахыргы хәләл продуктны җитештерә, аны сата, ә без табыштан үзебезгә дигән өстәмә акчаны алабыз.

– Классик партнерлык килеп чыга түгелме?

– Бик дөрес. Без, клиентның партнеры буларак, аның үтенече буенча чимал сатып алабыз, ул аны предприятиесендә куллана, алга таба без аның үз продуктын ахыргы кулланучыга сатуын көтәбез генә.

– Бу һәр клиент өчен каралмагандыр инде? Мөгаен, клиентка ярдәм кулы сузаргамы-юкмы икәнен аңлау өчен ниндидер тикшеренүләр үткәрәсездер?

– Дөрес сорау. Без гади кредит очрагындагы кебек акчаны кире кайтаруны гына көтә алмыйбыз, шуңа күрә финанс куркынычы ихтималын да күз уңында тотарга тиеш - без хәйрия оешмасы түгел. Партнерлык барыбер табыш алуны күздә тота. Без шуны бик яхшы аңлыйбыз: Россия территориясендә бик күп тәэминатчылар хәләл продукция бирә, өстәвенә, гадәти товарны җитештергән гадәти җитештерүче кебек үк шартларда. Алар бераз конкуренциядән читтәрәк кала кебек. Әгәр гади кулланучының ирекле, хәләл булмаган акчаны алып тору мөмкинлеге булса, безнең потенциаль клиентның ислам финанслары буенча мондый мөмкинлеге юк. Шуңа күрә бүгенге көндә без финанс куркынычын федераль челтәрләргә кабул итәбез – бу илебез буенча тәкъдим ителгән бөтен эре челтәрләр. Безнең клиент дебиторлык бурычы буенча таләпләр хокукын өченче компанияләргә – федераль челтәрләргә бирә. Һәм шулай килеп чыга ки, безнең клиент турыдан-туры керем алмый, ә безнең банк аша ала. Димәк, федераль челтәр сатылган товар өчен тәэминатчы алдындагы бурычын безгә түли. Без алдан сөйләшеп куелган өстәмә акчаны үзебезгә алабыз, ә калганын акчаны клиентның исәп-хисап счетына җибәрәбез.

Гыйнварда продуктыбызга сертификат алдык. Хәзерге вакытта ислам факторингы буенча эш башлана гына әле. Ләкин яңалыкларда әлеге продукт турында мәгълүмат пәйда булуга, мин хәлнең ничек үзгәрүен күрәм. Ислам факторингы белән мөселманнар булмаганнар да актив кызыксына. Без аларны кире кага алабызмы?

РӨСТӘМ ХӘЗРӘТ НУРГАЛИЕВ:
– Шуны да онытмаска кирәк: без күпмилләтле илдә, дини, милли яктан бик төрле, әмма баланс сакланган мохиттә яшибез, потенциаль клиент теләсә кайсы милләттән булырга мөмкин. Ул ислам финансларының өстенлекләрен күрә икән, моның нәрсәсе начар? Без аңа үз продуктыбызны бирүдән баш тарта алмыйбыз. Көйләүче дә бездән шуны көтәдер. Минемчә, монда бернинди дә начарлык юк. Бу ислам икътисад системасының яшәүгә сәләтен тагын бер кат исбатлый.

РУСЛАН ХӘЛИУЛЛИН:
– Күпчелек кеше өчен хәләл сыйфат билгесе дә әле. Алар үзләрен алдамаячакларын, әйтелгән шартларның үтәләчәген белә. Хәләл казылыкны барысы да сатып ала. Кассада сездән нинди дин тотуыгыз турында сорамыйлар. Мисал китерәм. Казахстанда бер эшмәкәр беренчеләрдән булып хәләл кибет ача, тиздән ул мондый нәтиҗәгә килә: иң рәхмәтле клиентлар – рус әбиләре. Ни өчен? Чөнки монда дөрес үлчиләр! Хәзер дөньяда безне нәрсә беләндер җәлеп итәргә, кайдадыр вак язу белән язарга, кайдадыр кирәкмәгән комиссия алырга тырышалар. Ислам финанслары монда гадел финансларның үрнәге булырга мөмкин. Кешегә йөзе белән борылган банк.

ЯЛГАН ТОВАРДАН НИЧЕК САКЛАНЫРГА

– Банкта, кибеттә, финанс компаниясендә миңа тәкъдим ителгән продуктның хәләл булуын кем контрольдә тота?

РӨСТӘМ ХӘЗРӘТ НУРГАЛИЕВ:
– Татарстанда сатыла торган барлык ислам продуктларын ТР мөселманнары Диния нәзарәте вәкиле, кагыйдә буларак, Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы әгъзасы контрольдә тота. Ислам финанслары кырында тәүге уенчыларның берсе булган «Амаль» Финанс Йорты вәкиле Ильмар моны сезгә раслый ала. Мәсәлән, аларны ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы әгъзасы Булат хәзрәт Мөлеков контрольдә тота.

– Диния нәзарәте бөтенесен дә контрольдә тотып бетерә аламы? Физик яктан бу мөмкинме?

МАРАТ САДРИЕВ:
– 1 марттан бездә үз эксперты булган бүлек ачылды. Ул, үз чиратында, безнең тышкы аудиторыбыз – ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы әгъзасы каршында хисап тотачак. Ләкин факторингта, мәсәлән, абсолют контроль мөмкин түгел. Әйтик, без чимал сатып алабыз, клиент аның барлык критерийларга туры килүен раслый. Клиент бу чимал белән нәрсә эшләячәк – бу аның җаваплылыгында. Хәзер безнең белгеч базар операцияләрен тикшерәчәк. Әгәр дә без клиентның акчаны дөрес булмаган якка юнәлтүен күрсәк (закон буенча хокуклы булса да), без аңа башка счетка күчүне тәкъдим итәчәкбез – гадәти, хәрәм счетка. Эшләсен, әмма яшел марка астында түгел – алдарга кирәкми.

– Гадел акчалар ике якның да гадел булуын күздә тота. Моны партнерлык финанслары базарында күптән эшләгән «Амаль» Финанс Йортыннан да яхшырак белүче бармы икән?

Ильмар Сөләйманов, «Амаль» Финанс Йорты

ИЛЬМАР СӨЛӘЙМАНОВ:
– Безнең компания әлеге базарда 2010 елдан бирле эш итә. Ике юнәлеш буенча эшлибез, беренчесе – мудараба принциплары буенча инвестицияләр җәлеп итү. Икенчесе – нигездә, кече һәм урта бизнесны финанслау. Без, аерым алганда, автомобильләр, махсус техника, җиһазлар сатып алуны финанслыйбыз. Стартапларны без финансламыйбыз. Беренче юнәлешне алсак, монда берничә төрле пакет тәкъдим итәбез. Берсе – күпмедер акчасы булган һәм дивидендлар алу өчен аны эшкә кертергә әзер клиентлар өчен. «Хаҗ өчен тупла» дип аталган продукт та бар. Кеше акчасын кертә, алар эшли һәм әкренләп аның счетын тулыландыра. Хәйрия тарифы бар: клиент табышының бер өлеше «Ярдәм» фондына күчерелә.

– Инвестицияле продуктлар буенча минималь кертем күпме?
– Якынча 50 меңнән башлана. Гади кешеләр өчен бик реаль акча. Ә клиентны финанслаганда без финанс йөкләмәсен, аның түли алу сәләтен карыйбыз. Теләсә кемгә акча таратмыйбыз. Максатыбыз кешене бурычка батыру түгел. Проблемалар арасында – потенциаль клиентларның финанслар буенча белемнәренең түбән булуы. Партнерлык килешүенең асылын аңлатуга, кул куяр алдыннан табышның нинди өлешенә өметләнергә кирәклеге турында сөйләшүгә күп вакыт китә. Барысын да тәфсилләп аңлату өчен, кешеләрне шәригать белгечләренә җибәрәбез.

ИХТЫЯҖНЫҢ ТӘКЪДИМНЕ ТУДЫРУЫ ТУРЫНДА

РУСЛАН ХӘЛИУЛЛИН:
– Чынлыкта, партнерлык (ислам) финансларын, ислам банкингын үстереп, без сәламәт альтернатива булдырабыз. Игътибар итегез: бүген банклардан кредит алганда кешеләр хафага төшә: капкын! Югары процент ставкалары, штрафлар, пенялар... Ә без сәламәт икътисад культурасын булдырабыз. Әйе, ул әле бик кечкенә масштабта. Әмма ислам финансларының асылын белгән кешеләр инде процесска кушылды. Һәр зур проект инвестицияләрдән тора. Партнерлык үзе үк төрле инвесторлар килүен аңлата. Шуңа күрә без зур акча әйләнешләренә дә җитәрбез дип өметләнәм. Монда яхшы проектларның нәтиҗәле булуы бик мөһим.

МАРАТ САДРИЕВ:
– Дөрес. Исегезгә төшерик: 2005–2006 елларда, ипотека пәйда булгач, аның күчемсез милек сату базарындагы өлеше бер проценттан да кимрәк иде. Бүген – 89 процент. Кешеләр ипотеканың нәрсә икәнен аңлады, аны актив куллана. Ислам финанслары белән дә шул ук хәл. Асылда, без әле яңа гына эшли башладык, безнең базар зур түгел, монда банклардагы кебек триллионлык әйләнеш юк. Ләкин күпмедер вакыттан соң, продуктлар да, клиентлар да ишәер, дип өметләнәм. Ислам финансларының тулы базары эшләячәк. Югары уку йортларында ихтыяҗ тәкъдимне тудыра дип укыталар. Ислам финансларында әлегә алай түгел. Безгә мондый продуктның булуын күрсәтергә кирәк! Ислам финанслары буенча сыйфатлы продуктлар тәкъдим итик! Бу чакта, һичшиксез, банк продуктлары гына түгел, сатып алучы да булачак.

РӨСТӘМ ХӘЗРӘТ НУРГАЛИЕВ:
– Маратны хуплыйсым килә. Без бик озак альтернативасы булмаган икътисад системасында яшәдек. Һәм Россиядә яшәгән 25–30 миллионлап мөселман (төрле исәпләүләр буенча) башка вариантлар күрмәде. Һәм озак вакытлар ислам буенча рөхсәт ителмәгән дип саналган продуктлардан файдаланды. Ләкин дөнья көчле үзгәреш кичерә, яңа мәгълүмат та тиз үзләштерелә. Карагыз, Россия Федерациясендә мөселманнар гасырлар буе яши, ә хәләл продукция 30 ел элек кенә җитештерелә башлады. Моңа кадәр «хәләл» төшенчәсе нинди булган: дуңгыз ите яисә дуңгыз ите түгел. 30 ел элек кенә без бозау ите дә, сарык ите дә хәләл түгел икәнен аңладык. Моны аңлагач, шунда ук үзгәрдек һәм дөрес хәләл продукцияне куллана башладык. Финанслау белән дә шулай булыр, дип уйлыйм. Тик кайбер банклар кебек фикер йөртергә кирәкми: янәсе, без әзер, ләкин безгә ихтыяҗны күрсәтегез. Безнең Татарстан банкы кебек эшләргә кирәк: ихтыяҗны көтәргә түгел, ә тәкъдим формалаштырырга. Бер продукт, икенче, өченче... Һәм мин ышанам, әлеге кыю гамәлләр ихтыяҗны формалаштырырга мөмкинлек бирәчәк.

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ИСЛАМ БАНКЫ ҺӘМ САНКЦИЯЛӘРГӘ КАРАМАСТАН ИНВЕСТИЦИЯЛӘР ТУРЫНДА

– Партнерлык финанслары өлкәсендәге эксперимент чит ил ислам финансларын җәлеп итәргә мөмкинме? Әллә бүгенге вазгыять шартларында моны көтеп булмыймы?

РӨСТӘМ ХӘЗРӘТ НУРГАЛИЕВ:
– Эксперимент башланганда иң элек инвестицияләр җәлеп итү турында сүз барды. Ләкин бүген, алты айдан соң, хәтта көйләүченең дә таләбе үзгәрә башлады. Шәхсән мин моңа бик шат. Без гарәп илләреннән зур инвестицияләр җәлеп итү турында хыялланудан туктадык һәм үз халкыбызга ышана башладык. Янчыкларга, итек эчләренә, мендәр асларына яшерелгән акчаларга. Минемчә, бу илебезнең икътисади иминлеге ягыннан нәтиҗәлерәк тә. Бу дөресрәк юнәлеш.

РУСЛАН ХӘЛИУЛЛИН:
– Сүз уңаеннан, мендәр асларында, янчыкларда да триллионнар ята. Чит ил инвестицияләренә килгәндә исә, аларны алу механизмнары бар, әмма санкцияләр, әлбәттә, эшне катлауландыра. Безнең потенциаль партнерлар ислам финанслары буенча эксперимент турында закон кабул ителүне уңай бәяләде, аларны кызыксындырган реаль бизнес-проектлар бар. Ләкин аларда катнашу, мөгаен, хөкүмәтара килешүләр нигезендә булачактыр, финанс куркынычларына юлыкмас өчен. Нигездә, монда нинди механизмнарны кулланырга мөмкин булуы аңлашыла, хәзер реаль законнар да бар.

– Бездә пәйда булган Иран банкы – әлеге кырда уйнарлык уенчымы?

РӨСТӘМ ХӘЗРӘТ НУРГАЛИЕВ:
– Әйе, ул эшли, ислам продуктлары буенча эшли, аның турында аз белүебезнең сәбәбе, бәлки, маркетингның начар куелуындадыр. Бу банк, сүз уңаеннан, РФ законнарына тулысынча туры китереп төзелгән. Бу Иранның иң зур банкы – «Милләт банкы»ның бүлендеге. Ике ил арасындагы партнерлык ныгый барачак, күптән түгел Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Иранда булып кайтты. Шуңа күрә банкның киләчәге бар.

МАРАТ САДРИЕВ:
– Күптән түгел ТР мөфтие катнашындагы киңәшмәдә тулысынча ислам кануннары буенча эшләүче банк ачу идеясе ишетелде. Үзебезнекен, Татарстанныкын. Бик амбицияле идея.

РӨСТӘМ ХӘЗРӘТ НУРГАЛИЕВ:
– Хәзерге вакытта бу максат фантастика тоелса да, ирешеп булырлык, дип уйлыйм. Күз алдына китерегез, безнең үз тәҗрибәсе булган берничә уенчыбыз бар. Аларның һәрберсе үзенең партнерлык (ислам) продуктлары җыелмасына ия, кемнеңдер үз фишкасы бар. Шуңа күрә бәйсез ислам банкы оешкан вакытка хәзерге уенчыларның бу эштә акча белән генә түгел, тәҗрибәсе белән дә катнашу мөмкинлеге булачак. Эксперимент уңышлы барган очракта, әлеге уенчылар барысы да «Бәйсез ислам банкы» дип аталган яңа структурада катнаша ала. Үзләре эшләп туплаган тәҗрибәгә таянып.

«АВТОГРАДБАНК». РОССИЯДӘ ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫН КЕРТҮДӘ БЕРЕНЧЕЛӘР САФЫНДА

Дмитрий Сивков

Узган елның октябреннән партнерлык (ислам) финанс операцияләрен башкару өчен хокук базасы булырлык федераль закон гамәлгә керде. Хәзерге вакытта эксперименталь программага ун кредит-финанс оешмасы керде, һәм алар арасында банклар өч кенә. Татарстандагы «Автоградбанк» президенты Павел Сигал «Татарстан» журналы укучыларына ил өчен яңа төр банк хезмәтен эшләтеп җибәрүчеләр сафында булуның үзенчәлекләре турында сөйләде.

БЕРКАЙЧАН ДА «ӘСИРЛЕКТӘ» БУЛМАДЫК

– Павел Абрамович, «Автоградбанк»ка алдынгылык ят түгел, чөнки 1991 елда нигез салынган оешмагыз Татарстанда иң беренче шәхси банкларның берсе санала. Бу еллар эчендә Яр Чаллыдагы кечкенә генә шәһәр банкы, бик күп уңышларга ирешеп, «Россиянең социаль-икътисади үсеше флагманнары» гомуммилли реестрына һәм ипотека кредитлары бирү буенча Россиянең беренче 20 банкы рейтингына керде. Бу казанышларга нәрсәләр хисабына ирешелде соң?

– Әйе, ул чорда оешкан банкларның күпчелеге бүген инде эшләми. Банкның бүген ничек эшләве, беренче чиратта, минемчә, аның әле Венера Иванова җитәкчелегендәге беренче командасының казанышыдыр. Хәзерге вакытта банкта эшләгән тәҗрибәле хезмәткәрләрнең күпчелеге шул командадан. Аларга алмашка балалары килә. Мисалга, ислам банкингы буенча эшче төркемне Гөлнара Шәрәпова җитәкли, аның әнисе банкның беренче көннәреннән үк эшләгән, хәзер ул лаеклы ялда, әмма инде менә 20 ел аның эшен кызы дәвам итә. Шул рәвешле хезмәт династияләре пәйда була дияргә мөмкин.

Икенче сәбәп – «Автоградбанк»ның сәнәгать ягыннан үсеш алган территориядә оешуы. Бу очракта мин Татарстанны да, Яр Чаллыны да күз уңында тотам. Монда машина төзелеше гиганты КАМАЗ да, аграр сәнәгать, нефть чыгару һәм эшкәртү тармаклары алга киткән Кама аръягы икътисади зонасы да бар.

Өченчесе – «Автоградбанк» беркайчан да кэптив булмады. Аңлатып китәм: үз мәнфәгатьләрен кайгырту өчен нинди дә булса финанс-сәнәгать төркеме тарафыннан оештырылган кредит оешмасын шулай дип атыйлар. Инглизчә captive сүзе «тотылган», «әсир» мәгънәсен аңлата. Шуңа күрә без беркайчан да «әсирлектә» булмадык, диясе килә. Банк һәрвакыт кече һәм урта бизнес белән эшли. Сүз уңаеннан, мин килгәнче, төп акционер юк иде, алар берничә санала иде, шуңа күрә күп тармакларга җәлеп ителгән активларга ия киң диверсификация (компания эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген финанс куркынычларын бүлү хисабына арттыру) эшләгән.

ҺӘРНӘРСӘГӘ ҮЗ АКЫЛЫҢ БЕЛӘН ИРЕШҮ

– Һәм, мөгаен алдынгылар рәтендә булырга, яңа продуктларны беренче булып эшләтеп җибәргә теләү дә алга этәргәндер...

– Чыннан да бу шулай. «Автоградбанк» үз тармагында еш кына пионерлар рәтендә йөри. Әйтик, беренче бизнесменнар (ул чакта – Чаллы кооператорлары) үз исәп-хисап счетларын безнең банкта ачтылар, ягъни без бизнесның нәрсә икәненә, аның белән ничек эшләргә кирәклегенә

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА. «Автоградбанк» АЖ

төшенгән беренче белгечләр. Татарстанда беренчеләрдән булып пластик карталар чыгардык, беренчеләрдән булып банкоматта түләүләр кабул итә башладык, мобиль телефоннар аша түләүне керттек, ипотека кредитлары бирә башладык.

Әлеге факторлар банкка күп юнәлешләр буенча уңышлы үсәргә мөмкинлек бирде. Хәзер чиратта – ислам финансларын кертү.

– Эшчәнлегегезнең әлеге юнәлеше турында җентекләбрәк сөйләсәгез әле.

– Эшчәнлек дип сөйләргә әлегә иртәрәктер. Без әле бары тик шул юнәлешне алабыз гына, ислам банкингы продуктларын һәм аларны гамәлгә кертү механизмнарын эшлибез.

Исегезгә төшерәбез, ислам финанс моделенең асылы мөселманнарга көндәлек тормышта, шул исәптән икътисади эшчәнлектә салынган тыюларны бозмыйча эшләү. Сүз акчадан файдаланган өчен алдан билгеләнгән процент алу турында бара, ислам моны риба дип аңлата; керем алуны һәм тыелган гамәлләрдә катнашуны тыю турында: хәмер һәм тәмәке, дуңгыз ите җитештерү һәм сату, тотализатор һ.б. шундый комарлы уеннарда уйнау һәм оештыру. Шулай ук табыш алу билгесез һәм артык финанс куркынычы белән бәйле булган ысуллар да тыела.

– Һәм монда башкалар тәҗрибәсенә таяну мөмкинлеге дә юкмы?

– Бик дөрес. Һәрхәлдә, безнең илдә. Федераль законның максаты да – мөселманнар күп яшәгән һәм ислам финанс структуралары эшли торган төбәкләрдә ислам финанс моделен сынау. Бу, Татарстаннан тыш, тагын Башкортстан, Дагыстан һәм Чечен республикалары.

Әлбәттә, партнерлык финанслары өлкәсендә ниндидер эшләнмәләр бар иде, шул исәптән безнең республикада да, әмма махсус ислам банк офисы эшенең көйләнгән механизмы әлегә кадәр юк. Әзер карарлар да юк, шуңа күрә хәләл банк продуктларын үз акылың белән уйлап чыгарырга туры килә. Күп нәрсә партнерыбыз – ТР мөселманнары Диния нәзарәтенә бәйле, аларның белгечләре безгә хаталардан сакланырга булыша, шулай ук хәләл финанс продуктлары экспертлары буенча да Диния нәзарәте ярдәменә өметләнәбез.

КЛИЕНТЛАР ӨЧЕН УҢАЙЛЫРАК ФОРМА

– Сезне тыңлагач, ислам банкингын гамәлгә кертү тоташ проблемалардан тора кебек. Алай булгач, бу сезгә нәрсәгә кирәк?

– Бу хакта еш кызыксыналар, хәзер дә сорыйлар. Мәсәлән, Үзәк банк һәм башка хезмәттәшләр моннан нинди табыш көтүем, гомумән, партнерлык финансларына ихтыяҗның булу-булмавы белән кызыксыналар иде. Мин ислам банкингын үстерүнең кирәклеген күбрәк интуитив рәвештә аңлыйм, дип җавап бирә идем. Бүген моңа ышаныч пәйда булды.

Шундый фактны гына алып карыйк: республика халкының якынча яртысы – татарлар, аларның күбесе мөселман, әчке тоемлаулары буенча гына булса да. Әгәр дә аларның бер өлеше шәригать кушканнарны төгәл үти икән, алар акчаларын җыя яки үзләре белгәнчә ниндидер эшкә сала, чөнки хәзерге вакытта алар өчен банк хезмәтләре юк.

– Бу уй ничек пәйда булды?

– Теманы җентекләбрәк өйрәнгәннән соң. Шулай ук ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы гыйльми секретаре, Казан ислам институты проректоры Рөстәм хәзрәт Нургалиев белән киңәшләшү дә ышаныч бирде. Ул ислам банкингы хезмәтләренә ихтыяҗ зур булыр, Татарстанда гына да меңләгән гаилә алардан файдаланыр, дип ышана.

Тагын бер нәрсә: партнерлык финанс продуктлары мөселманнар өчен генә түгел. Мәсәлән, башка конфессия вәкилләрен ислам банкингы буенча түләүләр соңга калган очракта пеня һәм штрафларның рөхсәт ителмәве дә җәлеп итәргә мөмкин. Тагын түләмәүчеләр белән судлашу да каралмаган. Бер сүз белән әйткәндә – партнерлык. Димәк, клиент өчен уңайлырак һәм йомшаграк форма, традицион банкингтагы кебек катгый түгел. Сүз уңаеннан, бу катгыйлык банклар тарафыннан гына түгел, ә көйләүче – Үзәк банк тарафыннан билгеләнә. Мәсәлән, күреп торасың, эшмәкәр авыр хәлгә тарыган, син бернәрсә дә эшләмисең, бернәрсәсен дә тартып алмыйсың... Хәленә кереп була, ләкин Үзәк банкта шунда ук сорау туа: ни өчен чаралар күрелми? Ә чара күрү – тартып алу алу, бөлгенлеккә төшерү...

БИЗНЕСМЕН ГЕНӘ ТҮГЕЛ, СӘЯСӘТЧЕ ДӘ

– Шунысы сәер: моңа кадәр партнерлык финансларының мондый зур потенциалына игътибар ителмәгән...

– Сүз уңаеннан, без Венера Иванова белән бу тема буенча ун ел элек, мин банкка килгәч, шактый тәфсилле итеп фикер алышкан идек. Кызыксыну бар иде, әмма бу юнәлешне үстерү мөмкинлеге бирә торган закон базасы булмады. Үзәк банк бу программаларга һәрвакыт бик сак карый иде, хәзер хәл үзгәрде. Ил Көньякка һәм Көнчыгышка борылды.

Хәзер программада ун кредит-финанс оешмасы бар, әмма алар арасында банклар әлегә өч кенә. Арада «Автоградбанк» кына санкцияләргә тартылмаган. Бу чит илләрдән партнерлык финансларын җәлеп итәргә мөмкинлек бирә. Теоретик яктан карaганда, без бүгенге көндә Россиягә ислам финанслары килә ала торган канал. Ә инде аның ничек гамәлгә ашырылачагы берничә факторга бәйле һәм, беренче чиратта, үзебезнең потенциаль партнерларыбызга нәрсә тәкъдим итә алуыбызга.

– Һәм конкрет нәрсә?

– Бу турыда җентекләп сөйләү иртәрәк. Бу, мөгаен, хәләл дебет банк карталары, хәләл инвестицияләр кертү мөмкинлеге булыр... Бу сорауга бераз соңрак әйләнеп кайтырга тәкъдим итәм

– Сөйләштек. Павел Абрамович, сез бизнесмен гына түгел, сәясәтче дә, кече һәм урта эшкуарлыкның «ОПОРЫ РОССИИ» гомумроссия иҗтимагый оешмасына нигез салучыларның берсе, күп еллар аның Татарстан төбәк бүлеген җитәкләдегез, хәзер «ОПОРЫ РОССИИ» оешмасының беренче вице-президенты булып торасыз. Шуңа бәйле рәвештә ислам финансларын үстерүнең актуальлеге һәм кирәклеге турындагы соравым Татарстан буенча гына түгел, ә ил масштабында да.

– Нигездә барысы да Татарстанга карата әйткән сүзләргә туры килә. Рәсми статистика буенча, 2024 ел башына Россиядә 20 миллионга якын мөселман яши, бу халыкның якынча 15 процентын тәшкил итә. Аларның кайберләре акчаларын банкка салып инфляциядән саклап калу мөмкинлегеннән мәхрүм. Аларга бу мөмкинлекне бирергә кирәк.

– Сезгә уңышлар теләргә генә кала.

– Рәхмәт. Без беренче булырга телибез, гәрчә яңа юл яру һәрвакыт авырлыклар белән барса да. Ияреп баручыларга күпкә җиңелрәк. Ләкин алар өчен офык та таррак булачак бит.

ШӘФКАТЬ ҺӘМ ЮМАРТЛЫК АША ИГЕЛЕК ЭШЛӘҮ

Рөстәм Сәгъдиев,
«Амаль» Финанс Йорты* генераль директоры

Рамазан бөтен дөнья мөселманнары көтеп алган ай. Әлеге изге айда мөэминнәр ураза тота, дога кыла, яхшылык эшли, рухи яктан чистарына. Ураза тотучыларга, таңнан кичкә кадәр ач һәм сусыз торып, тулысынча чит кеше мәрхәмәтенә бәйле мохтаҗларның хәләтен үз җилкәсендә тою мөмкинлеге бирелә. Әмма, рухи чистарынудан тыш, Рамазан аенда мөселман өммәте, якыннарына һәм мохтаҗларга ярдәм итеп, үзенең шәфкатьле, намуслы һәм игелекле булуын да күрсәтә. Бу айда мөэминнәр хәйриячелек белән актив шөгыльләнә һәм мөмкин кадәр күбрәк яхшылык кылырга тырыша.

Мохтаҗларга ярдәм итүдән тыш, Рамазан аенда мөселманнар үзләренең якыннарын һәм күршеләрен дә кайгырта: аларга бүләкләр бирә, акчалата ярдәм итә, нәрсә дә булса эшләргә булыша. Мөселманнар үз тормыш-көнкүрешләренең барлык юнәлешләрендә дә намуслы, гадел, рәхимле булырга, игелекле гамәлләр кылырга омтыла. Бу рухи бергәлекне ныгытырга һәм үзара аңлашу һәм кайгыртучанлык мохите тудырырга булыша. «Амаль» Финанс Йортының эшләү дәверендә кешеләргә бушлай ярдәм күрсәтүнең клиентлар мәнфәгатеннән өстенрәк булуын раслый торган кейслар шактый. Мәсәлән, бер инвесторның өч клиентының акчалата бурычларын каплавын мисалга китерергә була...

Мөэминнәр, бу айда барлык игелекле гамәлләр өчен савап арта, дип ышана. Рамазан аенда эшләнгән теләсә нинди игелеккә Аллаһ Тәгаләнең чиксез рәхмәте иңә. Бу Раббыбызның юмартлыгын һәм кешеләрне яратуын күрсәтә. Мөселманнар, бу айда кылынган иң кечкенә генә игелекле гамәл дә гаять зур савап китерә, дип ышана. Нәкъ менә шуңа күрә дә күп кеше бу айда яхшылык эшләвен күпкә арттыра.

Бөтен ел буена да рәхим-шәфкатьле булу мөһим. Игелекле гамәлләрне аз-азлап, әмма даими кылу – иң яхшысы. Без, инде унбишенче ел базарда эшләгән компания буларак, моңа инандык. Уртак проектларга сөенә торган бик күп оешмалар, хәйрия фондлары бар. Без инде Казанда гына түгел, хәтта Татарстаннан читтә дә яхшы мәгълүм «Ярдәм» хәйрия фонды белән күптәннән хезмәттәшлек итәбез. Бергәләп «Игелек әйләнеп кайта» дип аталган инвестицияле продукт булдырдык – инвестор табышының бер өлеше ай саен үзеннән-үзе фондка күчерелә бара. Шул рәвешле кеше пассив керем дә ала, хәйриячелектә дә даими катнаша. Бу аеруча мәшгуль кешеләр өчен бигрәк тә уңайлы: аларны, дөнья мәшәкатьләренә баштанаяк чумып, иң әһәмиятлесен онытмаудан саклый.

Әйдәгез Рамазан аен яңа баскычка күтәрелү һәм рухи чистарыну өчен бер мөмкинлеккә әйләндерик. Башкаларга булышып, без әйләнә-тирәбездә якты үзгәрешләр хасил итәбез һәм җәмгыятьнең муллыгына, иминлегенә таба атлыйбыз. Һәр игелекле гамәлнең үзебезгә меңе белән кире әйләнеп кайтачагын бер дә хәтердән чыгармасак иде!

*Юридик атамасы – «Амаль» Кулланучылар җәмгыяте

Фото «Амаль» КҖнән алынды. РЕКЛАМА. «Амаль» КҖ

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Дроннар узышында **ничек** артта калмаска

Хатын-кыз бизнесы ир-атларныкыннан **нәрсә** белән аерыла

Җитәкче булу **нәрсә** ул

Балаларыбызны **ничек** әхлаклы итәргә

Автор фотосы

30 УРАДЫМ КАЗАН КАЛАСЫН...

Дмитрий Сивков

Киләчәк Уеннары. Дроннар узышы. Дөньяның төрле почмакларыннан җыелган 16 команда, чын профессионаллар көч сынаша. Бу компаниядә безнең Turbo Drones командасы – иң яше. Узыш осталары – Никита Яушев белән Георгий Беляевка 17 яшь, икесе дә Казанның Лицей – инженерлык үзәгеннән.

...Көндәшләр станында бераз аптырап калганнар. Берәү дә көндәш буларак әллә ни игътибарга алмаган Turbo Drones коптеры алдынгылар рәтендә бара. Ул аккумуляторны алыштыру өчен пит-стопка бик еш керми, тигез һәм ышанычлы оча. Бу яктан Turbo Drones коптеры хәтта тәҗрибәле кытайларныкыннан да аерала, аларның дроны әледән-әле пит-стопка туктый, ә аннары, двигательне көчәндереп, янә көндәшләр артыннан куа чыга.

Тизлеккә узышта 50 әйләнеш ясарга кирәк, көндәшләр старт бирелүгә алга ыргылган башбирмәс дрон озакламый акрыная башлар, дип өметләнә. Әмма узышның чирегe, яртысы уза, ә нәтиҗә үзгәрми. Сенсация көтеләме?

Матур төш 31 нче әйләнештә тәмамлана. Казанлыларның коптеры кинәт юкка чыга – аны уенчылар да, судьялар да күрми. Казанлылар бирешми – трассага запас дронны чыгара. Ләкин балык инде кармактан ычкынган... Финишта безнекеләр өченче урынга гына калды. Димәк, Turbo Drones чирек финалга эләкмәде. Матур төш тә әнә шулай өзелде...

БОРЫЛЫШТА КӨТКӘН БӘЛА

Turbo Drones егетләре белән очрашу өчен, командалар урнашкан ремонт зонасына юл тоттым. Гаҗәп, Георгий белән Никита кәефсез күренми.

– Әлбәттә, менә шулай килеп чыгуы үкенечле. Аның каравы, зур тәҗрибә алдык, – ди Георгий Беляев.

– Бу бит мондый дәрәҗәдәге беренче ярышлар гына. Безнең өчен барысы да алда әле, – дип җөпли иптәшен Никита Яушев.

– Егетләрнең фикерләренә мин дә кушылам, – дип яклый шәкертләрен тренер Никита Ильин. – Без бит моңарчы Россия дроннар лигасының мәгариф учреждениеләре дивизионында гына чыгыш ясадык. Ә монда

– Узышта без бер тапкыр да фигурага яки яктырткычларга эләкмәдек, аларны оптималь траектория буенча уздык, – ди тренер Никита Ильин.

Никита Яушев (сулда), Никита Ильин, Георгий Беляев.

башлангыч узышларда ук шундый көндәшләр! Ә бит чыннан да аларны уза ала идек!

– Ни булды соң?

– Башта сигнал югалды дип уйлаган идек. Кичә 20 әйләнешле башлангыч узышта мондый хәл булган иде инде, сүз уңаеннан, без анда җиңдек. Ләкин бу юлы дроныбыз аккумуляторсыз калган булып чыкты: резина белән пластик салкында шатырдап ката, шунлыктан батарея борылышта төшеп киткән. Ә дрон әле генә пит-стоптан чыккан иде, аккумулятор тулысынча корылган. Андый чакта көндәшләрне артта калдырып кына китәсе. Икенче коптерны чыгарырга туры килде. Җитди узышу турында инде сүз дә була алмый иде. Көндәшләрнең хата җибәрүенә генә өметләнәсе калды, ләкин алар бер дә ялгышмады...

КЫЙММӘТЛЕ УЕНЧЫК

– Ә сез шундый профессионаллар җыелган ярышка ничек килеп эләктегез? Ярышларны уздырган хуҗа ил вәкилләре буларак, уайлд кард (стандарт таләпләргә карамый, ярышларда катнашырга чакыру. – Ред.) бирделәрме?

– Юк, барысы да гадел булды. Мәскәүдә узган сайлап алу ярышларында өченче килдек һәм катнашу хокукы алдык.

– Бу очракта җиңелү күпмегә төшә? 1/4 финалга чыккан өчен приз акчалары күбрәк булыр идеме?

– Дөресен әйткәндә, бүгенге чыгышыбыз өчен күпме алачагыбызны белмим дә. Приз акчалары әзерләнүгә тотылган чыгымнарны каплар дип өметләнәм. Әйтергә кирәк, дроннар узышы бер дә арзан нәрсә түгел. Балаларына ярдәм иткән өчен ата-аналарга рәхмәт. Сүз уңаеннан, әтиләр монда, бүген безнең янда.

– Уеннарга әзерлек күпмегә төште?

– Бер дрон ясау өчен генә дә уртача 45 мең сум кирәк. Әле тагын пультка – 30 мең, күзлеккә – 80 мең тирәсе. Шуңа өстәп ангар арендасы, аны тренировкалар өчен җиһазлау... Шактый күп җыела.

– Нигә ангарда?

– Ачык һавада дрон очыртуны тыйганнан соң, шунда күчәргә туры килде. Ләкин егетләргә бу хәтта файдага булды: кысан урыннарда тренировкалар аларга төрле киртәләрне курыкмыйча узарга өйрәнергә булышты. Узышта без бер тапкыр да фигурага яки яктырткычларга эләкмәдек, аларны оптималь траектория буенча уздык. Шуңа исәп тоттык та.

ДРОННАР ЯРЫШЫ – ҖИТДИ ШӨГЫЛЬ

– Тренер булудан тыш, сез әле...

– ...Лицей директорының технологик белем бирү буенча урынбасары, программалаштыру, робот техникасы, интернет-технологияләр белән бәйле бөтен дәресләрне алып барам.

– Үзегезнең дә егетләр белән бергә ярышка чыгу теләге юкмы соң?

– Ничек булмасын, ди?! Без бит алар белән бергә өч ел элек иң төптән өйрәнә башладык. Беренче елны мин технология белән генә шөгыльләндем. Ә бер елдан соң, егетләр кайда нәрсә икәнен төшенгәч, үзем дә оча башладым. Башка команда өчен чыгыш ясыйм, дөрес, әлегә Никита белән Георгийга җиңеләбез. Гомумән, безнең лицейда көндәшлек зур. Узышларда гына да 17 кеше чыгыш ясый, өстәвенә V-VIII сыйныф укучылары шөгыльләнә торган түгәрәк эшли.

– Яшьләргә бу юнәлеш якын.

– Анысы шулай. Тик моның белән җитди шөгыльләнергә һәркем дә әзер түгел. Дронрейсинг ул узышу гына түгел, үзеңне тулысынча шуңа багышлау таләп ителә. Мәсәлән, син җәй көне беркая да ялга китә алмыйсың, чөнки ул әзерлек эшенең иң кызган чагы – атнага өчәр тренировка була. Әмма шөгыльләнергә теләүчеләр җитәрлек. Ә безнең команда Киләчәк Уеннарында катнашканнан соң, андыйлар тагын да күбрәк булыр дип уйлыйм.

Бер дрон ясау гына да уртача 45 мең сумга төшә.

Иң мөһиме – катнашу.

БАРЫСЫ ДА ГАРМОНИЯЛЕ БУЛЫРГА ТИЕШ

«Бу сиңа нәрсәгә кирәк инде, әнә балаларыңны кара!», «Акчаны ир-ат эшләргә тиеш», «Сиңа нәрсә, ирең акча бирмиме әллә?», «Әгәр күңелсез икән, спа-салонга бар, юләрләнеп йөрмә!», «Эшләргә теләсәң, офиска урнаш», «Хатын-кыз гаилә, кухня, балалар өчен!»...

Хөрмәтле ханымнар үзләренә карата мондый сүзләрне бер генә тапкыр ишетмәгәндер, әмма бу гына аларны туктата алмый. Шуңа күрә бүген без Татарстанда төрледән-төрле «хатын-кыз» бизнесларын күрәбез дә. Алар һәрвакыт чиста хатын-кыз шөгыле генә булмаска мөмкин – тик барыбер чиста ир-атларныкыннан кечкенә генә аерма бар: «Барысы да гармонияле булырга тиеш!» – дип саный эшкуар ханымнар.

Бүген сүзебез акыллы һәм гүзәл ханымнар, аларның гармонияле бизнесы һәм, әлбәттә, башка шөгыльләре турында.

ВЕЛОУЗЫШЛАРДА ХИСАП – ВАТТЛАРДА

Дмитрий Сивков

Түбән ягындагы татар авылында туып-үскән кызның «Их, велосипедым булсын иде» дигән теләге аны кайчандыр велоспорт секциясенә алып килгән. Нәтиҗәдә, әнә шулай педальләр әйләндерә-әйләндерә, ул Россия җыелма командасына эләккән, юниорлар арасында дөнья һәм Европа чемпионнары титулларына ирешкән һәм, ниһаять, Киләчәк Уеннарына барып җиткән. Дөрес, моның өчен аңа «испан» кызына әйләнергә туры килгән.

Агенты, шалтыратып, Киләчәк Уеннарында катнашырга тәкъдим иткәч, Инна Абайзуллина сүзнең нәрсә турында барганын тиз генә аңлап та бетерми. Агентының физик спортны һәм цифрлы мохитне берләштергән бәйгеләрнең яңа төрле ярышлар дип аңлатырга азаплануы да әллә ни кызыксыну уятмый аңарда. Шулай да Инна ярышлар турында төгәлрәк белү ниятеннән сорап куя:

– Ә ул уеннар кайда узачак соң?

– Казанда.

Шуннан соң кыз ике дә уйламый ризалаша:

– Алыгыз командага!

Шунысын да әйтеп китү урынлы булыр: агент Швейцариядән шалтырата, кыз Словакиядән җавап бирә, ә испан командасы составында катнашу турында әңгәмә рус телендә бара. Замана спорты әнә шундый кызык хәлләр китереп чыгара.

Бу кара чәчле, коңгырт күзле, кечкенә буйлы кызны сәхнәдә милли киемдә күз алдына китерү бик җиңел, әмма ул тормышын велокомбинезон һәм велотрек белән бәйләгән. Юниорлар арасында тректа велоузышларның олимпия төрләрендә Европа һәм дөнья чемпионы булуы бу адымының дөреслеген раслый кебек.

Тышкы буй-сынының шөгыленә туры килмәвеннән бигрәк, Инна Абайзуллинаның «география»се тагын да ныграк гаҗәпләндерә. Россия җыелма командасы әгъзасы хәзерге вакытта илебезнең Marathon-Tula һәм Португалиянең Matos Mobiliti профессиональ командалары өчен чыгыш ясый, ә Казанда Team Spain дип аталган испан командасы данын яклый.

Автор фотосы

ДЖОЙСТИК УРЫНЫНА – ПЕДАЛЬЛӘР

Виртуаль велоузышларда джойстик белән уйнамыйлар, ә велостанокта чын педаль әйләндерәләр, трек яки шоссе сурәте мониторларга чыгарыла: аның берсе – шәхси дисплей, спортчы күз алдында, икенчесе – зурысы – җанатарлар өчен. Сүз уңаеннан, станокларда – спортчыларның узышларга йөри торган шәхси велобайклары, аларның арткы тәгәрмәче генә салдырылган.

Инна белән дүрт сынауның беренчесе – 1 километрга вакытка индивидуаль узыштан соң әңгәмә кора алдык.

– Син шактый дәрәҗәле спортчы. Мөгаен, үзеңне потенциаль җиңүчеләр исемлегендә күрәсеңдер?

– Әлбәттә, җиңәсе килә. Әмма монда профессионаллар шактый, күбесе белән танышмын да. Marathon-Tula командасыннан дус кызларым Диана Климова һәм Гөлназ Хатунцева белән аралашу мөмкинлегенә бик сөендем. Сүз уңаеннан, Гөлназ – Олимпия уеннары призёры. Ләкин титуллар монда бернинди роль уйнамый. Һәм шул ук һәвәскәрләр каршында да нинди дә аерым бер өстенлекләребез юк. Киресенчәдер әле, мөгаен...

– Алай да булырга мөмкинмени?

– Гадәти узышлар белән чагыштырганда, бу ярышларның үз үзенчәлеге, үз тактикасы бар. Фиджитал-велосипедчылар тренажёрларга яхшырак җайлашкан, мондый узышларда тәҗрибә туплаган, аларның үзенчәлеге һәм тактикасы белән таныш. Өстәвенә, профессионалларны даими рәвештә допингка тикшереп торалар, һәвәскәрләрдә андый нәрсә юк. Шулай булгач, виртуаль узышларда аларның җиңүе сирәк күренеш түгел.

ТИЗЛЕКНЕ ВАТТ БЕЛӘН ҮЛЧИЛӘР

– Ә синең бу спорт төрендә нинди дә булса тәҗрибәң бар идеме соң?

– Бөтенләй юк. Эш барышында барысын да өйрәнәм. Менә беренче коймак төерле булып чыкты. Көчне дөрес бүлмәдем. Дүрт әйләнешнең беренчесен спринтер кебек тулы куәткә әйләндердем, аннары бераз хәлем китте, финишка кадәр шул ук ваттларны тотып тору бик кыен булды.

– Виртуаль велоспортта тизлекне ваттларда үлчиләрмени?

– Педальләрне никадәр көчлерәк әйләндерсәң, шулкадәр зуррак егәрлек бирәсең, димәк, тизлек тә югарырак. Шулай булгач, ваттлар – бик мөһим күрсәткеч. Спринтта Россия рекордчысы Алина Лысенко хәзер менә стартта 1100 ватт бирде, чит ил егетләре авызларын ачып карап торды. Янәсе, бу мөмкин хәл түгел, ул бит кыз кеше!?

– Ә трассада синең егәрлегең никадәр?

– Уртача 250–300 ватт. Егәрлеккә гәүдә авырлыгы да йогынты ясый. Минем бөтен авырлыгым 54 кг, һәм миңа, әйтик, 60 кг лыларга караганда, ваттларны арттыру кыенрак. Күргәнегезчә, бу ярышның нечкәлекләре күп.

ОЛЫ АКЪЯР – ПИТЕР – СЛОВАКИЯ

– Мин Төмәннән 30 чакрым ераклыкта урнашкан Олы Акъяр авылыннан. Дүртенче сыйныфка кадәр велоспорт турында берни дә белми идем. Аннары күрше авылда велосипед спорты секциясе барлыгы турында әйттеләр. Ул чагында минем велосипедым юк иде. Менә шуңа күрә язылдым да, – дип елмаеп искә ала Инна.

Ике елдан соң аңа әти-әнисе велосипед сатып ала, ләкин кызлары педальләрне шулкадәр шәп әйләндерә ки, аны инде туктату мөмкин булмый. 14 яшендә Инна Санкт-Петербургта Александр Кузнецовның спорт интернатына элләгә. Велоспортта Александр Анатольевичны фигуралы шуудагы Мишин яисә хоккейдагы Тихонов белән чагыштырырга була: ул утыз ел СССР, БДБ һәм Россия

Ярыш бара.

җыелма командаларын җитәкли, бик күп Олимпия һәм дөнья чемпионнарын әзерли. Менә Инна да дөнья чемпионы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә, әлегә юниорлар арасында.

Дөрес, хәзер кыз Нева буе каласыннан Словакиягә күчеп киткән.

КҮҢЕЛЕНДӘ ТАТАР КЫЗЫ УЛ

Үзе әйтүенчә, Европага күптән күченеп китәргә теләгән булган ул. Сәбәп ниндидер көнкүреш мәсьәләләре белән бәйле түгел, Россиядә шоссе велоспорты белән шөгыльләнү өчен яхшы шартлар тудырылмаган, ә кызның трек узышлары белән генә чикләнеп калмыйча, нәкъ менә шул юнәлештә үсәсе килә икән.

– Чит илдә моның өчен климат шартлары да яхшырак, түләү ягы әйбәт дөнья туры командалары да күп. Ике ел элек словак милләтеннән бер егет белән очраша башладым. Ул да велоузышчы. Һәм менә инде ике ел мин Словакиядә яшим, Португалия командасы өчен чыгыш ясыйм, ләкин Россия чемпионатларында да катнашам. Туганнарымның хәлен белешер, әбием пешерә торган пәрәмәчләремне һәм бишбармакны авыз итәр өчен, ярты елга бер тапкыр берәр атнага туган ягыма кайтып килергә тырышам.

– Балачагыңны – Көнчыгыш Себердә, яшүсмер вакытыңны Санкт-Петербургта үткәргәнсең, хәзер Европада гомер кичерәсең – машина белән Венага ике сәгатьтә барып җитә аласың... Күңелеңдә үзеңне кем итеп тоясың?

– Мөгаен, аз-азлап һәркайсын сеңдергәнмендер. Әмма, әлбәттә, үземне татар итеп тә тоям. Милләтем белән генә түгел, мәдәни яктан да. Мин бит татар авылында үстем, өйдә татарча сөйләштек, мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыдык. Ә менә тарихи ватан – Казанны күптән күрергә хыялланган булсам да, шушы Киләчәк Уеннарында беренче тапкыр гына килүем. Бик матур, җылы тәэсирләр кала: шәһәрдән дә, Кремльдән дә, бигрәк тә Кол Шәриф мәчетеннән. Кызганыч, барысын да карап чыгарга вакыт ягы кысан иде, ләкин, һичшиксез, моның өчен бирегә киләчәкмен әле.

ҖИҢЕЛҮ АЧЫСЫ, УҢЫШ МИЗГЕЛЛӘРЕ...

Инна шат күңелле һәм күтәренке кәефле кеше. Шулай да без аралашкан көнне йөзендә үкенеч чагылып үтте кебек. Бу икенче этаптан соң булды. Анда җиңелгән узышчылар төшеп кала бара, ә Инна ярышта унынчы урын алды.

– Мин тизлекне көндәшләремнеке кебек үк диярлек көйләп куйдым, ләкин алар педальләрне шактый иркен әйләндерде, ә мин аларны тизәйтә алмадым, әйтерсең, тигез трек буйлап түгел, рельеф режимын кушкандагы кебек, тауга мендем. Ник алай икәнен аңламадым. Судьялар болай булырга тиеш түгел, диде. Әмма нәкъ шулай иде бит! – диде Инна, хисләрен яшермичә.

Протест бирүнең мәгънәсе юк иде. Илебездә эшләнгән виртуаль велоузыш программасы Киләчәк Уеннарында тест режимында сынау уза, һәм кайбер кимчелекләр күзәтелергә мөмкин, әмма аларга бәйле дәгъвалар кабул ителмәячәк, дип кисәтеп куйган оештыручылар. Хәер, Инна өчен ярышларда уңышсыз кара полоса шуның белән тәмамланды. Соңгы ике этап: скретчта – тауда бер финиш белән 10 км га, критериумда – 2 км саен арадаш финишлар белән 30 км га узышта татар кызы икенче урын алды. Ләкин бу инде командага призёрлар санына эләгергә ярдәм итмәде, чөнки җиңү-

Яхшырак урынга өмет иткән идем.

челәр барлык этапларда җыелган очколарның гомуми саны буенча билгеләнә.

– Без Мәскәү егете Евгений Тихонин белән болай да команданы 7 нче урыннан 4 нче урынга тартып чыгардык, әгәр испаннар бераз тырышкан булса, һичшиксез призёрлар исемлегенә керә идек, – дип бәя бирде ярыш нәтиҗәләренә Инна бераз үкенгәндәй.

Уеннарда шәхси беренчелек булса, татар кызы бүләкләрсез калмас иде, аның активында – 175 балл. Бу – ярышта барлык катнашучылар арасында өченче нәтиҗә, ә хатын-кызлар арасында – икенче күрсәткеч. Сүз уңаеннан, ике испанлы икесенә бергә нибары 51 балл җыйган.

P.S. УРЫНЫНА

Беренче тапкыр уздырылган Киләчәк Уеннарындагы һичбер сикәлтә, һичбер борылыш бу вакыйга белән бәйле гомуми тәэсирне боза алмады.

Без Инна белән ул инде Словакиягә барып җиткән көнне үк шалтыратыштык. Кызның күтәренке кәефе тавышына чыккан иде:

– Кәефем яхшы. Уеннарны оештыру ягыннан барыбыз да канәгать калдык: юл хакы, яшәү, иминиятләштерү – кабул итүче тараф хисабына булды. Һәм акчалата призлар да начар түгел, без, мәсәлән, 4 нче урын өчен 3 мең доллар алдык. Яхшырак та булырга мөмкин иде, әлбәттә. Димәк, башка юлы булдырачакбыз.

Чишенү бүлмәсендә сөйләшү.

Фиништан соң.

редакция кухнясы

ЮЛИЯ ЛУНИНАДАН САРЫК ШУЛПАСЫ

Татьяна Вафина

Югары технологияләр ничек кенә алга китмәсен, аларны үстерүчеләрнең традицион милли ашларны яратуы үзгәрешсез кала бирә.

Бүген «Татарстан»ның «Редакция кухнясы»нда «Информационные Бизнес Решения» ҖЧҖ уңышлы IT-бизнесы хуҗасы Юлия Лунина нәкъ менә шундый ризык – әлегә кадәр беркемне дә битараф калдыра алмаган шулпа әзерли.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- Сарык ите – 300 г;
- Суган – 1 данә;
- Кишер – 1 данә;
- Бәрәңге – 200 г;
- Татлы борыч – 1 данә;
- Черри помидорлары – 1 ботак;
- Яшел тәмләткеч үләннәр – 1 бәйләм;
- Тәменчә тоз, борыч.

ИКМӘК ЗАВОДЫНДАГЫ IT-БҮЛЕК

Сөйкемле, гүзәл хатын-кызлар матурлыгы белән генә түгел, бик акыллы булуы белән дә шаккатыра ала. Юлия Лунина Казанга 2000 елда килә, университетның югары математика һәм кибернетика факультетын тәмамлагач, үзенең гомерен мәгълүмати технологияләргә багышлый.

2005 ел азагында ул инде 7 нче икмәк пешерү заводының хисап системаларын автоматлаштыру белән шөгыльләнә торган IT-бүлеген җитәкли. Аннары «Ак барс» холдинг компаниясе белән Казан авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә IT-хисап юнәлешен үстерә. Биш ел буе «Домо» компаниясендә IT-технологияләр директоры булып эшли. Һәм, тәҗрибә туплап, 2010 елда үз бизнесына керешә.

Әмма яңа эшкә баштанаяк кереп чумса да, ул йорт җанлы булып кала – аның өчен гаилә беренче урында тора. Иң мөһиме исә – әлеге гаиләне тәмле ашату. IBR компаниясе хуҗасы аш-су әзерләүгә дә бик оста.

Фото: Алсу Шакирова. РЕКЛАМА

АШ-СУГА КАГЫЛЫШЛЫ КИҢӘШЛӘР

Гомер буена әллә нинди киңәшләр ишетергә туры килә. Мин барысын да игътибар белән тыңлыйм – киргә чыгуы бар бит. Мәсәлән, бүген ишеткәннәрдән:

ӘБИЕМ КИҢӘШЕ: «Тозны кашык белән түгел, кул белән саласың икән, беркайчан да артык тозлы булмаячак». Шунлыктан бернинди кашык та кирәкми!

ДУС КЫЗЫМ КИҢӘШЕ: «Суганны бөҗралап түгел, кыяклап турарга кирәк. Шулай матуррак була». Кыяклап кисәбез.

МИНЕМ КИҢӘШЕМ: «Гадәттә мин кишерне, матур булсын өчен, махсус сырлы пычак белән турыйм. Ризык матур булганда, тәмлерәк тә тоела».

– Сарык итен башта кыздырып алырга кирәк, – ди ул. – Шулай иткәндә, күбеге азрак, ә шулпа тәмлерәк булачак!

ХОСУСЫЙ IT-БИЗНЕС

Кунагыбызның аш-суга шулкадәр оста булуына гаҗәпләнеп, әллә бизнесы кулинария белән дә бәйлеме, дип кызыксынабыз.

– Әгәр заказ бирүче кулинариягә бәйле булса, бер дә баш тартмаячакбыз, – дип көлә ул. – Без IT-интеграторлар буларак эшлибез, комплекслы хезмәт күрсәтәбез, IBR классындагы системалар кертәбез, предприятиеләргә ярдәм итәбез. Безнең хәтта шундый предприятиеләребез дә бар – аларның үзләренең IT-штаты бөтенләй юк, һәм алар үзләренең эшләрен IT-тәэмин ителешне тулысынча безгә аутсорсингка бирәләр. Анда без IT-консалтинг ролендә дә, предприятиене автоматлаштыру системаларын үстерү буенча IT-партнер ролендә дә хезмәт куябыз.

Безгә инде IT-системаларны көйләүне генә түгел, бәлки аларның һәм бизнес-процессларның үсеш стратегиясен дә ышанып тапшыралар – безнең «Информационные Бизнес Решения» компаниясе белгечләре җитештерүдәге, складтагы, финанс һәм регламент хисабын автоматлаштыру тармагындагы проектларны гамәлгә кертүдә гаять зур тәҗрибәгә ия.

IT-ГАИЛӘ

– Компания актив үсә башлагач, ирем миңа ярдәмгә килде, – дип дәвам итә Юлия Владимировна. – Без партнерлар. Бизнесны бергәләп үстерәбез, бер-беребезне баетабыз – мин күбрәк консалтинг, идарә системалары өчен, ул исә инфраструктура проектлары өчен җаваплы.

Сергей – эштә генераль директор, өйдә исә – яраткан ир һәм эти. Аның белән ике улыбызны үстерәбез: олысы Маркка 14 яшь, ул инженерлык лицеенда укый; кечесе Гордей – 29 нчы гимназиядә. Хәзер үк малайларның математика фәннәренә сәләте күренә, шунлыктан әлеге юнәлешне мөмкин кадәр үстерергә тырышачакбыз.

– Баланың буе үссен өчен кишер ашаталар, диләр. Ә менә яшь организм төгәл фәннәргә тартылсын өчен нәрсә ашатырга кирәк икән? Әллә бу геннарга гына бәйлеме?

– Тиешле мохит тудырырга кирәк. Күп нәрсә бала үскән мохиткә бәйле. Физиклар белән лирикларның рационы исә әллә ни аерылмыйдыр, дип уйлыйм.

Якшәмбе көнне улларым этиләре белән ашарга пешерә. Үзләре шулай хәл итте – бу көнне кухня аларныкы гына. Мин исә шимбә көнне берәр тәмле ризык әзерлим. Атна уртасында исә алар көн буе мәктәптә, шунда тукланалар. Кич ит, балыктан җиңелчә генә кичке аш әзерлибез... Күп нәрсә дөрес туклануга бәйле. Гади ашамлыкларны файдаланырга һәм аларны экологик кибетләрдән сатып алырга тырышабыз.

ЧӘЙ ЭЧӘРГӘ – IT-КӘНФИТ

– Без эштә дә хезмәткәрләребезгә уңайлы мохит тудырырга тырышабыз – компаниядә белгечләрнең күпчелеге 20-30 яшьтә генә бит. Барлыгы исә 70 тән артык кеше эшли. Офиста ашханә бар, алар ризыкны китертә яки үзләре алып килгәнне җылытып ашый ала. Кәнфит-шоколадтан бер дә өзмибез – акыл эшчәнлегенең даими сыйлануны таләп итүен яхшы аңлыйбыз. Барысы да тәм-том белән рәхәтләнеп чәй-каһвә эчә ала. Шул рәвешле эштә уңайлы шартлар тудырыла.

IT-БАШ МИЕ НИШЛИ БЕЛӘ?

– IBR компаниясенең яшь хезмәткәрләре нәрсәләр эшли белә?

– Без Татарстандагы төбәк компаниясе буларак мәгълүм. Күп көндәшләребезнең төп офислары Мәскәүдә урнашкан, ә без биредә – Казанда эшлибез. Мәскәү компанияләре кебек үк хезмәтләр күрсәтсәк тә, бәяне үз төбәгебезгә хас чикләрдән арттырмыйбыз. Беренче чиратта IBR КАМАЗ, ТАИФ, дары заводы, Ак Барс Девеломпент кебек үзебезнең Татарстан компанияләренә ярдәм итә. Безнең кадеребез дә шунда: үзебезнең менталитетны яхшы аңлыйбыз һәм, предприятиеләргә безнең яңа продуктлар килгәч, алар киләчәктә мөстәкыйль эшли һәм үсә алсын өчен тырышабыз. Персоналны IT-технологияләргә өйрәтәбез.

ЯШЬ IT-БУЫН ҮСТЕРӘБЕЗ

– Хәзер югары уку йортлары белән актив хезмәттәшлек итәбез. Безне халыкның IT-белемен арттыру буенча цифрлаштыру программасына чакырдылар, мондый программалар барлык вузларда да өйрәтелә башлый. Безнең экспертларыбыз студентларны укыта. Әгәр былтыр цифрлаштыру программасы буенча IBR компаниясе аша 450 студент укып чыкса, быел инде аларның саны өч меңнән арта.

Без студентлар белән чын кейсларны тикшерәбез – бу мобиль технологияләр, хисап системалары булырга мөмкин... Уку азагында студентлар, нинди продукт барлыкка килүен күрсәтеп, йомгаклау эше яза. Проектка тулысынча кереп китү техникасыннан да файдаланабыз – бу командалар оешсын, теләсә кайсы студент IT-компаниядә эш нинди була икәнен аңласын өчен кирәк. Һәркем үзенә кызыклы роль сайлап ала: җитәкче, уйлап табучы яки аналитик. Быел Россиядәге конкурсларда катнашырга ниятлибез – студентларыбыз үзләренең безнең белән бергә эшләгән продуктларын яклый алсын өчен тырышабыз. КФУ, КМТТУ-КАИ белән берлектә стажировкалар да үткәрәбез... Бурыч – шәкертләрне IT-мохиткә чумдыру, яшь белгечләрне проектны дөрес технологияләр ярдәмендә ясарга өйрәтү һәм кадрлар әзерләү – бүген IT-тармакта кадрлар кытлыгы сизелгәнгә, яшьләрне моңа җәлеп итү һичшиксез кирәк.

IT-БИЗНЕС-ЧИШЕЛЕШЛӘР

– Шулкадәр катлаулы һәм җитди бизнес-чишелешләр ничек туа?

– Безнең компаниянең бурычы – «Барлык катлаулы нәрсә – бик гади!» Менә бу шулпа кебек. Иң гади ризыклар җыелмасы, бик гади рецепт, әмма һәр хуҗабикә аны барыбер үзенчә пешерә, нәтиҗәдә бик тәмле килеп чыга. Катлаулы түгел, әмма һәрвакыт төрле.

Хатын-кыз өчен иң мөһиме нәрсә? Барысын да бик яхшы эшләү теләге. Мин реаль проектлардан, кемгәдер белемемне тапшырудан, нинди дер компания, җәмгыять өчен файдалы эш эшләүдән канәгатьләнү алам. Үз хезмәт җимешләре җәмгыятькә кирәкле һәм файдалы икәнен күргән һәрбер хатын-кызның, нәрсә белән генә шөгыльләнмәсен, эше гөрләп барачак, ул һәр эштә якыннарының хуплавын тоячак.

Безнең компания тәкъдим иткән барлык бизнес-чишелешләрне чын профессионаллар һәм экспертлар командасы эшләвен дә хәтердән чыгармау мөһим: автоматлаштыру проектлары белән идарә итү һәм аларны гамәлгә кертү тармагы белгечләре, инфраструктура һәм гамәли системалар архитекторлары, мөгаллимнәр һәм аналитиклар, зур төзелеш һәм җитештерү предприятиеләре һәм холдингларын автоматлаштыру белән идарә итү тәҗрибәсенә ия җитәкчеләр.

Шунлыктан безнең компаниянең теләсә кайсы предприятиенең комплекслы идарә системасын төзүгә керткән өлеше һәрвакыт файдалы, ул карарларны вакытында кабул итүне, бизнес-процессларның гаделлеген, эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүне тәэмин итә.

Төзелештәге идарәдән башлап, сәнәгать холдингы белән идарә итүгә кадәр – теләсә кайсы тармактагы теләсә нинди катлаулылыктагы проектларны безнең белән гамәлгә ашырып була. Аерым бизнес-процессларны комплекслы автоматлаштыру өчен мобиль кушымталар эшләүдән алып, тулы бер предприятиенең менеджмент системасын цифрлы трансформацияләүгә кадәр.

IT-ПОРТФОЛИО

– Сезнең портфолиода нинди проектлар бар инде?

– 13 ел эчендә без теләсә кайсы бизнеска яхшырак эшләргә булыша торган 500 проектны гамәлгә ашырдык. Мәсәлән, «Ремдизель» АҖ. Машина төзелеше һәм приборлар төзелешенә бәйле проект «1С Ел проекты 2021-2022» конкурсында җиңде.

Ә «Ак Барс Строй» Идел буе төзелеш компаниясендә (ПСК) безнең ярдәм белән түбәндәге

– Мин пешеренергә бик яратам. Бигрәк тә гаиләм яраткан ризыкларны пешерергә. Моңа мине әбием өйрәтте. Ул ашханәдә бригадир булып эшләдә, бөтен нәрсәне пешерә белә иде.

1 Пешерәбез

2 Тоз салабыз

3 Чистартабыз

4 Чистартабыз

5 Турыйбыз

6 Кыздырабыз

7 Турыйбыз

8 Өстибез

9 Пешерәбез

10 Өстибез



11 Турыйбыз

12 Өстибез

13 Турыйбыз

процесслар 1С ERP УСО да автоматлаштырылды: төзелеш, матди-техник тәэминат, механизмнар белән идарә итү, казначылык, бюджет төзү, финанс планлаштыруы, регламентланган хисап, мәгълүматларны холдингның АБД 1С системасына кертү.

2022-2023 елларның глобаль проекты – «Кнорр-Бремзе КАМА» ҖЧҖ (КАМАЗлар өчен тормоз системаларын эшләү һәм җитештерү). 1С ERP, 1С ДО һәм 1С ЗУП продуктларыннан файдаланып, автоматлаштырылды: планлаштыру, сәүдә, сатып алу, мобиль эш урыны белән җитештерү логистикасы, склад логистикасы, финанс һәм регламентланган хисап, Финанс хисабы халыкара стандартлары (МСФО), бюджет төзү.

«1С Ел проекты 2022-2023» конкурсында «РФнең Идел буе федераль округындагы иң яхшы проект» номинациясендә җиңгән «Алкоторг» ҖЧҖ («Татспиртпром» АҖ КТ) проекты нәтиҗәләре: төп процессларны хисапка алу да, җитештерүче заводлардан продукция сатып алу да, продукцияне экспортка чыгару да, йөкләрне күчерү белән идарә итү дә, планлаштыру да, дебиторлык бурычлары белән идарә итү дә, акчаны сәүдә юнәлешләре буенча һәм клиентларга роботлаштырылган бүлү дә... Һәм тагын бик күп нәрсә.

Портфолиода шулай ук Казан мэриясе өчен IT-сервислар белән идарә итү системасын кертү дә, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты өчен активлар белән идарә итү процессларын автоматлаштыру да бар.

Клиентларыбызның 80 проценты безгә кабат мөрәҗәгать итә. Ә бит без клиентлар саны артыннан кумыйбыз. Безгә күрсәтә торган хезмәтләребезнең сыйфаты һәм үзебезнең абруй гына мөһим.

IT-КОТКАРУЧЫЛАР

– Һәм шуңа игътибар итегез: болар барысы да агрессив рекламадан башка эшләнә. Гәрчә безнең проектларыбыз киң колачлы булса да, нигездә, безнең турыда кемнәндер ишетеп кенә беләләр. Без бик катлаулы проектлар ясыйбыз, еш кына безне проектларны коткару өчен чакыралар. Чөнки без алынабыз икән, эшне ахырына чаклы җиткерәбез. Һәр проектның үзенең үзенчәлекләре бар, бу күнегелгән эш мантыйгын үзгәртүне таләп итә. Трансформациядән башка проектны эшләтеп җибәрүе кыен. Фикерләрен бераз башкачага әйләндерү өчен, кешеләрне дә үзгәртергә туры килә. Алайса проектны гамәлгә кертеп булмаячак. Һәр проектны тормышка ашыру 7-9 айга сузыла. Без төгәл эшлибез, вакытны юри сузмыйбыз. Эшләтеп җибәрәбез, аннары үстерәбез. Заказчыга барлык технологияләрне дә тапшырабыз, өйрәтәбез.

УНИВЕРСАЛЬ IT-СОЛДАТ

– Мондый төрле пландагы «коткаручыларны» кайдан аласыз? Әллә алар сезнең барысы да универсальме?

– Бар тармакта да белемле булган универсаль IT-белгеч булмый шул. Без белгечләребезне төрле юнәлешләр буенча бүләбез: финанс секторы, склад логистикасы, җитештерү логистикасы, транспорт. Һәм һәр проектка кирәкле белгечләрне билгеләргә тырышабыз. Шунлыктан безгә төрле тармак вәкилләре мөрәҗәгать итә дә: бу җитештерү дә, төзелеш тә, ретейл да, склад һәм транспорт логистикасы да. Эшебезнең үзенчәлеге шунда ки, без бизнесның теләсә кайсы төре өчен автоматлаштыруда гына түгел, бәлки компаниянең бизнес-процесслары логикасын көйләүдә дә файдалы була алабыз.

IT-ӨЙРӘНЧЕК

Сөйләшә-сөйләшә кунагыбызның ашны өлгертүен сизми дә калганбыз – ул матур итеп кишер белән суганны да турады, аларны кыздырып шулпага да салды һәм инде менә бүлеп тә бирде – рәхим итеп сыйланыгыз!

– Вакытыгыз шундый тыгыз булгач, пешеренергә ничек өлгерәсез?

– Мин пешеренергә бик яратам. Бигрәк тә гаиләм яраткан ризыкларны пешерергә. Моңа мине әбием өйрәтте. Ул ашханәдә бригадир булып эшләде, бөтен нәрсәне пешерә белә иде. Ашханәдә еш кына заказлы мәҗлесләр дә уздырыла, әбием мине булышырга алып бара. Өйдә бөтен бәйрәмнәргә ул бик матур табын кора, мин гел аның янында кайнаша идем. Кечтән өйдән алып китә дә, икәү көне буе рәхәтләнеп әзерлибез. Шунлыктан ризык әзерләүнең миңа бер авырлыгы да юк.

Үз гаиләсен яраткан һәр хуҗабикә һәрчак тәмле итеп ашарга пешерергә тырыша, дип саныйм.

Мин 23 яшемдә кияүгә чыктым, иремә 27 яшь иде. Билгеле инде, шундук белгәннәрем белән мактанасым килде. Көненә өчәр тапкыр пешеренә башладым: пирог, бәлеш, өчпочмак – татар халык ашларын бик яратам, барысын да сөенә-сөенә пешерәм. Икебез дә киемнәребезгә сыймый башлагач, дөрес туклануга күчәргә туры килде. Шулай 19 ел буена яшибез инде...

ГАИЛӘ IT-БӘХЕТЕ СЕРЕ

– Ягъни сез инде 19 ел өйдә дә, эштә дә гел бергә. Бәлки, гаилә бәхетенең сере нәкъ менә шулай гел бергә булудадыр?

– Бу безнең шулай килеп чыкты. Без гаиләдә бер-беребезне тулыландырабыз, рухландырабыз, һәм бу безгә шундый зур энергия бирә, үсеш өчен этәргеч булып тора.

Әмма, минемчә, гаиләдә иң мөһиме – үзара аңлашып яшәү. Бүген һәркем үзенең шәхси кырын сакларга омтыла. Әмма бөтен кеше синең кубызыңа биергә тиеш түгел. Гаилә – һәрвакыт үзара аңлашу, юл куя белү дә ул. Үзеңне генә түгел, партнерыңны да ишетә белү мөһим. Хәләл җефетең өчен дә уңайлы мохит тудыру кирәк. Ирең өчен, балаларың өчен. Аларның берсенә дә минем янымда уңайсыз булмаска тиеш. Якыннарыбыз хуплавын тойганда, безгә канатлар үсә бит. Бу гаиләдә иң мөһиме.

– Без гаиләдә бер-беребезне тулыландырабыз, рухландырабыз, һәм бу безгә шундый зур энергия бирә, үсеш өчен этәргеч булып тора.

ИКЕ IT-КАПИТАН

– Сез эштә дә, гаиләдә дә гел бергә, мавыгуларыгыз да уртакмы?

– Хоббига килсәк... Балачагымда мине чигәргә дә өйрәттеләр әле. Хатын-кыз белергә тиешле нәрсәләрнең барысын да эшли беләм мин. Хәзер җырлыйм, шуннан энергия алам. Миңа күп һәм дөрес сөйләргә, күп халык алдында еш чыгыш ясарга туры килә, шуңа тавышымны шулай чыныктырам. Бу – минем шәхси мавыгуым.

Ирем белән уртагы да бар – без икәү Африка тангосы биибез. Җәен исә бакчада кайнашырга яратабыз, бер-ике түтәл утыртабыз да, шуңа сөенәбез. Артыгы кирәкми.

Тагын бергәләп сәяхәт итәргә яратабыз – мәсәлән, икәү генә бер-ике көнгә Петербургка чыгып китә алабыз. Былтыр исә икәү бергә капитанлыкка укыдык. Төркиядәге шкиперлар мәктәбендә яхта белән идарә итәргә өйрәндек.

ХАТЫН-КЫЗЛАРЧА БИЗНЕС – РУХЛАНДЫРГЫЧ КӨЧ

«Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» Төбәк иҗтимагый оешмасы үзләренең коммерция эшчәнлегендә инде зур уңышларга ирешкән гүзәл затларны берләштерә. Бу мәйданчык бер үк вакытта нетворкинг та, хатын-кызлар клубы да, мәгълүмати ярдәм күрсәтү үзәге дә булып тора. Оешма ничек үсә, кем аның резиденты була ала? «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» Төбәк иҗтимагый оешмасы президенты Лиана Сәетова сөйли:

ФИКЕРДӘШЛӘР БЕРЛӘШМӘСЕ

– Безнең оешма 2012 елда төзелде. Эшкуар хатын-кызларны бердәм комьюнитига берләштерү өчен 12 ел эчендә күп нәрсә эшләнде. Кайчандыр мин үзем эчке туризмны үстерү белән шөгыльләнә идем, аннары мине дәүләт хезмәтенә – Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе урынбасары итеп чакырдылар. Гәрчә мин инде берничә ел буе туристлык компаниясе белән җитәкчелек итсәм дә, дәүләтнең эшкуарларга күп төрле ярдәм күрсәтүен агентлыкка килгәннән соң гына белдем. Менә шул чакта минем шундук әлеге мәгълүмати бушлыкны тутырасым килде.

Без оешма төзедек, эшлекле хатын-кызлар форумын үткәрдек, максатларыбызны билгеләдек һәм эшли башладык. Беренче биш елда безнең берләшмәдәге хатын-кызлар саны йөздән артмады, һәм бөтен эш иҗтимагый нигездә алып барылды. Әмма бу безгә оешма эшчәнлеге юнәлешен төгәл билгеләү һәм аңлау мөмкинлеген биргән яхшы тәҗрибә булды. Бүген без бизнесны үстерү максатыннан эшкуар хатын-кызларны берләштерүне үзебезнең миссиябез, дип саныйбыз. Бу тулы кыйммәтле үзара аралашу һәм читтән яңа белемнәр алу. Конференцияләр, бизнес-миссияләр, осталык дәресләре, профессиональ спикер һәм экспертларны чакырып төрле белем бирү чаралары үткәрү – болар барысы да безнең резидентларыбыз һәм кат-

Фото: tatar-inform.ru

нашучыларыбызның шәхес буларак үсешен дә тәэмин итә, аларның бизнесларын үстерүгә дә булыша.

Бу гаять зур энергия таләп итә торган бик мөһим эш. Безгә кызык өчен генә килмиләр. Оешма әгъзаларының барысы да безнең нәтиҗәле эшләвебезгә һәм үзләренең потенциалын ачарга ярдәм итүебезгә өметләнә. Дөресен әйтергә кирәк, без дә, үз чиратыбызда, теләгән бөтен кешене дә кабул итмибез. Безгә кушылыр өчен, аягында нык басып торырга, бизнесында елына кимендә 4,2 миллион сумлык әйләнеш булырга тиеш. Бу клубка керү өчен минималь лимит, әмма безнең резидентларыбыз арасында еллык әйләнешләре икешәр миллиард сумга җиткән гүзәл затлар да бар. Ягъни безнең клуб ул коткару боҗрасы түгел, бәлки рухландыра торган субстанция булып тора – анда фикердәшләр, булган бизнесны алга этәреп яки яңа стартапка илһамландырып, бер-берсенең мәнфәгатьләрен иркенләп киңәйтә ала. Практика күрсәткәнчә, хәзерге эшкуарларның артыннан чыбыркылап куу таләп ителми, алар үз көчләрен куллану өчен яңа мәйданчыклар эзли һәм бары тик офыкларын киңәйтүгә генә мохтаҗ.

БИЗНЕС ТУРЫНДА ГЫНА ТҮГЕЛ

Бүген без Татарстанның төрле шәһәрләрендә мәгълүм, безнең җирле төбәкләрдә эшли һәм үз чараларын үткәрә торган рәсми вәкилләребез бар. Безнең республика оешмасына барлыгы 342 резидент керә. Тагын бер меңләп кеше рәсми резидентыбыз саналмый, әмма алар безнең чараларда катнаша яки спикер сыйфатында чыгыш ясый. Бу очракта безнең өчен иң мөһиме сан түгел. Без – тату, бердәм фикердәшләр коллективы, һәм безнең көчебез һәм өстенлегебез дә шунда. Нindидер сәбәпләр аркасында безнең бергәлеккә кабул итмәү очраклары да булгалады. Бизнеста закон бозуларга юл куймау – иң мөһим критерийлардан берсе.

Без һәр елны билгеле бер тематикага багышлыйбыз һәм аның белән тирәнтен шөгыльләнәбез. Мәсәлән, бу елны без электрон коммерциягә багышларга ниятләдек, чөнки әлеге тармакта кулланучыларның кызыксынуы глобаль масштабта үсә. Күптән түгел без Электрон сәүдәне үстерү үзәге вәкиле белән очрашу үткәрдек. Һәм менә нәрсә ачыкланды: безнең клубның күп кенә әгъзалары Үзәкнең эшкуарларны электрон мәйданчыкларда эшләргә, анда үз продукцияләрен дөрес тәкъдим итәргә түләүсез өйрәтүен белмәгән дә икән.

Командабызда гел хатын-кызлар гына булганга, без бизнес турында гына түгел, мәгариф, сәламәтлек саклау, гаилә мөнәсәбәтләре, балалар тәрбияләү, матурлык мәсьәләләре хакында да сөйләшәбез. Барлык чаралар үзара бәйле һәм бик кызыклы итеп планлаштырыла.

НИЧЕК РЕЗИДЕНТ БУЛЫРГА?

Эшкуар хатын-кыз үз бизнесын үстерүдә билгеле бер казанышларга ирешкәч, ул аңа кызыксыз булып тоела башлый. Ул инде барысын да аңлаган, бар нәрсәгә дә төшенгән, хәзер алга барырга кирәк, тик ничек? Безнең оешма үз өстенә нәкъ менә диверсификатор вазыйфаларын ала да инде. Бирегә яңа партнерлар табу, яңа идеяләр белән рухлану һәм рәхәтләнеп аралашу өчен килиләр.

«Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» Төбәк иҗтимагый оешмасы резиденты булыр өчен, безнең сайтта гариза тутырырга кирәк. Без аны өйрәнәбез һәм, әгәр барысы да таләпләребезгә туры килсә, клубка чакырабыз. Бездә яшь буенча чикләүләр юк, салым органнарына да бернинди мәгълүмат бирмибез.

ХАТЫН-КЫЗЛАРЧА БИЗНЕС

Гаиләне һәм традицион гаилә кыйммәтләрен саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен популярлаштыру максатыннан Россиядә 2024 ел Гаилә елы дип игълан ителде. Һәм биредә безнең тематика контекстында сөйләшер һәм фикер алышыр нәрсәләр күп. Кызганыч ки, мәгълүм статистика безнең практикада да раслана: эшкуар хатын-кызларның 80 проценты диярлек кияүгә чыкмаган яки аерылган. Ире ярдәмендә уңышлы бизнес алып баручылар сирәк. Хатын-кыз бизнеска текә эшкуар булыр өчен түгел, бәлки балаларын ашатырлык акча эшләү ниятеннән килә. Шулай да булырга мөмкин: гаиләне хәерчелектән коткару өчен, хатын-кыз үз эшен башлый, һаман алга бара, гел эштә була, ире исә моны аңламый, үпкәли һәм нәтиҗәдә – аерылышу. Билгеле, ялгыз калган һәр хатын-кыз да, өстенә җаваплылык алып, үз эшен башлауга сәләтле түгел. Моның өчен ныклы белем дә, максатчанлык та, оптимист холык та кирәк.

Безнең көчле коралыбыз – интуиция: кем белән аралашырга, кемне командага алырга, кемне ялларга, кем белән партнерлык мөнәсәбәтләрен урнаштырырга, кайчан тәвәккәлләргә була – моны без яхшырак тоябыз. Без ир-атлар белән ярышмыйбыз, үз юлыбыздан барабыз, үзебез сиземләгәнчә гамәл кылабыз. Без көрәшмибез, көнләшмибез, яуламыйбыз – без яңаны тудырабыз, иҗат итәбез.

Шундый бер гыйбарә бар: янәсе, хатынкызның уй-фикере ир-атның эш-гамәленә тәңгәлләшә, имеш. Ягъни хатын-кызга, бизнесын үстерү өчен, иртәнге сәгать алтыдан торып, көн буена миллион эш эшләргә өлгерү һәм хәле бетеп өенә кайтып егылу мәҗбүри түгел. Ул үз теләген дөрес итеп космоска җибәрә белә һәм аның һичшиксез үтәләчәгенә ихластан ышана. Ничек кенә көлке тоелмасын, хатын-кызларча бизнес нәкъ менә шуннан гыйбарәт тә инде – ул үз фикерләре, үзенең эчке куәте аша чынбарлык белән идарә итә һәм бөтен теләгенә дә ирешә.

Фотолар Аида Демьянованың шәхси архивыннан. РЕКЛАМА

КАТНАШ НИКАХЛАР
МИЛЛӘТАРА НИЗАГТАН САКЛЫЙ

Күпмилләтле Татарстанда катнаш никахлар инде беркемне дә гаҗәпләндерми. Рус егете татар кызына өйләнә, татар кызы мари егетенә кияүгә чыга, марилар мордва кызларын ала, мордва кызы яһүд егетенә гашыйк була, яһүд егете татар кызыннан башка яши алмый, татар кызы гомерлек юлдаш итеп грузин егетен сайлый... Республика территориясендә 173 милләт вәкиле яши бит, башкача була да алмый!

Катнаш гаиләләрдә ике якның да гореф-гадәтләрен хөрмәтлиләр. Бергәләп Сабан туенда һәм Акатуйда күңел ачалар. Яки Питрау һәм Валда Шинясь бәйрәмнәрен көтеп алалар. Мөселманнар ураза тота, христианнар кайбер ризыклардан тыелып тора, аннары Пасха һәм Гаетне бәйрәм итәләр. Яңа ел да, Рош ха-Шана да, Нәүрүз дә тансык безгә... Күптән түгел исә Татарстандагы бер гаиләдә, бөтен традицияләрне саклап, кытайча Яңа елны каршы алдылар. Без дә булдык анда кунакта, синьцзян дә эчтек, сыйландык та. Бу бәйрәм Аида Демьянова һәм аның ире Юйның татар-кытай гаиләсендә булды.

ТАТАР ЙӨРӘГЕНӘ КЫТАЙ ЮЛЫ

Аида – «ВАНМЕЙ ГРУПП» консалтинг агентлыгын оештыручы, Казандагы өч кытай рестораны хуҗасы, Кытай белән бизнес алып бару белгече.

Булачак ире белән ул Казанда таныша. Гадәттәгечә, барысы да саф мәхәббәттән башлана. КФУның Көнчыгыш телләре факультеты студенты Аида Демьянова кытай телен шулкадәр шәп өйрәнә ки, шул ук вакытта Казанда белем алучы гади кытай егете Юй аның кытайча сөйләшүенә, тавышына һәм үзенә үлеп гашыйк була.

– Ә Аиданы Юй ничек үзенә каратты соң?

– Үзенең кайгыртучанлыгы белән. Төнгә кадәр тәрҗемәләр белән эшләгәндә, ул миңа хәтта аш та пешереп килә иде...

Бу моннан тугыз ел элек булган, хәзер исә инде Аида белән Юйның, зур һәм саф мәхәббәттән тыш, зур гаиләсе, зур бизнесы һәм киләчәккә зур планнары да бар.

ЗУР ГАИЛӘ

– Безнең гаиләбез ишле, – дип сөйли Аида. – Ике улыбыз бар – җиде яшьлек Даниэль һәм өч яшьлек Эрик. Тагын әле Дейзи кушаматлы эт һәм Алиса кушаматлы песи дә асрыйбыз.

Балалар ике исемле, алар хәзер Россия гражданнары. Кытайда берьюлы ике ил гражданы булу тыела, әмма бала балигъ булгач, кайсы ил гражданы булырга теләвен үзе сайлап алырга хокуклы.

Ирем малайларга кытай исемнәрен кушты. Ул тумышы белән Төньяк Кытайдан, анда исем өч иероглифтан тора: беренчесе – исем үзе, икенчесе – нәсел күрсәткече. Мәсәлән, минем улларымның икенче иероглифы Дин, ул «матур урын» дип тәрҗемә ителә, иремнең икенче иероглифы исә Чунь, анысы «яз» дигәнне аңлата. Икенче иероглифтан кешенең кайсы нәселнеке булуын ачыкларга мөмкин. Ә соңгы, өченче иероглифны бала үзе сайлап ала. Махсус компьютер программасы буенча. Кытайлар өчен шунысы бик мөһим: бала тормышының бөтен ягы да гармонияле үсештә булырга тиеш, шунлыктан сәламәтлек тә яхшы, карьера да уңышлы, башка бөтен нәрсә дә хәерле булсын өчен, бик уйлап сайларга кирәк. Бу бик җаваплы процесс.

– Ә компьютерлар булмаганда өченче иероглифны ничек сайлаганнар соң?

– Элек махсус багу системасы, махсус багучылар булган, алар дөрес исем сайларга булышкан. Хәзерге астрологлар сыманрак инде.

– Димәк, барлык әйтелгәннәрне исәпкә алсак, Даниэль белән Эрикның кытайча исемнәре ничек була инде?

– Инг һәм Ханг.

ИТЕКСЕЗ ИТЕКЧЕ

– Сез гаиләдә балалар белән нинди телдә сөйләшәсез?

– Мин үзем кытай теленнән профессиональ тәрҗемәче булсам да, нигәдер балаларымны кытайча өйрәтә алмыйм шул, – дип көлә Аида. – Итексез итекче кебек. Олы улымны өйрәтергә дип, көненә ике сәгать шөгыльләнергә студент кызны чакырдым. Әмма бераз вакыт туктлып торырга туры килде дә, улым барысын да онытты. Һәм ул хәзер өр-яңадан кытайча өйрәнә башлады. Аңа бу ошый, аның Кытайны бик күрәсе килә, шунлыктан тырыша. Әле аларның Кытайны күргәннәре юк: башта кечкенә иделәр, аннары пандемия башланды... Хәзер мин аларның икесенә дә чит ил паспорты ясаттым, тиздән алар әтиләренең ватанын һәм, ниһаять, үзләренең кытай әбиләрен күрер, дип өметләнәм. Минем әти-әниемне исә көн саен күрәләр, алар безгә улларыбызны тәрбияләүдә бик булыша.

Хәзер улларым әтиләре белән ватa-җимерә русча сөйләшә. Балалар хәйләкәр бит, җиңел юлны сайладылар. Әгәр алар белән өлкән кеше кытайча сөйләшсә, ничек тә өйрәнергә туры килер иде. Ә безнең очракта

исә өлкән буын бераз йомшаклык күрсәтте, һәм менә нәтиҗәсе шулайрак булып чыкты.

ИҢ ШӘП ВАКЫТ

Кытайчага өйрәнүдән тыш, Даниэль әле футбол белән дә шөгыльләнә. Аңа кадәр брейк-данска йөреп карады, тик ошатмады. Без дә ирексезләмәдек. Аның хәзер шундый чагы, үзен бөтен нәрсәдә сынап карарга тели. Хәзер блогер булмакчы – эйдә, хәленнән килә икән, тырышып карасын.

Мин уларымның икесен дә йөзүгә йөртәм. Үзем йөзә белмим. Сүз уңаеннан, кытайларның да күбесе йөзә белми. Шуңа мин балаларны һичшиксез йөзәргә өйрәтергә кирәк, дип саныйм. Ризалыкларын сорап та тормадым. Әмма икесе дә бассейнга бик теләп йөри.

ИР БЕЛӘН ХАТЫН

– Плюс белән минус бер-берсенә тартыла, аннан соң инде ир белән хатын арасында аңлашылмаучанлыклар да килеп чыгарга мөмкин. Сезнең гореф-гадәтләр дә, тел дә, көнкүреш тә икегезнең ике төрле, озак ияләштегезме?

– Төрлечә булды инде. Мәсәлән, ризык белән. Кытайлар тәмле ашарга ярата, ризыкка табына, дип тә әйтеп була. Аларда ашау вакыты – изге. Кытай сыйланганда, бөтен нәрсә туктап кала.

Ә миңа дусларым да, якыннарым да, гел бик тәмле пешерәсең, диләр иде. Мин бик сирәк, әмма тәмле пешерәм, һәм моны дусларым яхшы белә. Тик ирем белән бергә яши башлагач, ул мин пешергән ризыкларны ашый алмый иде. Нәрсә генә пешерсәм дә, ашарлык түгел, дип зарлана. Мин тырышам, аңа 2-3 төрле ризык әзерлим, ул кабып карый да, борынын җыера, аннары йә ризык китертә, йә үзе пешерә башлый.

Башта миңа бу бик авыр булды. Шулай бервакыт ирем эштән кайтты, мин, интернеттан карап, үземчә кытай ризыгын әзерләп көттем – соя соусы, сарымсак, зәнҗәбил белән. Гарниргa исә – бәрәңге. Ә ул сорый:

– Моны нәрсә белән ашарга соң? Гарнир кайда?

– Менә, бәрәңге.

– Бәрәңгенең монда нигә кирәге бар?! – диде ул, ачуы чыгып.

Аларда бәрәңге аерым ризык, бернинди дә гарнир түгел икән. Йә токмач, йә дөге кирәк.

Аннан түзмәде, үзенә дөге пешерде. Шул вакыттан бирле мин бәрәңгенең гарнир түгел, аерым ризык икәнен яхшы хәтерләп калдым.

Хәзер безнең Кытайдан килгән ашчылар эшли торган чын кытай рестораныбыз бар, һәм Юй үзе теләгән бөтен нәрсә белән сыйлана ала. Нәкъ Кытайдагы кебек.

КЫЙММӘТЛЕ-ЗИННӘТЛЕ БУЛСЫН

Безнең уртак тормышыбызда кызыклы хәлләр дә шактый. Мин, мәсәлән, сәяхәттә йөргәндә, төрле илләрдән һәм шәһәрләрдән магнитлар алып кайтырга яратам. Дусларым да алып кайткалый. Бу һәрвакыт ниндидер бер хатирә, тарих, кеше белән бәйле була...

Кытайлар өчен бу бөтенләй башка халәт. Җыю-туплау-саклау аларга хас түгел. Аларда бөтен нәрсәне сатып алып була бит. Һәм менә бервакыт Юй миңа сюрприз ясады.

Ул Кытайдан бер өем магнит кайтарткан, мин әле барып күрмәгән илләрдән дә бар. Бик күп магнит!

– Нәрсә бу? – дип шаккаттым мин.

– Син магнитлар яратасың бит, – ди ул, бәхетле елмаеп һәм мине сөендердем дип уйлап.

– Безнең өчен магнит – сәяхәтләр, очрашулар турында хатирә бит ул, – дип аңлатмакчы булам.

Ул аңламый, бу аның башына сыймый. Ниндидер предметка мөкиббән китеп буламыни? Алар, бөтен нәрсәне акча хәл итә, дип уйлый.

Брендлар белән дә шул ук хәл. Хушбуй сатып алалар икән, аларны ис бөтенләй кызыксындырмый. «Диор» яки «Шанель» дисәң, иң кыйбатлы савыттагысын сайлыйлар да, шуны сатып алалар. Иң мөһиме – кыйммәтле-зиннәтле булсын, исе ошау-ошамавында исә аларның эше юк.

– Моңа ничек түзәсез инде?

– Ничек-ничек, түзәбез инде! Дөресен әйтсәң, үпкәләтерсең кебек, ул бит тырышкан, шулай яхшырак булыр, дип уйлаган. Ә икенче яктан караганда, әгәр бу юлы әйтми калсаң, киләчәктә дә шулай буласын көт тә тор! «Менә мин синең өчен акча кызганмыйм бит, ә сиңа ошамый!» – ди. Аңлатмакчы булам. Мисаллар китерәм. Әкренләп бераз булса да үзгәрәбез инде...

Әмма миңа шунысы ошый: 2015 елдан бирле бергә булсак та, без һәркайсыбыз шәхес булып калдык. Ачыкланганча, без әллә ни төрле дә түгел икән әле.

БӘХЕТЛЕ НИКАХ СЕРЕ

– Бәлки, бәхетле никахның сере дә шундадыр, – дип фикер йөртә Аида. – Яңа культура һәм традицияләргә ачык булу. Хәләл җефетеңнең сәер үзенчәлекләренә сабыр итү. Инде балигъ булган кешене ни өчен үзгәртергә маташырга соң? Аны, ничек бар, шулай кабул итәргә кирәк. Ул хәзер синең янәшәңдә. Аның синнән бераз аерылып торуы хәтта кызыклырак та әле. Аның шәхесен хөрмәт итәргә, шул үзенчәлеге өчен яраткансың икән, аны үзгәртергә тырышмаска гына кирәк. Гаиләдә һәркем үзе булып калырга тиеш.

ТУЙ АЛДА ӘЛЕ

– Ә туегыз ничек узды: безнеңчәме, әллә кытай гореф-гадәтләре буенчамы?

– Туй булмады. Язылыштык кына. Әмма хәзер, Кытайны яхшырак белгән саен, минем үземнең чын кытайча туй үткәрәсем килә. Бик күп кунак чакырып, кызыл төстәге кытай милли киемнәрен киеп... Миңа бу бик кызык шикелле тоела. Табигый ки, мин бу туйның Кытайда булуын телим.

– Ә кияү ризамы соң?

– Әйе, ул каршы түгел. Димәк, безнең кытай туебыз алда әле.

ЯШЬ ПАРЛАРГА КИҢӘШЛӘР

– Казанда сезнеке кебек никахлар күп түгел. Әмма кытай егетләренә безнең ил кызлары бик ошый, диләр. Һәм мондый ир-атлар Казанда һаман арта бара. Үз гаиләгез тәҗрибәсеннән чыгып, Татарстан-Кытай парларына нинди киңәшләр бирер идегез?

– Әйе, кытайлар безнең Россия кызларын бик ярата. Әгәр кызлар да кияүгә чыгарга каршы түгел икән, башта аларның менталитетын, культурасын өйрәнсен һәм кайда яшәячәкләрен алдан ук хәл итсен иде. Бу мөһим. Без танышкан гына чакта мин Кытайга китәргә риза идем. Булачак иремә шулай дип әйттем дә: әгәр ул теләсә, мин күченергә риза. Тик миңа Юй:

– Юк, миңа Россия дә, Казан да бик ошый, минем моннан китәсем килми, – диде.

Һәм хәзер инде, тамыр җибәргәч, бизнесыбызны коргач, минем үземнең дә китәсем килми. Һәрвакыт әйтә киләм: минем иң яраткан шәһәрем – Казан. Чөнки әти-әнием дә, эшем дә, йөрәгемә якын башка нәрсәләр дә барысы да биредә... Мәхәббәт мәхәббәт белән, тик башка илгә күченүгә бәйле мөһим нәрсәләрне алдан ук сөйләшеп кую зарур.

Улларым белән минем мисал бик үк дөрес түгел. Аларны кечкенәдән үк ата теленә дә, ана теленә дә өйрәтергә кирәк булган. Кеше балачактан төрле культураларны сеңдереп үсә, әмма һәркемнең үз милли тәңгәллеге һәм башкаларга карата тату мөнәсәбәте булырга тиеш. Мондый никахлар – бик шәп нәрсә, чөнки балалар мультикультур мохиттә һәм ике якның да бердәй яхшы булуын күреп үсә.

Хәзер дөньяда барган хәлләрдән чыгып шуны әйтә алам: кешеләрнең бер-берсен милләтләргә, илләргә бүлмәве бик мөһим. Минемчә, бу ил яхшы, ә бусы – начар, бу милләт кешеләре яхшы, ә болары начар дип, ярлык тагарга ярамый. Иманым камил: нәкъ менә катнаш никахлар, бу никахта туган сабыйлар, гаиләдә башка милләт кешеләренә хөрмәт белән тәрбияләнеп, киләчәктә әлеге каршылыкларны юкка чыгарыр. Чөнки халык, балалар бөтен җирдә дә бертөрле, барысы да бертигез.

КИЛӘЧӘК ГАИЛӘСЕ

– Сез киләчәк гаиләсен шулай күзаллыйсызмы?

– Әйе. Минемчә, безнең балалар башкачарак, яхшырак яшәр. Алар безгә караганда бәйсезрәк, фикерлерәк, акыллырак булачак. Безне үстергәндә, төрле юнәлешләрдә сынап карау мөмкинлеге бүгенгедәй булмаган әле. Миңа 35 яшь, һәм мин әле үземә нәрсә ошавын, нәрсә белән шөгыльләнергә теләвемне нибары моннан ике ел элек кенә аңладым. Киләчәк балаларының андый сайлау мөмкинлеге иртәрәк булыр, дип ышанам.

Менә, мәсәлән, олы улым өйләнергә җыенды, ди. Аның гаиләсе нинди булачак? Хыялланып карыйк. Гаиләдә һәркем тигез хокуклы булыр, дип өметләнәм: ир һичшиксез шуны, ә хатын исә шуны эшләргә тиеш, дигән стереотиплар булмаячак. Ә бәлки ир-ат ашарга пешерергә, балалар белән кайнашырга яратадыр, хатыны исә гаилә бизнесы стратегиясе өчен җавап тотадыр?

Минем улымның гаиләсендә һәр икесе шәхес булып калыр, һәр икесе гармонияле үсештә булыр, дип өметләнәм. Аларга бергә яшәве рәхәт булсын. Бергә каядыр бару. Бергә дәшмичә тору. Бергә вакыт уздыру. Гаиләнең төп кыйммәте, асылы шунда бит инде: сиңа янәшәңдәге кеше белән бик рәхәт булырга тиеш, ул сине ничек бар, шулай кабул итсен.

ТАГЫН МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА

– Кайгыда да, шатлыкта да, көнкүрештә дә, бизнеста да, балалар тәрбияләүдә дә тугыз ел гел бергә... Сезнең мөнәсәбәтләрдә тәүге саф хисләр сакландымы соң? Әллә бу инде күнегелгән гадәт кенәме?

– Әйе, бер-беребезгә ияләштек инде. Нииндидер проблемалар килеп туса, электәге кебек үк кинәт кызып китмибез. Ә мәхәббәткә килсәк... Вакыт-вакыт сиздерә әле ул. Мин моны гомумән гормоннарга бәйле, дип саныйм. Мәсәлән, яз миндә мәхәббәт уята. Эш көннәрендә ул азрак, ял көннәрендә күбрәк сизелә.

Кайвакыт мин иремә: «Әйдә, очрашуга чакыр әле мине!» – дим. Ә ул: «Нинди романтика инде ул, ярты гомер үтте бит!», йә «Нинди мәхәббәт инде ул? Сиңа 36 яшь тулды бит!» – ди. Эш шунда: кытайлар ана карынында үткән елны да кушып саный, шуңа ул миңа гел бер ел өсти. Инде 32 яшь тулгач ук ул миңа, гомер үтте инде, дигән иде. Бу мәсьәләдә пессимист ул. Бәлки, тагын шуңадыр да: алар туган көннәрен елына ике тапкыр үткәрә бит – шул көнне һәм Ай календаре буенча. Шуңа иремнең мәхәббәте хакында җавап бирә алмыйм. Вакыт-вакыт аңарда миңа карата бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт уяна үзе – кочак-кочак чәчәк һәм бүләккә күмәргә мөмкин...

– Сез дә ике туган көн үткәрәсезме?

– Әйе, һәм ике Яңа ел!

Өйләнешкәннән соң беренче елларда минем Яңа елны күнегелгәнчә – шампан шәрабе эчеп, теләкләр теләп каршылыйсым килә иде. Ә ул хәтта бүләк тә бирми! Чөнки кытайлар өчен безнең Яңа ел – гади ял көне генә. Ял итәләр дә кабат эшкә чумалар. Хәзер мин инде кытай Яңа елына зурлап әзерләнәм. Безнекен дә бәйрәм итәбез, әмма бусы активрак үтә.

Баштарак ике тапкыр туган көн үткәргәнгә дә үпкәли идем. Әтием ярдәмгә килде. (Ә ул – удмурт.) Ул авылда бер көнне туган, тик аны ике айдан соң гына теркәгәннәр – кар эреп, юллар ачылганчы район үзәгенә барырлык булмаган ул чакта. Һәм әтием гомере буе туган көнен елына ике тапкыр бәйрәм итә – шәп бит! Һәр нәрсәнең уңай ягын табарга гына кирәк.

«ГАИЛӘ БИЗНЕСЫ – ТУГАННАР АРАСЫНДА МӨНӘСӘБӘТ КЕНӘ ТҮГЕЛ»

Бөгелмәдәге «Инженерлык-җитештерү үзәге» ҖЧҖ директоры һәм аның хуҗаларыннан берсе булган Ольга Айдуганова үзенең гаилә предприятиесе, булачак варислары һәм җитәкчелекнең төп принциплары турында сөйли.

Фотографияләр Ольга Айдуганова архивыннан алынды. РЕКЛАМА

«БЕЗ КОМСОМОЛДАН ЧЫКТЫК...»

Безнең предприятиенең тарихы 80-90 нчы елларда эшли башлаган, хәзер аякта нык басып торган башка бизнесларга охшаган. Ул вакытта комсомолга (ВЛКСМ) яшьләр өчен фәнни-техник иҗат үзәкләрен ачарга, шулай ук эшкуарлык белән шөгыльләнергә рөхсәт итәләр.

Әтием 1988 елда нәкъ менә шундый үзәкләрнең берсен оештырган да инде. Башта озак вакыт патентланган үз технологиябез белән бөтен Россия буйлап торбаүткәргечләр салып йөрдек. Аннары үз производствобызны ачарга вакыт җиткәнен аңладык: 2004 елда завод барлыкка килде, ә 2008 елда без яңа корпуслар төзедек. Менә шулай акрынакрын алга барабыз һәм үсәбез.

«ХӘЗЕР БУЛМАСА, БЕР ЕЛДАН, ҺИЧШИКСЕЗ, САТАЧАК...»

Мин 2018 елда җитәкче кәнәфиенә утыргач, күпләрнең: «Мөгаен, бизнесны сатар... Хәзер булмаса, бер елдан, һичшиксез, сатып җибәрәчәк», — дигән сүзләрен ишеттем.

Ә мин сатмадым, һәм менә 6 ел инде мин үземне бу рольдә бик яхшы хис итәм. Хәер, бу башкалар өчен генә түгел, хәтта үзем өчен дә көтелмәгән хәл булды.

Әлбәттә, юлыма төрле кыенлыклар очрый тора: компаниягә ышанычны саклап калырга тырышу да, ковидка бәйле чикләүләрне җиңеп чыгу да — гомумән, һәр очракта бер-берсенә бөтенләй охшамаган мәсьәләләрне хәл итәргә туры килә.

«ГАИЛӘ БИЗНЕСЫ — ТУГАННАР АРАСЫНДА МӨНӘСӘБӘТ КЕНӘ ТҮГЕЛ»

Предприятиедә безнең гаилә әгъзалары да эшли. Бер абыем — үсеш буенча директор, икенче абыем куркынычсызлык өчен җавап бирә, шулай ук өчтуган сеңлебез дә безнең янда. Шуңа да карамастан, «гаилә бизнесы» төшенчәсен мин шактый киңрәк кузаллыйм.

Без компаниябезгә үзебезнең гаилә кыйммәтләрен һәм принципларын алып киләбез, алар оешма принципларына авазлаш.

Мәсәлән, без һәрвакыт нинди дә булса яңалыкка, аны үзебездә булдырырга омтылабыз. Шуңа күрә хезмәткәрләребезнең укуын һәм үсүен, камилләшүен хуплыйбыз, аларның сайлау ирегенә хөрмәт итәбез һәм үз карашларыбызны көчләп такмыйбыз.

Сүз уңаеннан, гаилә традицияләренә тугрылык, буыннар алмашы күп кенә хезмәткәрләребезгә хас. Компаниябездә тулы бер гаилә булып, бергә хезмәт итә торган токарь, слесарь һәм инженер-техник хезмәткәрләр династияләре бар.

«ГАИЛӘ ПРЕДПРИЯТИЕСЕ — СЫЙФАТ БИЛГЕСЕ»

Россиядә генә түгел, бөтен дөньяда гаилә предприятиеләре күп булган. Моның берничә сәбәбе бар:

* нәкъ менә шундый предприятиеләр аеруча тотрыклы. Партнерлар, кинәт араны өзеп, башка өлкәгә китәргә мөмкин булган кризислар вакытында бу тотрыклылык бигрәк тә нык сизелә. Гаилә бизнесында мондый хәл килеп чыкмый диярлек, чөнки эшләр мирас итеп тапшырыла, шуңа бәйле рәвештә традицияләр һәм гомуми принциплар формалаша;

* гаилә бизнесы синең фамилияң, исемең белән тыгыз бәйләнгән, әлбәттә, аларның начар тәэсир, тискәре фикерләр уятуын теләмисең;

* һәрвакыт үз продукцияңнең сыйфатын күтәрергә һәм озак вакытлы элемтәләр корырга омтыласың. Мәсәлән, варисларың бар икән, син 30, 40, 50, 100 ел үткәч ничек булыр дип, киләчәкне уйлыйсың. Дәвамчыларың юк икән, артык баш ватмыйсың.

«ГАИЛӘ БИЗНЕСЫ ТУРЫНДАГЫ ЗАКОН КИҢ ОФЫКЛАР АЧАЧАК»

Сәүдә-сәнәгать палатасы (ТПП) тарафыннан гаилә бизнесына карата кызыксыну арту сөендерә. Мин ул законның Россия Федерациясе югарылыгында һәм аның барлык төбәкләрендә кабул ителгәнен бик көтәм, әлегә ул Дәүләт Думасында фикер алышуның соңгы стадиясенә килеп җитте.

Ул җайга сала ала торган шактый күп мәсьәләләр бар. Мәсәлән, әгәр син берничә компания җитәкчесенә әйләнәсең икән, бу аларны бүлгәләүне күрсәткән бер билге дип карала. Тик компания үсә, аның эшчәнлек төрләре күбәя икән, бу эш төрләрен юнәлешләргә аерып чыгару һәм барлык акчаны бер янчыкка салмау — гадәти күренеш бит. Әгәр син бер предприятие кысаларында берләшәсең икән, финанс агымнары бутала, нәтиҗәдә, банклар предприятиене югары куркынычка ия предприятие дип бәяли.

Шуңа күрә мондый законны кабул итеп, гаилә бизнесының компанияне ваклау-бүлгәләү түгеллеген тасвирлап, аңлатып бирү әлеге мәсьәләне генә түгел, ә гаилә предприятиеләрендә мирас мәсьәләләрен дә хәл итүнең законлы юлын ачачак.

«БАЛАЛАРЫМ БИЗНЕСТА МИН БАЛА ЧАКТАГЫГА КАРАГАНДА КҮБРӘК КАТНАША»

Алар күргәзмә, очрашу һәм конференцияләргә йөри. Алар яшендәге чагым белән чагыштырганда, балалар заводка ешрак килә.

Мине, мәсәлән, гаилә бизнесына бөтенләй әзерләмәделәр. 6 ел элек, варис булып калгач, бу бизнес турында гомуми белемнәрем генә бар иде. Миңа башка тармак һәм компанияләрдә эшләгәндә туплаган зур тәҗрибәм ярдәм итте.

Балаларым минем эшемне дәвам итәргә һәм гаилә бизнесы белән шөгыльләнергә тиеш дип, йөз процент ышандырып әйтә алмыйм. Мин аларга сайлау иреге бирәм, тик аларның, һичшиксез, эшнең ничек барганын күреп, бизнесның ничек оештырылуын аңлап үсүе мөһим. Чөнки 30–40 елдан предприятиебезне мирас итеп алганда, кайчандыр минем кебек аптырап калмас өчен, компания белән нәрсә эшләргә кирәклеген яхшы аңларга-белергә тиешләр.

«ИҢ МӨҺИМЕ — ЯРАТКАН ЭШЕҢ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮ»

Хатын-кызларга гына түгел, ир-атларга да бизнес белән гаиләне бергә алып бару кыен. Бу үтәп булмастай тоелган бурыч. «Көчеңне каян аласың, уңышың шунда» дигән гыйбарә бар. Әгәр көч-куәтеңне гаиләңнән аласың икән, димәк, уңышың — гаиләдә, бизнестан икән, димәк, уңышың — бизнеста. Гаилә бизнесында исә алтын урталык һәм тигезлекне табу һәм саклау аеруча кыен.

Шуңа күрә мин һәркемнең яраткан эше белән шөгыльләнүен телим. Әгәр сүз бизнес турында бара икән, беренче чиратта ул акча түгел, ә канәгатьлек, рәхәтлек алып килсен, ә акча үзеннән-үзе килеп кушылачак.

Әгәр синең яраткан эшең гаилә икән, бәлки, сиңа бизнес белән шөгыльләнергә дә кирәкмидер. Гаилә дә һәр көнлек эш-мәшәкать дигән сүз бит ул.

Икесен берләштерергә тырышасыз икән, үзең һәм якыннарың өчен атнага ике буш көн калдыруны кагыйдә итеп алыгыз. Җомга көнне кичке сәгать алтыда хезмәт урыны белән бәйле эшләрнең ишеген ябасыз да аны дүшәмбе көнне иртәнге сәгать җидедә ачасыз. Нибары шул гына. Бу җиңел түгел, әмма гадәткә кертеп булырдай нәрсә.

ӨЛГЕР ӘНИ ТОРМЫШНЫ СӨЕП ЯШИ

Оксана Бирюкова

Кайбер ханымнарның өлгерлегенә сокланып туя алмыйсың. Әңгәмәдәшем Лилия Садыйкова шундыйлардан. Иҗади, отставкадагы полиция майоры, дүрт бала анасы, төрле чаралар оештыручы, «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» бизнес-клубы, «Нур» хатын-кызлар социаль инициативалары ассоциациясе әгъзасы. Энергиясенә, дәрт-дәрманына шаккатарлык. «Татарстан» хәбәрчесенең Лилия Садыйкова белән очрашуы – ярашмастайны яраштыра алган ханым турында кызыклы әңгәмә ул.

– Лилия, һөнәри юлыгыз нәрсәдән башланды? Бу тәҗрибә сезгә нәрсә бирде?

– Балачактан ук мин мәктәптә җәмәгать эшләрендә, үзешчән сәнгатьтә һәрвакыт актив катнаша идем, түгәрәкләргә йөрдем, югары сыйныф укучылары советы башлыгы, отличник булдым. Ләкин активлыгым мәктәп белән генә чикләнеп калмады. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институтына укырга кердем. Анда уку плацта тезелеп сафта торуны, катгый дисциплинаны, хәрби киемдә йөрүне күздә тота. Мин анда янә иҗади мохиткә чумдым. Атаклы «Академия 02» КВН командасына йөрдем, анда бердәнбер кыз идем, администратор да булдым. Бу үз көчемә ышаныч өстәде, сәхнә осталыгын арттырды. Командабыз белән үзебезнең республикада, Мәскәүдә һәм гомумән Россия күләмендә чыгышлар ясадык.

Безнең команда уенчылары барысы да диярлек бүгенге көндә билгеле шәхесләр: Бөгелмә районы башлыгы Линар Закиров, Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе урынбасары Дамир Фәттахов һәм башкалар. Институттан соң хокук саклау органнарына эшкә урнаштым, оештыру тәҗрибәмне искә алып, миңа шунда ук Эчке эшләр министрлыгының мәдәният үзәге (элекке Менжинский мәдәният йорты) администраторы вазыйфасын тәкъдим иттеләр. Мин коллегияләр, полициянең төрле хезмәтләре һәм бүлекчәләренең бәйрәм көннәрен, тантаналы чараларны үткәрү өчен җаваплы идем. Аннары декрет ялына чыктым, кызым туды. Эшкә чыкканнан соң, озак та үтмәстән, миңа эчке эшләр министры Әсгать Сәфәровның өлкән референты (1998–2012 еллар) булырга тәкъдим иттеләр.

– Бу чор ничек хәтергә кереп калды?

– Күп мәсьәләләрне берьюлы хәл итүнең кирәклеге һәм матур көннәре белән. Ул вакытны җылы хисләр белән искә алам: сәгать җиденче яртыда ук эшкә киләсең, иртәнге сводка, докладлар, вакыты чикләнмәгән хезмәт көне. Киң күңелле, акыллы җитәкче, искиткеч укытучы һәм остаз Әсгать Әхмәт улының ярдәмчесе булып эшләвем яхшы мәктәп булды, дип уйлыйм. Һәр көнне кызыклы кешеләр – төрле министрлык җитәкчеләре, танылган шәхесләр, депутатлар, Президент аппараты, Министрлар кабинеты хезмәткәрләре, генераллар белән очрашулар күздә тотыла иде. Көн дәвамында телефон шалтырап тора, элемтәгә чыгучыларга дөрес җавап бирергә һәм мәсьәләне хәл итүдә булышырга кирәк. Хокук саклау эшенең

Фотолар Лилия Садыйкованың гаилә архивыннан. РЕКЛАМА

җитдилеген һәм мөһимлеген, намусың һәм җәмгыять каршында җаваплылык белән бәйле һөнәрнең әһәмиятен аңлау зарур. Бу ыгы-зыгы миңа бик ошый иде, үземне нәкъ менә үз урынымда дип хис иттем. Дөрес, кайвакыт кызымны карау белән кыенлыклар булгалады. Ул, иртән торып, минем белән эшкә бара, бүлмәдә көтеп утыра, аннары гына мәктәпкә китә. Дәресләр беткәч тә, минем янга кайта. Шулай да бу еллар иң матур чор булып хәтеремә уелып калган. Әсгать Әхмәт улы Сәфәров җитәкчелегендә Эчке эшләр министрлыгында искиткеч тормыш мәктәбе үттем. Ул үзенең отставкасы турында әйткәч, күз яшьләремне тыеп тора алмадым. Бераз соңрак исә тормыш кискен борылыш ясады: улым туды, ел ярымнан соң – тагын берсе, берничә елдан соң дүртенче бала – кызымны алып кайттым. Аннары пенсия яше дә килеп җитте, шуңа күрә полициягә эшкә кире кайтмадым.

– Декрет ялы – һәрвакыт бөтенләй яңа тормыш кебек ул. Ул чаклар ничек истә калды?

– Бер караганда, бу – эмоциональ яктан талчыктыра торган чор. Ләкин мин, үземне программалаштырып, әзерләп куйган идем һәм көнкүреш мәшәкатьләрен, бала чүпрәкләрен җиде ел тыныч кабул иттем. Өстәвенә, бала караучы да ялламадым, янәшәдә әби-бабайларыбыз юк – без шәһәрдән читтә яшибез. Йортны икенче улыбыз тугач сатып алдык. Ярдәмчеләрдән ирем һәм өлкән кызым гына булды. Мин полициядә эшләгәндәге чыныгуым ярдәм итте, дип уйлыйм. Шуңа күрә декрет ялын да уңай рухта үткәреп җибәрдем. Ә менә ыгы-зыгыны, хәрәкәтне сагынуым – анысы башка нәрсә. Шул вакытта төрле җәмгыятьләргә, шул исәптән «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» оешмасына кердем, 2016 елдан очрашуларга, семинарларга, эшлекле төшке ашларга йөри башладым.

– Тормышка мәгънә бирү өчен яңа мөмкинлек таптыгыз булып чыга...

– Әйе. Эшлекле хатын-кызлар янына ашкынуыма үзем дә гаҗәпләнә идем. Теге яки бу кичәгә билет сатып алам да барам, минем аралашасым, яңа танышлар табасым килде, социаль челтәрләрдәге сәхифәләремне үстерә башладым, тренинглар уздым.

Бу исә таныш-белешләр даирәсен киңәйтте, дусларым, фикердәшләрем күбәйде, белем-күнекмәләрем кулланыш тапты, үзем йөргән җәмгыятьләрдә, берлекләрдәге таныш кешеләр арасында теләсә нинди бәйрәм-кичәне үткәрә алам. «Лилия – бәйләп торучы буын, дипломат, бөтен кешене, бөтен нәрсәне белә», – дигәнне еш ишетәм. Тирәюнемдәге яңа кешеләр белән күзгә күренми торган бәйләнеш сизәм. Дус була беләм, ярдәм сораганда кире какмыйм, киңәшемне кызганмыйм. Шуңа күрә миңа ир-атлар да, хатын-кызлар да, ышанып, үз серләрен ача, тумыштан килгән дипломатлык сәләтемне эшкә җигеп, низагларны хәл итәргә булышам. Үзем беркайчан да ызгыш-каршылыкларга кермим, кешеләрнең миңа тартылуы шуның белән дә бәйле.

– Тормышыгызга коучинг каян килеп керде? Ни өчен бу белгечлекне үзләштерергә булдыгыз?

– Ниндидер яңа нәрсәләр белергә, үзем өчен ачышлар ясарга теләгәнемне аңладым. Коучинг үз-үзеңне танып белү, кешенең эчке дөньясында һәм тирә-ягында булган хәлләрне аңлау өчен этәргеч бирде. Диплом якладым, бу миңа тормыш психологиясе буенча белем өстәде һәм ышанычымны ныгытты.

– Сезнең өчен тормышта нинди рухи кыйммәтләр мөһим? Балаларга нинди принципларны сеңдерергә тырышасыз?

– Намуслылык, һәрвакыт дипломат булып кала белү, килешергә-сөйләшергә, компромисс табарга омтылу. Мин үзем дә шундый. Мөгаен, моңа челтәрле маркетинг компанияләре белән хезмәттәшлек тәҗрибәсе дә ярдәм иткәндер. Миңа кешеләр белән үзара элемтә тоту, аларның ихтыяҗларын күрә белү, аларга игътибар күрсәтү ошый иде. Шулай ук гаделлек һәм әдәплелек, дисциплинаны югары бәялим. Бу яктан мин балаларга бик таләпчән.

– 2024 ел Россиядә гаилә елы дип игълан ителде. Гаилә кыйммәтләрен ныгытуда һәм демографик вазгыятьне яхшыртуда нәрсә булыша ала?

– Әлбәттә, дәүләт ярдәме бик мөһим. Аннары хатын-кызда ышаныч та булырга тиеш. Ә аны янәшәдәге ир кеше тәэмин итәргә мөмкин. Әмма үз көчеңә ышаныч хисе дә кирәк, хатын-кыз алга атларга тиеш, даими үсештән башка мөмкин түгел. Монда иң мөһиме – гаиләне ташлап, актив хатын-кызлар җәмгыятьләренә, тренинг һәм рухи үсеш курсларына баштанаяк кереп чуммаска. Күп кешедә нәкъ шуны күрәм дә: тормышта үз урыннарын эзлиләр, тик таба алмыйлар. Ә асылда ике юнәлешне бергә алып барырга кирәк: фитнеска һәм бассейнга, матурлык салонына юл тотыгыз, хезмәттәшләрегез һәм дус кызларыгыз белән очрашыгыз, аннары – гаиләгезгә вакыт калсын, бала белән дәрес әзерләгез, кичке ашка берәр тәмле нәрсә пешерегез. Елларда ирегез белән театрга баруны планлаштырып куегыз. Еш кына яшь гаиләләрне күзәтәм дә гаиләне саклап калуның никадәр авыр икәнен аңлыйм. Хәзер кызыктыра торган нәрсәләр күп – кыланчыклык, байлыкка омтылу, тышкы бизәкләр, ә алар артында – бушлык. Җәмгыятебездә һәркем чын гаилә кыйммәтләренең нәрсәдә булуын аңласын иде.

– Ә сезнең гаиләдә аңлашылмаучанлыклар, кыенлыклар килеп чыкканы бармы?

– Һәр гаиләдә кебек. Балалар тугач, ир дә, хатын да дөньяга, тормыш кыйммәтләренә башкача карый, аларны башкача бәяли башлый. Ул чакта йә көн саен елап-шыңшып йөрисең, сукранасың, үпкәлисең яисә ризалашасың, аңлыйсың, үзеңне яхшыртасың, тормышыңны ниндидер яңа нәрсә белән тутырасың, үз-үзеңне үстерүгә йөз тотасың.

– Сезгә нәрсәләр куаныч китерә?

– Төрле вак-төяк нәрсәләр, теләгәнемне эшли алу, тормышыма үзем керткән чуарлык: иремә һәм балаларга иртәнге аш әзерләү, ә аннары инде үзем өчен берәр нәрсә эшләү, мәсәлән, театрга бару. Балалар да, ир кешеләр дә хатын-кызда хис-тойгыларның ташып торуын яисә, киресенчә, аның рухи яктан талчыгуын сизә.

– Хәзер нинди уй-ниятләр белән яшисез?

– Балаларга терәк булу, вакытны алар белән бергә үткәрү. Күптән түгел генә үземә эчке таянычның да кирәклеген һәм мөһимлеген аңладым, шуңа күрә параллель рәвештә төрле чаралар оештыруда, җәмгать эшләрендә катнашуымны дәвам итәчәкмен, чөнки, кайда гына булсам да, андый эшләр мине үзләре дә эзләп таба.

УЕН АША – СӘНГАТЬКӘ

ПЛАНЕТАБЫЗНЫ САКЛАУ СЕРЛӘРЕ

Баланы телефон һәм планшет экраныннан карап торган аллы-гөлле һәм мавыктыргыч дөньядан аерып буламы? Әйе, аңа кино галәме герое булырга тәкъдим иткәндә, бик мөмкин!

«Татарстан» журналы «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбе яулаган яңа үрләр турында сөйли.

ЙОЛДЫЗЛАР ЮЛЫ

Фильм ясау серләре белән танышу гомерлек тәэсирләр калдыра һәм шәхеснең яңа сәләтләрен ача. Моны «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбенең республикабызда инде 12 ел гамәлгә ашырыла торган «Шкодники» проекты раслый.

Балалар дәресләргә йөри, актерлык осталыгы һәм үзләрен иҗади яктан ачу серләренә өйрәнә, ә аннары белемнәрен кыска метражлы фильмнарда төшкәндә куллана «ДжуниорЛайф»та елына 80 ләп кыска метражлы фильм чыга. Аларны «Мир» кинотеатрында, Ленин мәдәният сараенда, шулай ук «Эфир» һәм «Күңел» телеканалларында күрсәтәләр. Һәм, әлбәттә, ютуб-канал белән социаль челтәрләрдә.

Зур экранда альманах премьералары ел саен июнь һәм декабрь айларында үткәрелә. Мондый премьералар һәрвакыт зур гаилә бәйрәменә әверелә. Тамашачыларны һәм яшь актерларны театраль этюдлар, концерт номерлары, котлаулар һәм изге теләкләр көтә. Яшь кинойолдызларга әле алар турында язма басылган «Татарстан» журналы да тапшырыла.

ТАБИГАТЬ ҮЗЕ ӘЙТЕП ҖИБӘРГӘН ИДЕЯ

2024 елда «Шкодники» 12 яшь тулуны билгеләп үтәчәк. Матур бәйрәмне алар яңа проект белән каршылый. Ә идеяне... Татарстанның матур табигате әйтеп җибәргән.

– «Шкодники» өчен актерлык осталыгы күчмә лагеренең чираттагы сменасы кызган чак иде. Бик матур җәйге көн. Кояшлы алан һәм дымсу урман кочагындагы гармонияле мизгелләрле озайтасы килде. Шул чакта башыма табигатьне саклауга багышлаган берәр проект булдырырга кирәк, дигән уй килде. Табигать бит чынлыкта бик нәзберек, сизгер, – дип искә ала «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбе җитәкчесе Елена Вальцефер.

Әйләнә-тирә мохитне саклауның кайсы юнәлешләре аеруча актуаль икәнен белү өчен, Елена Татарстанның Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, шулай ук республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгына мөрәҗәгать итә.

– Ике оешма да фикеремә бик җылы карады, идеямне хупладылар. Без «Эко-Шкодники» дип аталган проект уйлап таптык, ә 2023 елда Президентның мәдәни инициативалар фонды безгә грант бирде.

Хәзер студия алдында торган бурыч – ел дәвамында 12 кыска метражлы фильм төшерү. Беренче ролик инде эшләнгән дә.

– Кыска метражлы фильм чүп-чарны сортларга аеру мәсьәләсенә багышланган. Яңа буын өчен бу көндәлек гамәлгә әйләнергә тиеш, ләкин файдалы гадәтне кечкенәдән тәрбияли башларга кирәк, – дип аңлата Елена Вальцефер. – Моннан тыш, көнкүреш калдыкларын сортларга дөрес аеру да кирәк. Киләсе фильмнар урман һәм паркларның, елга-күлләрнең пычрануы турында сөйләячәк. Хәтта бәйрәмнәрдә бик күпләп күккә очырыла торган гелийлы шарларның зыяны турында да фильм булачак. Болар барысы да «уйный-уйный өйрәт» принцибы нигезендә, балаларга аңлаешлы җиңел формада, юмор белән эшләнә.

«Шкодники» проекты коммерция проекты булып торса да, Президентның мәдәни инициативалар фонды ярдәме бәрабәренә, экопрограммада катнашкан өчен, бу сәләтле балалар бер сум да түләми. Моны ишле гаиләләрдән булган балалар өчен чын социаль лифт дип атарга мөмкин, чөнки яшь киноактёрлар, уен осталыгын үстерүдән тыш, иҗади һәм шәхси потенциалын, үз-үзләренә ышанычны, коллективта эш итә һәм конструктив аралаша белү сәләтләрен ача.

Хәерле сәгатьтә, балалар!

«ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбе V һәм VI Канн халыкара һәвәскәр һәм яшьләр киносы фестивальләрендә катнаша һәм призлы урыннар ала, республика күләмендә уздырыла торган дистәләрчә конкурс, балалар һәм яшүсмерләр иҗат фестивальләре лауреаты булып тора.

«Шкодники» киножурналының прокат таныклыгы бар, исеме һәм логотибы Интеллектуаль милек үзәге тарафыннан теркәлгән. «ДжуниорЛайф» аудиовизуаль әсәргә махсус хокукларга ия.

Фото «ДжуниорЛайф» мәктәбе тарафыннан тәкъдим ителде. РЕКЛАМА

ЗАМАНЧА ГӨЛБАКЧА

Ләйсән Шлайфер, «Неолит-Дизайн» ландшафт дизайны студиясе генераль директоры

«Гармония утравы», «рәхәт урын», «гаилә белән ял итү почмагы»... Ландшафт дизайны турында сүз чыкканда, без еш кына һаман шул сүзләрдән файдаланабыз. Тик бу бит берничек тә инновацияләрдән баш тарту өчен сәбәп була алмый. Модалы ландшафт дизайнын яңа технологияләр, заманча материаллардан башка хәзер күз алдына да китереп булмый.

Инновацияләрдән файдалану билгеләнеше төрле булган мәйданчыклар булдыру һәм аны карап тотуны җиңеләйтү мөмкинлеген бирә. Мәсәлән, автоматлаштыру һәм акыллы идарә итү системалары су сибүне, яктыртуны, дизайнның башка нечкәлекләрен контрольдә тота. Интеллектуаль технологияләр шулай ук мохит параметрларын ерактан торып көйләү мөмкинлеген бирә.

Бүген проектны ясый башлаганда ук виртуаль чынбарлык һәм 3D-модельләштерү ешрак кулланыла. Шуңа күрә проектның нинди булып чыгасын күз алдына китерү дә бик җиңел. Нәтиҗәнең азагын алдан ук күргәч, проектлаштыруның башында ук детальләргә игътибарны арттыру мөмкинлеге туа.

Бүген уңайлылык иң мөһиме санала, шуңа күрә кояш нурларыннан саклый торган экраннар һәм җылытыла торган сукмакларга ихтыяҗ зур.

Яңа юнәлешләр арасында – ачык һавада эш мәйданчыклары булдыру. Бу заманча трендның чагылышы: өйдә эшләүчеләр саны һаман арта бара.

Башка трендларны да санап китик.

ЕЛ ӘЙЛӘНӘСЕ РӘХӘТ БАКЧА

Елның бар фасылларында да бакчаның декоратив булуына ихтыяҗ арта. Моның өчен мәңге яшел ылыслы һәм яфраклы үсемлекләр, матур кайрылы куаклар, җете җимешле агачлар, шулай ук кыяклылар сайлана. Әлеге детальләр бакчаны чәчәкләрне кар каплагач – көзен һәм кышын бизәп торачак.

ВЕРТИКАЛЬ ЯШЕЛЛӘНДЕРҮ

Хәзер шәһәрләрне дә, йорт яны территорияләрен дә вертикаль яшелләндерү көннән-көн күбрәк модага керә бара. Дивар, балкон, түбәгә утыртылган үсемлекләр җирдә күп урынны янга калдыра, йорт фасадын бизәү яки бакчаны зоналарга бүлү мөмкинлеген бирә. Моңа иң гади мисаллар – үрмәле гөлләр, диварга кашпо-тартмалар элеп кую һәм вертикаль түтәлләр. Ә иң югары пилотаж исә – Сингапурдагы Park Royal on Pickering кунакханәсе, аны дөньяның чираттагы могҗизасы, дип йөртәләр. Анда тропик урманнар бинаның фасадында һәм түбәсендә «үсә».

«КАРАУЧЫСЫЗ» БАКЧА

Мондый бакчада җирле талымсыз культураларга өстенлек бирелә. Үсемлекләрне бер-берсенә шактый якын итеп, күпләп утырталар.

Ә менә юл-сукмаклар уйланылган, нык, матур булырга тиеш, газонны да яхшылап тәрбияләү таләп ителә.

«Неолит-Дизайн» ландшафт дизайны студиясе үз тармагында 2006 елдан бирле мәгълүм. Шул вакыт эчендә компания төрле бәядәге 317 дән артык проектны гамәлгә ашырган. Штатта тәҗрибәсе 15 елдан артыграк булган хезмәткәрләр эшли. Башкарылган эшкә 2 ел гарантия бирелә.

Дизайн-проектка заказ бирү өчен, **neolitkazan.ru** сайтына кереп, проект сайларга һәм **+7 987-297-06-16** телефонына шалтыратырга гына кирәк.

Студия проектлары арасында түбәндәге объектларның ландшафт дизайны бар:

- Казан, Су спорт төрләре сарае
- «Казан Арена» стадионы территориясе
- Казан теннис академиясе
- Казан, Ишкәкле спорт төрләре үзәге
- Казан, Көрәш сарае
- «ТАИФ» компаниясе бинасы, Казан, Щапов ур., 27
- Казан, Яңа Савин һәм Совет районнарындагы скверлар
- «Лицей-инженерлык үзәге»: мәктәпкәчә төркемнәр, башлангыч мәктәп һ.б.

Казан шәһәре, Җиңү проспекты, 18а, 1 нче бина

«Неолит-Дизайн» ландшафт дизайны студиясе фотосы. РЕКЛАМА

«ҖИТӘКЧЕЛЕК – ҖАВАПЛЫЛЫК УЛ»

Гомәр Даутов

Татарстан җирлегендә меңьеллык тарихка ия булган шәһәрләр күп түгел. Алабуга – шуларның берсе, бу ил һәм дөнья фәнни җәмәгатьчелеге тарафыннан танылган факт.

Казан ханлыгы яуланганнан соң бу уңдырышлы туфраклы, көн итәргә гаять уңайлы төбәккә рус крестьяннарын күпләп күчереп утырта башлыйлар. Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли, акыллы урыс агае, зур елгалар буенда икмәк җыю нокталары ачып, аны зур шәһәрләргә сату белән шөгыльләнә. XIX гасырның икенче яртысында Василий Стахеев Идел һәм Чулман елгалары буйлап икмәк белән сәүдә итүне үз кулына ала. Аның хатыны Глафира Стахеева 1898 елда Алабугада хатын-кызлар өчен Епархия училищесы ачып җибәрә. 1918 елда – татар укытучылар семинариясе, соңрак педагогик техникум булып үзгәртелгән, ахыр чиктә институт статусын алган бу уку йорты озак еллар Чулман аръягы төбәгенең белемгә омтылучы яшьләре өчен мәгърифәт үзәге булып тора. 2011 елдан исә, Казан федераль университетына кушылып, яңа заман таләпләре куйган югарылыкта эшләвен дәвам итә.

Шул ук Алабуга уку йортыннан аерылып чыккан Чаллы педагогика институтыннан китеп, Алабугага эшкә урнашканда факультет деканы Альберт Зөфәр улы Нигамаев, әлбәттә, беренче эш итеп мине директорга алып керде. Елена Ефимовна Мерзонның татарча чиста сөйләшүенә шул чакта ук

Фотолар автордан алынды

исем китте. Кабинеттан чыгуга, деканның җиңеннән тартып туктаттым:

– Кем ул? Татарча ничек шулай яхшы сөйләшә?

Нәрсәнедер белмәгәнен беркайчан да күрсәтми торган Альберт Зөфәр улы бу юлы да эшлеклелек артына яшеренде:

– Әтисе татарча әйбәт белгән аның. Әнисе татар. Син хәзер документларыңны алып кил дә, кафедрага менеп, йөкләмәләрне карый башла...

Ләкин яңа гына танышкан күркәм ханымның «безнеңчә» белүе бөтен аңымны биләп, моның серенә төшенү омтылышы тудырган иде инде. Соңрак мин директорыбызның әтисе гаять моңлы итеп татарча җырлаган, республиканың күренекле сәнгать әһелләре белән аралашып яшәгән, югары җитәкче постлар билэп, хезмәттәшләре хәтерендә якты сәхифәләр калдырган Ефим Дмитриевич Мерзон булуын белдем һәм бу турыда документаль повесть та чыгардым, ул «Казан утлары» журналында дөнья күрде.

Кафедра мөдире булып эшләгән вакытта миңа директор белән иртәнге киңәшмәләрдә, гыйльми советларда еш очрашырга туры килә иде. Кайнаррак холыклы булса да, ул һәрвакыт әңгәмәдәше сүзенә колак сала, китергән факт-мисалларны исәпкә ала, һәр мәсьәләнең, кем әйтмешли, төбенә төшеп, эшнең асылын аңламыйча тынычланмый.

– Без үскәндә һәрвакыт әнидән «Сез бит Мерзон кызлары», ягъни сезнең начар булырга хакыгыз юк дигән мәгънәдәге сүзләрне ишетеп үстек, – диде иде ул бер әңгәмә вакытында.

Психологлар «Без барыбыз да тумышыбыз белән балачактан» дисә, халык шул ук фикерне «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр» дигән мәкаль белән раслап куя. Шуңа күрә бүгенге әңгәмәбезне мин шушы сораудан башладым.

– Елена Ефимовна, сез гаиләдә өч кыз, өчегез дә фән һәм мәгариф юлыннан киткәнсез. Нәрсә этәргеч булды моңа?

– Үз вакытында, яшь чакта, моңа бәлки бик игътибар да ителмәгәндер, хәзер исә, педагогик белемле кеше буларак, ышаныч белән әйтә алам: монда төп рольне әти-әни тәрбиясе уйнады. Без авылда үстек, минем күңелгә хәзер Ютазы районына караган Подгорный бистәсе Тукайга – Кырлай, Лермонтовка Тархан авыллары кебек гамьле һәм ямьле булып кереп калган. Әтиебез гомер буе җитәкче эшендә булса да, без ындыр табагында да эшләдек, мәктәптә укыганда бәрәңге алуда да катнаштык. Хәтерлим, сигезенчедә укыганда әти-әнидән, туган көн хөрмәтенә кырга бармыйм әле, дип сорадым. Рөхсәт итмәделәр, ләкин әти, төшке аш вакытында машинасына тәм-том төяп килеп, бөтен классны сыйлаган иде. Шул вакытта шатлыктан күзгә яшьләр килде, бөтен үпкәләр онытылды. Әтинең миңа шулай эшләнергә тиешле эшнең мәҗбүрилеген аңлата, шул ук вакытта сөендерә дә белүе – үзе бер сәнгать, минем өчен гомерлек сабак булды. Мин хәзер моны ничек үтимдер, белмим, моны башкалар бәяләргә тиеш.

Әни китапханәче булып эшләде. Беренче карашка җиңел эш булып күренсә дә, ул бик катлаулы хезмәт иде. Беренчедән, элек кеше күп укый иде, димәк, китап бирү, кабул итүне системага салып, бик төгәл алып барырга кирәк. Китап алган укучы һәрвакыт: «Бу нәрсә турында? Кызыкмы?» – дип сорый. Һәм хәтерләвемчә, әнинең җавапсыз калганы булмады. Эш сәгате төгәлләнеп өйгә кайтуга, әнинең икенче сменасы башлана: эти көн-төн эштә, маллар да бар, ашарга да әзерләргә кирәк. Без дә, бик кечкенәдән кул арасына кереп, әнидән хезмәт тәрбиясе алып үстек. Шуңа күрә апам Светлананың, педагогика фәннәре докторы дәрәҗәсенә ирешеп, бүгенге көндә Казан аграр университетында халыкара бүлекне җитәкләве, сеңлем Иринаның Чаллы медицина колледжында директор булуы табигый хәл дип саныйм.

– Сез Алабуга педагогика институтын тәмамлагансыз, хәзер аның җитәкчесе. Нинди булды бу юл?

– Янә этине искә алырга туры килә инде. Аның сөйләве буенча, бабам Дмитрий, танк гаскәре офицеры, сугышның беренче көннә-

КФУның Алабуга институты директоры Елена Мерзон.

Институтта студентларның татар театры түгәрәге дә эшли.

рендә үк һәлак булган. Бабамның әтисе исә, хатынын яклап, немец солдатына көрәк белән суга, һәм аны шунда ук атып үтерәләр. Әти, син кыяфәтең белән гел бабаңа охшагансың, характерың да шундый, райком секретаре булырсың, дип әйтергә ярата иде. Әти үзе, хуҗалыкчы буларак, партия номенклатурасы белән төрле вакытта төрле мөнәсәбәттә яшәде, ләкин һәрвакыт партиянең җитәкче һәм оештыручы ролен таный иде.

Институтта укуның беренче көннәреннән үк һәр проектта катнашып, студент тормышының бар кызыгын тоеп яшәдем. Комсомол үзенә күрсәтергә күп мөмкинлекләр бирде. Андагы эш мәҗбүриләп тагылмый, бөтенесе дә яшьлек ялкыны белән өретелеп, кызыклы бер чара итеп үткәрелә иде.

Һәр эшне җиренә җиткереп башкарырга гадәтләнгән кеше буларак, яхшы укытучы булырга теләдем, фәннәрне үзләштерү өчен өстәмә белем алырга да тырыштым. Әмма укытучы эшчәнлегенең чын мәгънәсендә гаять күпкырлы икәнлеген үзем мәктәп директоры булып эшли башлагач кына аңладым.

Ул вакыттагы шәһәр хакимияте җитәкчесе социаль мәсьәләләр буенча урынбасар итеп чакырды. Мин бу эшемдә яхшы тәҗрибә тупладым, аны чын җитәкчелек мәктәбе дип атар идем. Күпмедер вакыттан соң институтка директор булырга тәкъдим иттеләр. Бу педагогика институтының, КФУга кушылып, структура ягыннан да, эчтәлек ягыннан үзгәрешләр кичереп, зур бәхәсләр кузгаткан чор булды. Вакыт бу адымның үзен аклавын күрсәтте. Хәзер университет кампусларының үсеше, уку йортының иркен мөмкинлекләре карарның вакытлы һәм дөрес булуын тагын бер кат раслый. Соңгы ун елда Алабуга институты биләмәләрен киңәйтте, «Университет» мәктәбе, өстәмә белем бирү үзәге, колледж һәм фәнни коллаборация йорты ачуга иреште. Булачак укытучыларның педагогик практикасы өчен моннан да яхшырак база турында хыяллану мөмкин дә түгел. Бер әйберне төгәл әйтә алам: педагогик белем бирүнең мондый күпбаскычлы модуле илнең бер генә профильле вузында да юк.

– Бүген зур үзгәрешләр чорында яшибез. Ил һәр өлкәдә – җитештерүме ул, идеология юнәлешеме – үз юлын сайлый. Бу уку-укыту системасына да кагыламы? Кеше, шәхес анда нинди урын алып тора?

– Бер яктан караганда, мәгариф консерватив өлкә, чөнки ул шушы көнгә кадәр тупланган белем хәзинәсенә таяна. Икенче яктан килеп фикер йөртсәк, ул пәйда булган яңалыкларны балаларга беренче булып җиткерә. Педагог, фәлсәфәче Джон Дьюиның «Әгәр без бүген кичәге кебек укытсак, балаларның иртәгесе көнен урлыйбыз», дигән сүзләре бар. Мәгълүмат тапшыру чаралары үзгәрә, цифрлы һәм дистанцион технологияләр кулланып дәрес үткәрүнең төрле вариантлары барлыкка килә, уку-укыту системасы шул рәвешле динамик үсеш кичерә, ул укытучыларга гына түгел, балаларга һәм ата-аналарга да кагыла. Моны без «Университет» мәктәбе кысаларындагы институт һәм мәктәп укытучылары хезмәттәшлеге мисалында да күрәбез. Университет педагогларга төрле курслар, программа һәм семинарлар, конференцияләр аша һөнәри үсеш алу мөмкинлеге бирә. Әмма иң мөһиме – балаларны ярату кирәк, дип саныйм.

Безнең мәктәп укучылары өчен төрле түгәрәкләр эшли, алар ДНК роботлары җыя,

теплицада үсемлекләр белән тәҗрибәләр үткәрә, археологик табылдыкларны өйрәнә...

Ата-аналар да читтә калмый, алар өчен дә осталык дәресләре үткәрелә.

– Мөгаен, хәзер бирәчәк соравым алдагысы белән бәйледер: милли мәгарифнең киләчәген, татарча укытуның кирәклеген ничек һәм нәрсәдә күрәсез?

– Бу мәсьәләгә уңай карыйм. Күрәсез, ил үзенең тамырларына, традицион кыйммәтләргә кайта. Россиянең көче һәм байлыгы – күпмиллэтле халкында, аларның дус-тату яшәвендә. Милли һәм дини дуслыкның үрнәге буларак Татарстан турында күп сөйлиләр. Шуңа күрә без бу мәсьәләне берничек тә читләтеп үтә алмыйбыз. Хәзер институт тәмамлап чыгучыларның тормышта үзләрен табарга мөмкинлекләре зуррак булсын өчен, күп очракта ике профильле белем бирү өстенлек итә. Татарча белем алучыларга без дә шартлар тудырдык, «Инглиз теле, татар теле һәм әдәбияты» юнәлешендә белгечлек бирелә. Күп кенә студентлар инде чыгарылыш курсында ук мәктәптә эшли башлый, аларны көтеп торалар, бу белгечләргә мәгариф өлкәсендә ихтыяҗ зур. Соңгы вакытта татар бүлеге студентларына халык иҗаты буенча курслар да укыта башладык. Тел, сүз дә юк, халыкны милләт итеп саклаучы төп чара, ләкин аның рухын, дөньяга мөнәсәбәтен, фәлсәфәсен аңлар өчен, әдәбиятын, авыз иҗатын, сәнгатен дә белү кирәк. Республикабызда йола буларак каз өмәләре, кул эшләре конкурслары үткәрү әнә шул югарыда әйтелгәннәрне практикада тормышка ашыру өчен оештырыла бит. Үземне татар әдәбияты белән яхшы таныш дип әйтә алмыйм, ләкин мәктәптә укыганда концертларда катнашу, әниемә төрле чаралар оештыруда ярдәм итү тәҗрибәсеннән, аннан белгечлегем буенча тарихчы буларак шуны әйтә алам: татар сәнгате – кул эшләреме, гореф-гадәтләрме, йолаларымы – бик бай һәм серле дөнья. Гомәр Филгизович, сез ничек дисез әле: без ким түгел җирдә һичкемнән...

– Мин түгел, шагыйрь шулай ди.

– Шагыйрь дөрес әйтә. Әнә шул байлык – ул илебезнең уртак хәзинәсе, һәм безнең укучы яшьләребез Ватаныбызның бу кыйммәтләрен белергә тиеш.

– Үзем дә шушы уку йортында хезмәт куючы буларак, беләм, эш графигыгыз бик тыгыз. Җитәкче булу ул нәрсә: җаваплылыкмы, үзеңнең сәләтләреңне тормышка ашырумы...

– Беренче чиратта – җаваплылыкны курыкмыйча өстеңә алу. Халыкта «Күз куркыр – кул эшләр» дигән әйтем бар. Шуңа күрә, проблема нинди генә катлаулы тоелмасын, аны өйрәнә, тикшерә башлагач, хәл итү юллары да туа. Ләкин шунысы бар: хезмәткәрләренә бурыч куяр алдыннан һәр җитәкче беренче чиратта әлеге мәсьәләнең асылына төшенергә, үзе яхшылап аңларга тиеш, дип саныйм.

Шунысын да әйтеп үтик: институтта белемле, зыялы, үз өлкәләрен тирән үзләштергән белгечләр – педагог, психолог, тарихчы, филологлар эшли, ләкин һәр кеше – үзенчәлекле шәхес ул. Аларның эшчәнлеген заман таләпләрен, ихтыяҗларын үтәүгә юнәлтү, мотивация тудыру – җитәкченең бурычы.

Институтта 5000нән артык студент укый, 200ләп мөгаллим эшли. Югары уку йорты – үзе бер дөнья. Мондый зур коллектив белән эшләү, әлбәттә, катлаулы, ләкин кызыклы һәм мавыктыргыч. Һәр көнне институтка теләп барам, аның сере бар һәм ул бик гади – мин үз эшемне яратам.

– Кеше бит гел хезмәттә генә яши алмый: сез әле ике балага әни дә... Ял вакытларыгызны ничек үткәрәсез?

– Балалар инде үстеләр, Аллаһка шөкер, мөстәкыйль тормыш алып баралар. Шулай булса да, алар барыбер миңа бала булып, иң кадерле, якын кешеләрем булып кала. Әлбәттә, ял көннәрендә бергәләп иртәнге аш, кая да булса бару, сөйләшеп утыру кебек гаилә традицияләрен сакларга тырышабыз. Мондый вакытларда мин ял итәм, тормыш, эш мәшәкатьләреннән арынып торам.

Моннан тыш, өйдә кайнашырга, бакчада эшләргә, теплицада вакыт үткәрергә яратам. Татар милли ризыклары бик ошый, кул җиткәндә рәхәтләнеп пешеренәм. Тормышымны спорттан башка күз алдына китерә алмыйм, һәм инде, әлбәттә, балачактан канга сеңгән китап уку да зур шатлык китерә.

Традицион көзге бал.

ҮЗЕБЕЗНЕҢ СӘЙДӘ АПА

Руфия Фазылова

«Бөтен кеше мулла нәселендә тумый бит». Әңгәмә барышында Сәйдә абыстай Аппакова бу җөмләне әллә ничә тапкыр әйтте. Очрашудан кайтып, язарга утыргач, аның бу сүзләре янә искә төште. Белем, тәрбия, фикер сөреше – атаклы нәсел дәвамчысы шундый булырга тиештер...

«БИШ ЯШЬТӘН НАМАЗДА!»

Абыстай сүзен ярата ул, аңа килешеп тә тора. Утыз елдан артык заводта эшләгән югары белемле инженер Сәйдә Аппакова, лаеклы ялга чыккач та, бер көн дә эшләми – тормышын үзгәртә. Нәкъ шул елларда республика хөкүмәте гарәп теленнән тәрҗемәчеләр әзерли торган курслар оештыра. Сәйдә апа шунда укырга керә. Һәм шул ук вакытта 2 нче татар гимназиясендә диннәр тарихы һәм гарәп теле, әдәп-әхлак дәресләре алып бара башлый.

– 1982 ел булгандыр... Миңа «абыстай» дип эндәшә, Коръән ашларына чакыра башладылар, – ди Сәйдә апа. – Баштарак «абыстай» сүзен кушамат дип, авыр кабул иттем. Ничектер ул мулла хатынына әйтелә торган сүз дип уйлый идем. Ә ул гыйлеме булган кешегә дә бирелә икән. Мәрҗани мәчетенең имамы Габдулла хәзрәт бу исемнең дәрәҗә икәнен аңлатты. Шуннан соң әлеге сүзне ярата башладым.

Сәйдә апаны әнисе өч яшеннән укырга, биш яшеннән намазга өйрәтә. Дин белән дөньяви фәннәрне ул әнә шулай кечкенәдән сеңдереп үсә. Әнисе берничә телне белгән мөгаллимә, әтисе атаклы мулла нәселеннән була...

– Әтиебез ягыннан 13 буын бабаларым мулла, мәзин булган, – дип горурланып сөйли Сәйдә Аппакова. – Безнең гаилә Мәрҗани мәчетендә хезмәт иткән күп имамнар белән аралашып яшәде. Авылда яшәсәк тә, өйгә кем генә килми иде...

Фото: Лилиана Вәлитова

Апас Үзәк китапханәсендә узган очрашу. 2024 елның марты.

«ӨЧ ТАПКЫР ХАЖДА БУЛДЫМ»

Сәйдә абыстай өч тапкыр хаҗга бару бәхетенә ирешә. Ләкин изге җиргә иң беренче сәяхәте бигрәк тә онытылмаслык булган. Ул очракны бер могҗизага тиңләргә мөмкин...

– 1995 ел. Хаҗга барырга төркем җыялар дигәч, хәләл җефетемә кайтып әйттем. «Иң зур хыялың бит, бар», – диде ул. Бердәнбер проблема – акча җитми. Ирем әйтә: «Быел бармасаң, тагын андый мөмкинлек чыгамы, юкмы, әйдә, фатирны сатабыз», – ди. Әнә шулай өч бүлмәле фатирны икелегә алыштырып, калган акчага хаҗга барырга ниятләдем. Алучысын таптым. Урта яшьләрдәге матур гына татар ире иде. Фатирны ни өчен сатарга уйлаганыбызны әйттем. Ул башта бик аптырады инде.

Икенче көнне әлеге ир Сәйдә абыстайга 30 мең сум акча алып килә: «Сезгә миннән сәдака, хаҗга барырга бу. Фатирыгызны сатмагыз, игелек эшлисем килә», – ди. Баксаң, әлеге мәрхәмәтле ир әнисенә кайтып сөйләгән: «Анда бер апа фатирын сата, хаҗга барырга акчасы җитми», – дигән. Менә шуннан ана кеше улын зур изгелек кылырга күндергән... Иң гаҗәбе, Сәйдә апага күптәнге хыялын тормышка ашырырга ярдәм иткән шул ир-ат берничә елдан лотереягә фатир откан.

«КҮЛМӘК ҖИРДӘН СӨЙРӘЛМӘСЕН»

Сәйдә абыстай иң беренче нурлы йөзе, матур, үзебезчә киенгән булуы белән игътибарны җәлеп итә. Аның үзенә дә бу хакта еш әйтәләр икән. Башка милләт вәкилләре дә соклануларын белдереп китә.

Өс-башына Сәйдә абыстай бик җаваплы карый. Беренче чиратта чисталык, пакьлек һәм үзебезчә итеп бәйләнгән яулык, гаурәт урыннарны каплый торган күлмәк-ыштан.

– Мөслимәләргә «өч бармак илле» чәч күрсәтергә рөхсәт ителә, – дип фикерләре белән бүлешә абыстаебыз. – Ризаэтдин Фәхретдин, Шиһабетдин Мәрҗаниләрнең хатыннары белән төшкән сурәттә чәч күренә. Әнинең берничә сурәте сакланган, аның да аз гына чәче, муены күренә. Ә муен асты – бугаздан ябык. Муен биш бармак илле ачык булса да ярый, әгәр томаланып бетә икән, тын алу авырлаша. Шуның өчен дә безнең әбиләр бөтенләй капланып йөрмәгән. Күлмәк озынлыгына килгәндә, ул җирдән биш бармак калынлыгы өстә булырга тиеш. Өстерәлсә, пычрак җыеп йөри, ул инде ару дигән сүз түгел.

«БЕЗ МӘҢГЕГӘ КИЛМӘГӘН...»

Сәйдә Аппакова Казанның Ямашев урамында яши. Фатирын күреп ис китте: бер артык әйбер юк, монда һәр әйбер зәвыклы. Хәер, фатирын гына түгел, үзе яшәгән йортны да карап, тәртипләп тора икән. Хәтта кышын да подъезд төбенә чыгып кар да көри әле.

– Узган ел ишегалдына асфальт та җәйдердем, – дип көлде Сәйдә апа. – Алайса йөри торган түгел иде. Без ярар, таяк белән булса да узарбыз, бала арбасы тарткан әниләр бар, аларга читен. Идарә итү оешмасына атна саен барам, туеп беткәннәрдер. Тәртип, чисталык булсын дип таләп итәм.

Сәйдә апа үзенә карата да бик таләпчән. Аны әле дә атна саен төрле җирләргә чыгыш ясарга чакыралар. Ә ул аларга бик ныклап язмача әзерләнә: хәтта башта планын төзи.

– Монда минем һәр чыгышым теркәлгән, – дип түрдәге шкафын ачып күрсәтте абыстай. – Доклад сыман язам да, аны темаларга бүлеп, папкаларга теркәп куям. Миннән соң да югалмасын дип. Әти-әни өйрәткән үгет-нәсихәтләр, тәрбия-әхлак турында алар. Без мәңгегә килмәгән, белгәнеңне бирергә кирәк. Коръән дә шулай куша...

«УРАМ СЕБЕРҮЧЕ ДИП УЙЛЫЙЛАР»

Сәйдә апа җәйгә 90 яшен тутыра. Сөбханаллаһ, дип уйладым: әйбәт йөри. Бишәр сәгать халык алдында чыгыш ясый икән. Режим буенча яши: тик ашауга әллә ни исе китми. «Бер пешергән ашны атна буе да ашыйм», – диде ул. Чәчәкләр ярата, шуның өчен дә җәй буе үзе яшәгән йортның бакчасында кайнаша. Аннан ул гөлбакча ясаган. Иртә-кич үзенең фатирыннан чәчәкләренә чиләк белән су ташый.

– Бу яшьтә алай йөрергә авыр түгелме соң? – дидем Сәйдә апага.

– Авыр да инде, тик башкача булдыра алмыйм. Чисталык, тәртип, матурлык яратам. «И Аллаһы Тәгаләм, шушы эшләрне башкарырга көч бир. Сиңа гына тәвәккәлләп чыгам», – дип, башта иман китерәм. Аннан чыгып эшлим...

Әнә шулай итеп ел әйләнәсе яшәгән йортын карап тора ул. Күзен җиргә коелган яфракларны себереп, әллә ничә капчыкка тутырып, чүплеккә илтә икән. Аны танымаучылар: «Бу әби картайган көндә дә урам себерүче булып эшләп йөри, акчасын балаларына биреп барадыр инде, мескен», – дип китәләр икән. Тик Сәйдә апаның аңа исе китми, чөнки күңеле кушканга, Аллаһ ризалыгы өчен эшли.

– Рәхмәт әйтүчеләр дә күп, – ди Сәйдә апа. – Аеруча чәчәкләремә сокланып карап торалар. Ә мин кешеләргә шатлык китерә алуыма сөенәм.

«ХАТЫН-КЫЗ АЗРАК ХӘЙЛӘКӘР БУЛЫРГА ТИЕШ»

Сәйдә апаны тыңлау дәү әни белән сөйләшкән кебек. Ул сиңа үгет-нәсихәтләрен бирә, ә син шуларны тыңлап, сеңдереп барасың. Хатын-кыз буларак алар бигрәк тә кыйммәтле тоелды.

– Кыз балаларны элек-электән ир хатыны булырга өйрәткәннәр, – ди Сәйдә апа. – Кызганыч, бүген аналар ул әйбергә игътибар бирми. Ә мөселман илләрендә, кыз бала тугач та, аны гаилә тормышына әзерли башлыйлар. Безнең хатын-кызларны кызганам мин, чөнки алар эш атына әйләнде. Килен булып килгәч тә, каенатам минем тыз-быз йөгереп йөрүемне күргәч: «Килен, син болай эшләп йөрсәң, бер-ике елдан чиргә сабышачаксың. Иреңне дә эшкә өйрәт, азрак хәйләле бел. Аш пешергәндә, ирең бәрәңгесен чистартсын, белмәсә, өйрәнер, янында тот. Базар, кибеткә дә ирең барсын, авыр сумкалар күтәреп йөрмә», – диде. Хәзер шуны кайта-кайта уйлыйм: акыллы ир булган каенатам. Чынлап

Очрашу истәлеге.

та, бергә тормышны алып барсаң күңелле дә, җиңел дә бит. Мисал өчен, баштарак хәләл җефетеңә ипи кисәргә кушасың, аннары бәрәңгесен туратасың. Бер дә булмаса, иргә газета тоттырып, кычкырып укырга сорарга була. Хатын-кызның аның газета укырга вакыты булмый, ә ирнең шәһәрдә башка эше бик юк. Сиңа да файда, аңа да кызык.

Мәрхүм ирем белән начар яшәмәдек, шулай да төрле чак булгандыр. Ачуым чыкканда, шкафтагы әйберләрне ишеп төшереп, аннан аларны кабат киштәләргә тутыра идем. Җырлап җибәрсәң дә тынычланасың. Шкаф җыештырасың килмәсә, чәй куй. Чәй кайнап чыккач, табын янына гаилә җыела. Ачуланышкан вакытта җәмәгатем гел чәй куя иде, табын дуслаштыра...

«УЙЛАР ЯКТЫ БУЛСЫН...»

Сәйдә апа фәлсәфәче дә. Ул Коръән аятьләрен тормыш белән бәйләп, гади итеп аңлатып сөйли. Башка яулык бәйләмәсәң, начар энергия килә, ә начар уйлар чынбарлыкка әйләнә, дип саный.

Сәйдә апа шөкерана кылып яшәргә чакыра. Бүгенге җәмгыять шуңа корылган – дөнья куабыз. Әнә шуның аркасында гади генә әйберләргә соклана, сөенә белми башладык кебек...

– Берәүгә Аллаһы Тәгалә байлык бирә, берәүгә – фәкыйрьлек, тегесен дә, монысын да гыйбрәт алыр өчен бирә, – дип дәвам итте фәлсәфәсен Сәйдә апа. – Кеше ашау-эчүен генә түгел, йөрәген, җанын да тәрбияләргә тиеш. Нәрсә дигән сүз бу? Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп, Коръән аятьләренә таянып тормыш алып бару ул.

Адәм баласының башына көненә 6 меңләп фикер килә икән. Шулар арасыннан начарын кертмәскә тырышырга кирәк.

– Ә ничек? – дим.

– Акылны, уйны контрольдә тотарга кирәк. Адәм баласы акыллы җан иясе бит. Аның өчен рухның көчле булуы, Аллаһы Тәгаләгә ышану кирәк. Галимнәр дә әйтә: йөрәгебезнең магнит кыры ясарлык көче бар. Ә уйларыбыз энергиягә әверелә. Башыбызда матур уй булса, үзеннән-үзе шуны алабыз, начар уй булса, начары килә һәм шул тормышка да аша. Әлхәмдүлилләһ, дип яшик: кибеткә чыксак – ни генә юк, кырдан бәрәңге чүпләмибез, урманга утынга йөрмибез, коедан су алмыйбыз. Булганына канәгать итеп, һәр көнгә сөенеп яшәргә кирәк.

БАЛА ТӘРБИЯСЕ

Әңгәмә барышында тагын шуңа игътибар иттем: Сәйдә апа бик еш әти, әнисен, аларның сүзләрен искә ала. Каян барысын да хәтердә калдырып, алардан тирән мәгънә эзләп таба икән, дип хәтта гаҗәпләндем дә. Дөрес тәрбия шушы була торгандыр.

Әңгәмә очрашудан соң да дәвам итә.

– Борынгылар яхшы психолог булган, – диде Сәйдә апа, бала тәрбиясе турында сүз чыккач. – Әти эш кушса, аны контрольдә тота иде, әйтте дә бетте түгел. Шуңа күрә ул кушканны җиренә җиткереп эшли идек. Өч яшеннән гаиләдә вазыйфам бар иде: өстәлгә кашык, тәлинкәләр тезү. Аш пешеп чыгуга, сәке өстеннән сикереп төшәм дә тиз генә шуны эшли башлыйм. Үсә-үсә бу вазыйфалар артты, әлбәттә. Баланы эш белән тәрбияләргә кирәк, иң дөрес юл шул.

Сәйдә апа бүген балаларны дөрес тәрбияләмибез, дип саный. Беренчедән, балага әдәп-әхлак тәрбиясе бирмибез, икенчедән, артык иркәлибез...

– Ул яктан яһүдләр үрнәк, – ди Сәйдә абыстай. – Яһүд халкы иң беренче ата-ананы хөрмәт итәргә өйрәтә. Ә без ничек тәрбиялибез? И, балага тырыша-тырыша өчпочмак-пәрәмәчләр пешереп ашатабыз, матур киемнәр алабыз, мәктәптә начар укыса, репетитор яллыйбыз, һәм бу шулай тиеш кебек кабул ителә. Инде үсеп буй җиткәч: «Әтием, әнием, олы рәхмәт сезгә!» – дип тә әйтә белмәгән балаларга никахтан соң фатирга акча бирәбез. Безнең тәрбия шушы! Ә яһүдләр 1 сумлык эшли, 100 сумлык сөйли. Ә без, киресенчә, 100 сумлык бирсәк тә, 1 тиенлек сөйлибез...

...Татар – акъэбиле халык. Алар балалар өчен дә, олыларга да үрнәк булган. (Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясе юкка гына шулай халык күңеленә кермәгәндер.) Шөкер, бүген дә Сәйдә Аппакова кебек акъэбиләребез бар. Һәм мөмкин кадәр аларның үгет-нәсыйхәтләрен тыңлап, укып калсак иде, чөнки аларда чынлап та зур хакыйкать ярылып ята.

Татарстанда газета-журналларны вакытында китерүдәге җитешсезлекләрне төзәтү максатында «Татарстан почтасы» Федераль почта элемтәсе Идарәсенең «кайнар линиясе» эшли башлады.

Моңа бәйле сораулар туган очракта атнаның эш көннәрендә 09:00 сәгатьтән 17:00 гә кадәр 8 937 0404521 номерына шалтырата аласыз.

Реклама 16+

Татарстан почтасы
Контакт

«Кайнар линия»нең чатына QR-код аша да узарга була.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-79
8-9600-487-900
8-9172-740-352

Реклама 16+

игелекле эшләр / мәңгелек кыйммәтләр / акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Кем ул Чистайның батыр кызы

Китап киштәсендә **нәрсәләр** бар

Торнаязга торналар **кайчан** килә

ЧИСТАЙНЫҢ БАТЫР КЫЗЫ

Илдус Заһидуллин

Хатын-кызларның иҗтимагый тормышка тартылуын, үзләренең хокукларын яклап, газета-журналларда мәкаләләр бастыруын, Риза Фәхретдин әйткән милләт аналарын әзерләү юлында мөгаллимә буларак хезмәт куюын, милләтпәрвәр балалар тәрбияләүгә алынуын XX гасыр башында татар яңарышы хәрәкәтенә хас мөһим күренешләр дип атарга була.

Сүзебез төрки халыклар арасында беренче булып татар хатын-кызлары башлаган шушы хәрәкәтнең күренекле вәкиле, үз милләтен үстерү юлында башкарган эш-гамәлләре белән халык хәтерендә якты эз калдырган шәхес – Фатыймаи-Фәридә Нәүрүзова турында.

Фатыймаи-Фәридә 1889 елның 25 февралендә Чистай шәһәрендә галантерея товарлары белән сәүдә итүче Мортаза Әхмәт улы Ваһапов һәм Казан сәүдәгәре гаиләсеннән чыккан Фатиха ханым гаиләсендә дөньяга килә. Ваһапов, шәһәр татарлары вәкиле буларак, 18 ел дәвамында Чистай мещаннар управасы идарәсе әгъзасы була, шәһәр думасына да сайлана, шулай ук кайбер елларда каладагы мәдрәсәнең попечителе сыйфатында дини уку йортына матди ярдәм дә күрсәтә.

Мортаза бай кайбер нәселле гаиләләр гадәте буенча кызына Фатыймаи-Фәридә дип исем куштыра.

Әбисенең зиһенле кызга 3 яшеннән үк догалар, дин сабагын өйрәтә башлаганлыгы мәгълүм. 1892–1894 елларда сәүдәгәр гаиләсе белән ике тапкыр Төркиядә яшәп ала. Икенче тапкыр барганда 5 яшьлек Фатыймаи-Фәридә төрек башлангыч мәктәбенә йөри. Чистайга кайткач, абыстайда дин сабагын үзләштерә. Әтисенең, күрәсең, бердәнбер баласына яхшырак белем бирәсе килгәндер: 1895 елда ул аны кышкы айларда Казанга җибәреп, абыстайда тәҗвид белән Коръән укырга өйрәтә.

Чистайда Фатыймаи-Фәридә Закир ишан улы Ибраһим Камаловтан, аның 6 сеңлесе белән бергә, йорт шартларында дәрес тыңлый башлый. Шулай укып биш ел узгач, 1901 елны Ибраһим белем алырга Каһирә университетына китә. Шул сәбәпле Мортаза бай 1901 елны кызын кабат Казанга, бу юлы Галимҗан Баруди хатыны Маһруй абыстайның җәдит мәктәбенә илтә. Ибраһим хәлфә дәресләреннән соң яшүсмер кызга биредәге дин дәресләре кызыксыз тоела.

Фатыймаи-Фәридә, кабат Чистайга кайтып, ишан кызлары белән бергә, йорт шартларында яңа дамелладан дөньяви белем ала (гарәп теле синтаксисы, тарих, география, әдәбият). 1904 елның март аенда Каһирәдән кайткан Ибраһим кабат сеңелләре һәм Фатыймаи-Фәридә белән дәресләр башлап җибәрә, география, математика, тарих, табигать белеме, төрек, фарсы, гарәп, татар телләрен өйрәтә. Махсус рус мөгаллимәсен яллап, рус телен дә укыттыра башлый.

Ләкин яңа уку елыннан Мортаза бай җитеп килгән кызының русча укуын туктата, шуңа да карамастан, Фатыймаи-Фәридә, сабакташларыннан үткән дәресләрен сөйләтеп, үзлегеннән русча белемен арттырырга тырыша.

Актив яшүсмер кыз 1903–1904 елларда өендә, туганнарын һәм дус-ишләрен җыеп, 5–7 укучыга җәдитчә дәрес бирә, шул рәвешле иҗтимагый эшчәнлеген башлап җибәрә. Шушы уку елында йортларында яшәп,

Фотолар автордан алынды

Чистай кызлар мәктәбендә укыган Хәдичә Дунаева исемле кызга 15 яшьлек Фатыймаи-Фәридә сабуллашканда шундый нәсихәт бирә: «Бер милләтнең тәрәккыяте тәртипле гаиләләр аркылы гына буладыр. Гаилә эчендә иң зур эш күрсәтүче – хатындыр. Менә без шул вазифаны үтәргә әзерләнергә тиеш».

1905–1906 елларда Чистайда булып узган вакыйгалар Фатыймаи-Фәридәнең тормыш тәҗрибәсен баета. Әйтергә кирәк, Чистай өязеннән чыккан радикаль фикерле татар яшьләре социалист-революционерларның сәяси программасын якын итә. Бу төркемгә Гаяз Исхакый, Ибраһим Камалов, сәүдәгәр Бадамшин һәм тагын берничә кеше керә. Югарыда исемнәре аталган шәхесләр апрель аенда Санкт-Петербург түрәләренә шәһәр мөселманнары исеменнән петиция тапшырырга бара. Муса Бигиев һәм ишан Закир Камалов кызы Әсмаи-Галиянең туй мәҗлесенә туры китереп Чистайга чакырылган 500 җәмәгать эшлеклесе 1905 елның 20–22 май көннәрендә, киңәшмәләр үткәреп, сәясәт һәм милләт мәсьәләләрен тикшерә. Радикаль карашлы татар яшьләре, 20 май көнне кич белән Фатыймаи-Фәридәнең этисе Мортаза Ваһапов өенә җыелып, Габдерәшит Ибраһимовны каты тәнкыйтьли. Азактан Россиядә сүз, вөҗдан һәм дин тоту, җыелышлар үткәрү һәм союзлар төзү кебек демократик ирекләр, шәхеснең һәм торакның кагылгысызлыгы, шулай ук дәүләт идарәсен барлык сайлаучылар өчен гомуми һәм тигез, яшерен һәм туры сайлаулар үткәреп оештыруны таләп иткән резолюция кабул итәләр. Бу карар үзәк рус газеталарында басылып та чыга.

Сәяси вакыйгалар Фатыймаи-Фәридәгә дә тәэсир итми калмый, билгеле. Кыз өенә эсерларның листовкаларын да алып кайткалый, Чистай төрмәсенә ябылган сәяси тоткыннарга ярдәм оештыруда да катнаша. Бу вакыйгалар аның иҗтимагый актив һәм гаделлекне яклаучы икәнлеген раслап тора.

Чистай шәһәренең бай гаиләсендә үсеп, милләтенә хезмәт итүне максат иткән Фатыймаи-Фәридә феноменының сәбәпләре нидә дигән сорауга да җавап биреп карыйк.

Беренчедән, руслар арасында татар мәнфәгатьләрен яклап йөрүче сәүдәгәр этисенең көчле холкы да, аның кызына яхшы белем бирергә, яңа заманга әзерләргә омтылуы да һәм өйләрендәге иркен аралашу атмосферасы тудыруы да мөһим роль уйнаган, кызга үрнәк биргән дип уйларга кирәк.

Икенчедән, киң карашлы Ибраһим Камалов мәктәбе: мөгаллимнең фикер сөреше, күзаллаулары шулай ук әһәмиятле булган. Дөньяви белем алудан тыш, Фатыймаи-Фәридә «Ни өчен туган халкым алдынгы түгел?» дигән сорауга җавап эзли башлый, үзлегеннән белем алу һәм мөстәкыйль фикерләү кебек мөһим сыйфатларны үзендә тәрбияли. Ул татар халкын алдынгы милләт итү фикерен үзәккә куйган мәгърифәтчелек идеологиясен үз итә.

Өченчедән, яңа фикерләр белән танышып бару мөмкинлеге: җитеш тормышта яшәүче кыз төрекчә романнар укырга гадәтләнә, татар, төрек, гарәп, фарсы һәм рус телләрендәге китаплардан тупланган шәхси китапханәсен даими рәвештә тулыландыра, Төркиядән газета-журналлар, Бакчасарайдан «Тәрҗеман»ны алдыра. Бу мәгълүмат чыганаклары аны алгарыш юлына чыккан татар дөньясының омтылышлары белән бер дулкынга көйли.

Дүртенчедән, кызның характерында җәмәгать эшлеклесенә хас булган активлык, җаваплылык, яңалыкка һәм белемгә омтылу, аралаша белү һәм харизма, башкаларны үз фикеренә ышандыру көче кебек сыйфатлар да бу очракта бик тә кирәкле шартка әверелә.

МИЛЛӘТКӘ ХЕЗМӘТ ИТҮ ПРОГРАММАСЫ ФОРМАЛАШУ

Беренче рус инкыйлабыннан соң сәяси эшлеклеләрне эзәрлекләүләр башлангач, бу елларда иҗтимагый активлык күрсәткән 67 яшьлек Мортаза Әхмәт улы Ваһапов, сәүдә эшен туктатып, хакимият игътибарыннан читтәрәк торырга ниятли: 1907 елның июнь аенда Самара губернасы Бөгелмә өязе Кәрәкәшле авылына барып төпләнә, җир сатып ала, соңрак тегермән дә төзетә.

Авылда укыта торган абыстай булмау сәбәпле, хатын-кызлар үтенечен кабул итеп, Фатыймаи-Фәридә дәреслекләр кайтартырга заказ бирә. Бу уңайдан 18 яшьлек мөгаллимәнең көндәлегенә язган сүзләре игътибарга лаек: «Бер нәрсә белмәгән кызларны укырга–язарга өйрәтәм, фикерләрен ачам, аларга газеталар укыйм, үзләреннән укытам. Шулай итеп, алар бик яхшы милләт анасы – балаларын яхшы тәрбия итә торган бер дәрәҗә мәгълүматлы кызлар булсалар, милләткә аз булса да хезмәтем тия; вөҗданым рәхәтләнә; үзләреннән мөгаллимнәр җитештерәм...». Бу сүзләр Риза Фәхретдиннең «Мәшһүр хатыннар» исемле китабының эпилогында әйтелгән фикерләрне күңеле аша үткәреп язылган.

Фатыймаи-Фәридә шушы фикерне тормышының максаты итеп ала. Милләт аналары әзерләү буенча мәгърифәтчелек программасын тормышка ашырып, бер ел эчендә искиткеч матур нәтиҗәләргә ирешә.

Ул татар вакытлы матбугатына хәбәрләр язуны гадәткә кертә. 1907 елның 17 сентябрендә 4–5 укучы кыз өчен җәдит мәктәбе ача, кичләрен авыл хатыннарын җыеп, аларга китаплар укый. Бер уку елында берничә шәкертен Нократ губернасы Иж-Бубый авылындагы кызлар мәдрәсәсенә укырга кирәклек итеп әзерли, балаларын шунда җибәрергә этиләрен күндерә. Чыннан да, аның фатихасы белән Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлаган кызлар гомерләрен укытучы хезмәтенә багышлый.

Чистай шәһәре. XX гасыр башы.

Мөгаллимә күрше авыл муллалары хатыннарын һәм кызларын да аваз ысулы белән укыту методикасына өйрәтергә вакыт таба. Нәтиҗәдә тирә-як авылларда кызлар өчен җәдит мәктәпләре ачыла.

ТОМСКИДАГЫ ИҖТИМАГЫЙ ЭШЧӘНЛЕГЕ

1908 елның августында Фатыймаи-Фәридә Томск каласында мөгаллим булып эшләүче Мөхәммәтвагыйз Нәүрүзов исемле татар егетенә тормышка чыга. Бай гаиләләрдән килгән яучыларны борып җибәреп укылган бу никахны соңрак кызның үзе теләгән тормыш рәвешен сайлавы дип бәяләүчеләр дә табыла.

Бу вакытта Томскида Идел һәм Урал төбәгеннән күченгән 2 меңгә якын татар яши. 1910 елда башланган 2 нче мәчет төзелеше 1916 елда тәмамлана. Татарлар, бистәгә тупланып яшәп, балаларына белем бирү турында кайгырта, шуңа күрә Каһирәдә белем алган Мөхәммәтвагыйз Нәүрүзовны укытырга чакыралар.

Яңа урынга күченгәч, якыннан аралашкан берәү үзенең истәлекләрендә Фатыймаи-Фәридәнең хәләл җефете Вагыйз әфәнде белән бергә Томскига күченүләрен «үзебезнең зәгыйфь вә аянычлы милләтебезгә хезмәт итүне беренче бурычыбыз дип беләбез, милләткә хезмәт итәчәкбез», дип аңлатканын язып калдыра.

Мөгаллимә мәхәлләнең кызлар мәктәбендә эшли башлый, ләкин абыстайлар һәм җирле мөселманнар яңа ысул белән укытуга шикләнеп карый. Фатыймаи-Фәридә барешми: 1909 елны башлангыч мәктәп мөгаллимәсе исеменә имтихан тотып, шәһәр идарәсеннән беркадәр матди ярдәм алучы беренче җәдит татар кызлар мәктәбен ача. Уку елы ахырында укучыларының белемнәрен күрсәтү, ата-аналарның теләктәшлеген алу өчен ачык имтиханнар оештыра. Көндәшләре «тырышлыгы» белән матди ярдәм туктатылса да, укытуын дәвам итә.

Замандашлары мөгаллимәнең зиннәткә кызыкмавына, гади киенүенә, һәрвакыт башына калфак киеп йөрүенә, «Кешелек киемдә түгел, гыйлем һәм эштә», – дигән сүзләренә игътибар итә.

Рус шәһәре мохитендә үскән Фатыймаи-Фәридәгә Томскидагы тормышка ияләнү кыен булмаган дип уйларга нигез бар. Ул рус зыялы хатын-кызлары белән якыннан аралаша, төрле мәгариф һәм мәгърифәт таратучы җәмгыятьләргә әгъза булып керә, алар уздырган чараларда катнаша, фикерләрен әйтеп чыгышлар ясый, университет укытучыларының халык өчен укыган лекцияләренә йөри. Үзлегеннән рус телен өйрәнүен дәвам итеп, кызлар гимназиясендә 5 сыйныф буенча имтихан бирә, максаты, өлгергәнлек аттестаты алып, киләчәктә университетка укырга керү була.

Гомумән, ул милләтнең алгарышына төрле яклап ярдәм итәргә ашыга. Әйтик, татарларның шәһәрдә ачылган «Тәрәккыюне ислам» җәмгыятенә беренче әгъза булып языла.

ЖУРНАЛИСТ ҺӘМ «СИБИРИЯ» ГАЗЕТАСЫ МӨХӘРРИРЕ

Шәһәрдә татар җәмгыятенең азсанлы булуына карамастан, Мөхәммәтвагыйз Нәүрүзов 1912 елда «Сибирия» исемле газета чыгаруга рөхсәт ала. Нәүрүзовлар гаиләсе тарафыннан «Сибирия» газетасын бастыру милләткә хезмәт итүнең яңа формасы буларак бәяләнергә лаек. Мөхәммәтвагыйз, күрәсең, оештыручыдан бигрәк, язучы һәм педагог булган. Шул сәбәпле газета белән җитәкчелек итү мәшәкате дә акрынлап мәктәптә укытучы Фатыймаи-Фәридә җилкәсенә төшә.

Мәктәптә укытудан, редакциянең эшен оештырудан тыш, Фатыймаи-Фәридә «Сибирия»дә «Хатын-кыз мәсьәләсе» исемле бүлекне алып бара. Татар милли мабугатында мондый даими бүлек яңалык булганлыктан, «Сибирия» хатын-кызлар арасында ихтирам казана. Төрле төбәкләрдән битараф булмаган шәхесләрдән килгән хатларны урнаштырып, Нәүрузова газетаны, Маһруй Мозаффария (Казан), Багъбостан ханым (Оренбург), Фәхрелбанат Сөләйманова (Түбән Новгород) һ.б. кебек, гомерләрен милләткә багышлаган мөгаллимәләрнең уй-фикерләрен тарату, киләчәк турында уй-

лану һәм бергә туплану үзәгенә эверелдерә. «Сибирия»нең 45 нче санында, хатын-кызларга мөрәҗәгать итеп, 8 сораудан торган анкета урнаштыра. Газетаның 1913 елның 15 февраль санында редакциягә килгән утыздан артык җавап хатына анализ язый.

Бу яктан Фатыймаи-Фәриդәнең үз фикерләре дә аерым игътибарга лаек. Журналист еш кына мисалга Риза Фәхретдиннең «Мәшһүр хатыннар» исемле хезмәтеннән хәлифәләр заманында мөселман мөдәррисәләр, мөхәррирәләр, галимәләр, әдибәләр, шагыйрәләр ирешкән уңышлар хакында горурланып яза.

Аның милләт аналары тәрбияләүгә кагылышлы язмаларын берничә зур темага бүлеп карарга мөмкин.

Беренче зур тема – хатын-кызның гаиләдә, хатын һәм ана буларак, ирен һәм балаларын тәрбияләүдәге роле. Аныңча, ирләр – хатыннарның әсире, ирләрне ир итүче дә, юк итүче дә хатын-кыз. Ул: «Ирләр һәрвакытта да безгә мохтаҗ, алга да, артка да безнең тәэсиребез илә китүләрен онытмыйк, кыз туганнар!» – дип басым ясый.

Кызларны олы иҗтимагый миссияне башкарырга әзерләү юлында төп чара итеп күпләп мәктәпләр ачуның зарурлыгын, укый-яза белүдән тыш, аларга заманча белем, шул исәптән бала тәрбияләү, гигиена һәм йорт эшләре буенча мәгълүмат бирүнең кирәклеген беренче бурыч итеп куя. Шулай ук ул русча укыту, мөгаллимәләр әзерләүче махсус мәктәпләр ачу, укыту методикасын камилләштерү, мөгаллимәләргә яхшы хезмәт хакы һәм яшәү шартлары тудыру, хөрмәтле караш тәрбияләү хакында күп яза. Бу яктан, күрше халыклар, беренче чиратта руслар, ирешкәнне өйрәнергә һәм файдаланырга кирәклекне искәртә. Укучы кызларны һөнәрле итү: бакчачылыкка, кул эшләренә өйрәтү һ.б. мәсьәләләрне һәрдаим күтәрә килә.

Боларның барысын да ул милләт ваемы, халык язмышы белән бәйләп карый. Фәкать хатын-кызларын дөрес тәрбияләгән милләтнең генә балалары белемле, тәрбияле, намуслы, үз мәнфәгатьләрен халык иҗтыяҗларына буйсындырырлык булып үсә ала, шул вакытта гына алар ватанпәрвәр, гыйлем сөючe, һәрбер эшне башкарып чыга алучы булып җитешәчәк, дип ныклап әйтә.

Аны шулай ук татарларда ирнең хатын-кыз турында тиешенчә кайгыртмавы борчый. «Русия мөселман хатын-кызларына ачык хат»ында (1913 ел, 29 май) «кара мужикларның да, ак якалы татарларның да, муллаларның да, байларның да хатын-кыз мәсьәләсендә фикерләре бердер», дип белдерә, милләтнең иң эшчән, мактаулы яртысы – ирләр мөгаллимәләр әзерли торган уку йортларын оештырырга тырышмый, дип ачыктан-ачык тәнкыйтьли.

Аның хатын-кызларны активлыкка, язмышларын үз кулларына алырга чакыруы да шуның белән бәйләнгән. Файдалы эшне ирләрдән көтеп торсак, алданачакбыз: алар һичбер вакыт безнең ихтыяҗларыбызны үти алачак түгелләр. Чөнки үзләренең ихтыяҗлары шулкадәр күптер, кызларны кайгыртырга вакытлары җитми, дип ачына. Хатын-кызларны үз хокуклары өчен көрәшергә өндәп, болай ди: «Без, Русиядәге мөселман хатын-кызлары, дин, дөнья тәрбиясенә үзебезне үзебез әзерләргә, үзебезгә мәктәпләр ачарга, укып, үлгән аналарыбызның шанлы урыннарын тотарга тиеш. Моның өчен Русиядә русча, гарәпчә, татарча тәрбия күргән хатын-кызларга газеталар аркылы фикер алышырга, киләчәгебезне уйларга, милләткә тәрбияле аналар җитештерү өчен чаралар эзләргә керешергә фарыз».

Ул киләчәккә карап фикер йөртә. 1913 елның маенда язган мәкаләсендә хатын-кызлар өчен татарча махсус журнал чыгару кирәклеген көн тәртибенә куя, бу эшне үзе башкарырга ниятли, программасын төзи. Ләкин өлгерми кала.

Күпсанлы вазифалар башкару: мәктәптә укыту, гимназиядә имтиханнарга әзерләнү, бетмәс-төкәнмәс редакция эше алып бару, мәкаләләр язу, иҗтимагый чараларда катнашу һәм башка тормыш мәшәкатьләре Фатыймаи-Фәридәнең сәламәтлеген какшата. Акчасызлыкка карамастан, ул ахыргача газетаны чыгарырга тырыша.

1913 елның җәендә ире, редакцияне Уфага күчереп, «Тормыш» исемле газета чыгара башлау мәшәкатьләре белән йөри. Ябыгудан баласын имезергә сөте калмагач, яшь хатын сабыен сыер сөте белән тукландыра, әмма саклап кала алмый. 9 айлык кызының үлеме яшь ананы тәмам хәлсезләндерә. Август аенда ул салкын тидерә һәм туберкулез белән авырый башлый. Ай ахырында исә «Сибирия»нең соңгы саны дөнья күрә.

Каты авыру хәлдә Фатыймаи-Фәридә Кәрәкәшлегә, әтисе йортына кайтып егыла. Ул авыру хәлендә булуга карамастан, «Сибирия»нең дәвамы булып Уфада нәшер ителгән «Тормыш» газетасына мәкаләләр җибәреп тора.

1914 елның 16 февралендә 25 яше дә тулмаган Фатыймаи-Фәридәнең вафаты турындагы хәбәр татар җәмгыятен тетрәндерә. «Тормыш» редакциясенә төрле төбәкләрдән меңгә якын телеграмма, мең биш йөзгә якын кайгы уртаклашу хаты килә.

Әмма аның хезмәте яши. 1916 елда Кәрәкәшледә 200 кыз балага Фатыймаи-Фәридәдә белем алган, Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлаган Зәйтүнә исемле мөгаллимә белем бирә. Аның мөселман хатын-кызларының хокукларын яклап әйткән фикерләре һәм шәхси үрнәге бик күпләрне укырга, мөгаллимә булып, татар кызларыннан милләт аналары әзерли башлауга этәрә.

ОЛУГ ФАҖИГА КОРБАНЫ

Айдар Шәйхин

Аның исеменең онытыла төшүе, мөгаен, юкка түгелдер. Бәлки, кайбер исемнәр, мәңгелек төпкелләрендә югалмыйча, тарих елъязмасында җуелмаслык итеп теркәлүгә лаек та түгелдер? Истәлеге булып Казан урамына бирелгән исеме генә калган революционер Камил Якуб турында сөйләшик.

БЕРЕНЧЕ АКТ. МӘДРӘСӘ ШӘКЕРТЕ

Камил Лотфыйрахман улы Якупов 1894 елның 21 мартында туган. Аның кендек каны тамган җир хәзерге Татарстаннан читтә урнашкан. Ул елларда Якублар гаиләсе Самара губернасы Бөгелмә өязенең Әбдеки авылында яши. Бүген Татар Әбдекие авылы Самара өлкәсенең Шонталы районына карый. Бу авыл 1752 елда нигезләнеп, Камил дигән ир бала туачак елларга 2 су тегермәне, сабын заводы, почта станциясе, мәчете һәм мәдрәсәсе булган волость үзәге дәрәҗәсенә үсеп җитә.

Егетнең биографиясе ул чор эшлеклеләренең барысына диярлек хас траектория буенча башлана. Әлбәттә, ул башлангыч белемен туган авылының мәктәп-мәдрәсәсендә ала. Балачагыннан күп сораулар биргән һәм белемгә омтылышы сизелеп торган Камилне этисе Чистай мәдрәсәсенә җибәрә. Ә бу чорларда Чистайның «Камалия» мәдрәсәсе – иң данлыклы уку йортларының берсе. Биредә Гаяз Исхакый, Фатих Кәрими, Фуад Туктаров, Галиәсгар Гафуров-Чыгтай кебек шәхесләр укып чыга. Хәлбуки Камил Якуб монда озак тормый. 1909 елда ул Казанның «Мөхәммәдия»сенә укырга керә.

Татар дөньясының ул заман университетына тиң уку йорты ул «Мөхәммәдия». Монда кемнәр генә укымый да, кемнәр генә хезмәт итми! Бөек идеяләр һәм инициативалар, чикләр һәм шул чикләрне алып ату омтылышлары, дуамал шәкертләр, салмак фикерләргә чакыручы остазлар… Гөрләп торган мәдрәсәдә бу елларда Бакый Урманче да белем ала бит! Ул, шәкертлек елларын искә төшереп, Камил Якуб турында болай ди: «Тереклек тәҗрибәсе барлык күренә иде. Камилнең өлкән табигатьле булуы бик ачык хәтердә калган».

Әйе, киләчәкне уйларга тырышу һәм билгеле бер дәрәҗәдә фикер өлкәнлеге Камилгә хас була. Мәдрәсә тәмамлап чыкканнан соң уңышлы хезмәт юлы турында хыялланган шәкертләр «Учительская школа» шаһадәтнамәсен дә алырга омтыла. Ике дипломлы булу дигән сүз бит бу. Казан укытучылар мәктәбе хөкүмәт тарафыннан танылган документ бирә, син аның нигезендә казна мәктәпләрендә дә укытучы була аласың. Тагын бер мөһим ягы – рус телен өйрәнү. Кыскасы, зур шәһәргә укырга килгән Камил бу мәктәпне дә тәмамлау турында уйлана. Әмма этисе аңа мәдрәсәне ташлап китәргә рөхсәт итми, акча белән тәэмин итүдән баш тарту белән яный.

Максатчанлык – ир кешегә кирәкле иң мөһим сыйфатлардан. Камил Казанда әкренләп үзлегеннән рус телен өйрәнә башлый, акча җаен да кайгыртырга тотына. Ул, җәй айларында авылга кайтмыйча, «Болгар» номерлары харчевнясында официант булып эшли, ә кичләрен укый, эзләнә, дөньяви белем туплый. Аның биографиясен җентекләп өйрәнгән С. Фәйзуллин раславынча, ахыр чиктә, Камил Якуб барыбер укытучылар мәктәбе имтиханын тапшыра һәм рус теле укытучысы булып эшләү хокукына ирешә.

ИКЕНЧЕ АКТ. СОЛДАТТАН - БОЛЬШЕВИККА

Камил мәдрәсәне дә тәмамлый, укытучылар мәктәбе имтиханын да үтә. Әмма аңа мөгаллим-укытучы булып хезмәт итәргә насыйп булмый. 21 яшендә ул армиягә алына. 1915 ел… Беренче бөтендөнья сугышының икенче елы бара. Камил – Көнбатыш фронтның 2 нче армиясендә солдат.

Фронтта хәлләр мөшкел була. 1915 елның җәендә Россия империясе армиясе, Германия

Фотолар автордан алынды

гаскәрләренең һөҗүменә түзә алмыйча, артка чигенә. Бу вакыйганы Бөек чигенеш дип тә атыйлар. Кыска вакыт эчендә гаскәрләр ярты мең чакрымга чигенә, биш ай эчендә 1 миллион кеше әсирлеккә эләгә, ярты миллионы һәлак була яки хәбәрсез югала.

Беренче бөтендөнья сугышының киләсе еллары да шактый өметсез, мәгънәсез һәм фаҗигале үтә. Әмма Камил Якуб сугыш кырларында «күзен ача». Ул фронтта агитация алып барган большевикларның нотыкларын игътибар белән тыңлый һәм алар сайлаган юлны үзенеке дип кабул итә. Гомумән, ул хезмәт иткән 2 нче армия иң революцион дип санала, чөнки биредә сул партияләрнең пропагандасы аеруча зур уңышка ирешә.

1917 ел феврале вакыйгаларыннан соң, империя гаскәрләрендә үзгәрешләр башлана, фронт комитетлары барлыкка килә. Большевиклар агитациясен җәелдерергә мөмкинлекләр киңәя. Камил дә бу хәрәкәткә кушыла. Нотыклар сөйли, империалистик сугышның асылын аңлатырга омтыла. Ул инде шәкерт тә, укытучы да, гади солдат да түгел. Камилгә – 23 яшь. Камил – партия әгъзасы, чын большевик.

Бу вакытта җимерелеп барган империя армиясеннән милли полклар да үсеп чыга башлый. 1917 елның мартында Ильяс Алкин җитәкчелегендә Казан мөселман хәрби комитеты оеша, хәтта аерым татар хәрби округын оештыру планнары барлыкка килә. Май аенда Мәскәүдә үткән мөселман съездыннан соң бу эш тагын да җанлана төшә. Бөтенроссия мөселман хәрби шурасының нигезе хасил була, аның «Безнең тавыш» исемле газетасы да чыгарыла башлый.

1917 елның июлендә Казанда Бөтенроссия мөселман хәрби съезды үтә. Вакытлы хөкүмәт бу корылтайны үткәрергә рөхсәт бирми, әмма җыелыш барыбер уза. Аның лидеры – әлеге дә баягы Ильяс Алкин.

Камил бу вакыйгада 2 нче армиядәге татар солдатларының вәкиле буларак катнаша. Чыгышлар да ясый, җыелышны трибуна итеп куллана. Съездда сайланган Хәрби шурага да ул солдатлар вәкиле буларак кертелә.

Аңлашыла ки, съезддан соң Камил фронтка башка китми инде. Ул Казанда кала. Хәрби шураның Вакытлы хөкүмәт белән алып барган сөйләшүләре һәм Корнилов фетнәсе кебек вакыйгалар нәтиҗәсендә, берничә полкны «миллиләштерергә» рөхсәт бирелә. Казанда – 95 нче, Уфада - 144 нче, Симферопольдә 32 нче полк мөселман полкларына әверелә.

Камил Якуб, Якуб Чанышев, Мулланур Вахитовлар бу полкларны татарныкы гына түгел, ә нәкъ менә большевикларныкы ук итәргә омтыла. Алар агитация белән үзләре дә шөгыльләнә, агитаторлар хезмәтен дә оештыра.

Татар большевиклары. Камил Якуб уртада басып тора. 1918 ел. Татарстан Милли музее фотосы.

Мулланур Вахитов мөхәррирлегендә чыгарылган «Кызыл байрак» газетасына да Камил Якубның ярдәме зур була. Ул чакта Казанда большевикларның татар телендә чыга торган махсус газеталары булмый. «Большевизмны пропагандалау бурычлары» Мөселман социалистлар комитеты тарафыннан чыгарыла торган «Кызыл байрак» газетасы өстенә төшә. Газета бушлай таратыла, матди базасы тотрыклы булмый. «Кызыл байрак»ны типографиядә бастырып чыгару да зур мәшәкать тудыра. Газетаны бастыру мәсьәләсен хәл итү Камил Якубка тапшырыла. Камил бу эшне гаҗәп оста башкара, дип искә ала замандашлары. Ничек итеп? Тулы серен белмәсәк тә, совет дәреслекләрендә «типографиядә агитация оештыра һәм эшчеләрне социалистлар комитетына чакыра» дип язганнар. Сүз Кәримовлар басмаханәсе турында бара. Нәкъ менә Камил Якубның тырышлыгы белән газетаны бастыру тәртипкә салына. Бу матбугат органы 1917 елның 15 июненнән – Казанда, ә 1918 елның май-июлендә Мәскәүдә басыла. Газетада Җамал Вәлиди, Сафа Борһан, Мирсәет Солтангалиев, Сахибгәрәй Сәетгалиев кебек күренекле шәхесләрнең язмалары да урын ала.

«Кызыл байрак» озак чыкмаса да, Камил Якубның вафатыннан соң истәлеген саклауда бу газетаның роле зур була. Большевиклар кулына күчкән Кәримовлар басмаханәсе соңрак Камил Якуб исемендәге дәүләт типографиясенә әверелә. Гомуми тиражы әллә ничә миллионга җиткән татар совет китапларында «Камил Якуб исемендәге типографиядә басылды» дигән язуны күпләр хәтерлидер...

ӨЧЕНЧЕ АКТ. КОМИССАР

Октябрь вакыйгаларын Камил Якуб Казанда каршылый. Татар полкының аерым роталары да бәрелешләрдә большевиклар ягында

Виктор Федоровның «Комиссар Камил Якубов» картинасы (1981 ел). ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

катнаша. 25 октябрь кичендә Казанда хакимият Революцион хәрби комитет кулына күчә. Хәрби шура җитәкчесе Ильяс Алкин бу вакыйгаларга бик шикләнеп караса да, Камил Якубның үгетләвенә колак сала. Хәрби шура рәсми рәвештә Казанда хакимияткә килгән совет хөкүмәтен сәламли һәм хуплый.

Ә икенче көнне Казан советы К. Грасис җитәкчелегендә Революцион комитет сайлый. Бу органга татарлардан Казан гарнизоны ахуны Гатаулла Баһаветдинов, Хәрби шурадан Якуб Чанышев һәм Камил Якуб, Мөселман социалистлар комитетыннан Мулланур Вахитов белән Мирсәет Солтангалиев керә. Шулай итеп, Камил Якуб яңа хакимият эшендә турыдан-туры катнаша башлый.

Хәлләр катлаулана бара. Петроградта – инкыйлаб, әкренләп Гражданнар сугышы кабына башлый. Ил киләчәген үзенчә күзаллаучы көчләр шактый. Татар җәмәгатьчелегенең бер өлеше Милләт мәҗлесе һәм Милли идарә тирәсендә берләшә, әмма анда да яңа дәүләт эчендә татарның киләчәген төрлечә күрүчеләр бар. Камил Якуб белән Мулланур Вахитов та сәяси яктан карашлары бераз аерыла торган кешеләр бит. Кыскасы, Казан губернасы территориясендә идарә органнары бер-бер артлы алышынып тора. Большевикларга альтернатива булырдай көчләрнең берсе – Хәрби шура. Ахыр чиктә, нәкъ менә алар Идел-Урал штаты идеясен күтәреп чыга. 1918 елның февралендә Казанда үткән II Бөтенроссия мөселман хәрби съезды милләт өчен әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрә һәм яңа дәүләтчелекне булдырырга омтыла.

Камил Якуб бу мәсьәләдә Идел-Уралга каршы чыга, шул рәвешле Алкин белән элемтәсен дә өзә, дип аңларга кирәк. «Безнең тавыш» газетасында басылган мәкаләсендә Камил болай дип яза: «Дөрес, народный комиссарлар Донда, Украинада, Кырымда сугыш ачты, ләкин боларның халкына сугыш ачмады бит, бәлки халык исеменнән сөйли торган, милли әләм астына яшеренгән буржуазия, офицерство, гакселхәрәкәтчеләргә (контрреволюционерларга – авт.) каршы сугыш ачты. Бу изелгән фәкыйрь халык файдасын һәрнидән бөек идеал итеп токтан хәзерге хакимиятнең вазыйфасы иде, ул шуны үтәде, ул украин, фин эшчесенә матди ярдәм итте. Чөнки вөҗданлы күрше, үз йортыннан каракларны куалап чыгарып, күршеләрне талаганны сер итеп тормас, бәлки күршеләрне караклардан хәлас итәргә (коткарырга – авт.) тырышыр. Дөрес, бу сугышларда, ихтимал, гөнаһсыз демократиянең каны түгелә торгандыр, ләкин монда народный комиссарлар гаепле түгел, бәлки милләтләрнең башында торып, төрле буяулар белән алдап, халыкны үзенә корал итүчеләр гаепле».

Кызганыч, Камил Якуб өчен Хәрби шура һәм Милләт мәҗлесе идеяләре дә «буржуаз» булып чыга. Казанда Идел-Урал штаты төзелешен игълан итүгә юл куймас өчен, большевикларның революцион штабы Хәрби шура җитәкчеләрен кулга ала. Бу вакыйгаларда Камил Якуб та катнаша. Ә инде «хәрби шурачылар» Болак артында съезд эшен дәвам иткәч, Казанда чын фетнә күтәрелә. Монда большевиклар белән буржуазия генә түгел, татар белән татар да бер-берсенә каршы куела.

Бер ай тирәсе барган каршылыкта Якуб Болак арты хәрбиләре белән көрәшергә тиешле «кызыл дружина»ны җитәкли. Хәрби шура тәмам туздырылгач, Татар-Башкорт Совет республикасын уйлап табыла. Бу проект чынга ашырылмаса да, башлангыч этапта аны яклауда һәм идеясен таратуда Камил Якуб актив катнаша.

1918 елның мартыннан соң Камил Якубның партиядәге дәрәҗәсе арта. Ул Мәскәүдә оештырылган Үзәк мөселман коллегиясенең сәяси бүлеге әгъзасы һәм башлыгы, РКП (б) ҮК каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмасының Үзәк бюросы әгъзасы итеп билгеләнә. Бу органнар мөселман оеш-

малары, шул исәптән татар социалистлары аерылып йөрмәсен, аларның бердәм вертикаль эчендә булуларын тәэмин итәр өчен барлыкка килә.

Казан аклар кулына күчкән айларда да Камил Якубның эшчәнлеге туктамый. Ул Мәскәүдә газета чыгару эшендә катнаша, агитация белән шөгыльләнә. 10 сентябрьдә Казан азат ителә, тагын большевиклар кулына күчә.

ДҮРТЕНЧЕ АКТ. КОРБАН

Камил Якуб турында янә Бакый Урманче истәлекләренә мөрәҗәгать итик.

«Сугыш еллары, димәк, 1914 елдан 1919 га кадәр аның белән очрашу булмаган. 1919 да Казанда очраштык. Ул хәзерге Киров урамында тора иде. Шунда без утырышып әңгәмә кылдык. Аның Хәрби комиссариатта эшләгән вакыты. Минем сәнгать мәдрәсәсендә укыган вакыт. Беркөнне мин, сәнгать мәдрәсәсеннән чыгып, ул вакыт Грузин, хәзерге К. Маркска атаулы урамнан өйгә кайтып барганда, мине урамда патрульләр тотып, ЧК өенә алып бардылар. Аның вестибюлендә байтак кеше җыелган иде. Еракта атышулар ишетелә иде. Бу июнь көннәре. Минем сертификатларны карагач, ирекккә куйдылар. Шушы Камил үтерелгән көн иде. Татар батальонының кузгалышы.

Арча кырында Камилне җирләгәндә, күп халык җыелган булды. Гыйлемдар Баембәтов кайнар нотык сөйләде. Тагын кемнәрдер сөйләгәне исемдә калган. Камил һәр заман, һәр эштә хөрмәт итәрлек инсан иде».

Әйе, канлы вакыйгалар чылбыры 1919 елда да дәвам итә шул. Ел башында губерна тормышы бераз рәткә салына башласа да, Колчак гаскәрләре якынайгач, яңадан хәрби хәл игълан ителә.

Казанда урнашкан татар запас батальоны җәй көне Колчакка каршы фронтка җибәрелергә тиеш була. Әмма батальон солдатлары үз таләпләрен игълан итәргә ашыга. Эш шунда ки, бу солдатларның матди хәле чыннан да бик авыр була: кием җитми, ашату юк, егетләр айлар буе салкын идәндә йоклый. Мир-сәет Солтангалиев белән Микъдәт Борындыковның Ленинга җибәргән рапортыннан күренгәнчә, гарнизон җитәкчелеге батальонны күрәләтә авыр хәлдә калдыра, сугышу түгел, яшәргә дә мөмкинлек бирми диярлек.

1919 елның 25 июнендә татар запас батальонында чуалышлар башлана. Арча кырындагы казармалар буенда зур митинг күтәрелә. Вакыйга турында телеграмманы алган Камил Якуб шунда ук солдатлар янына ашыга – сүз көченә ышана ул.

Нинди генә аклану сүзләре әйтсә дә, ач-ялангач һәм котырынган солдатлар Якубның сүзенә колак салмый. Әллә провокаторлар эше булганмы, әллә чыннан да ачның ачуы яман булып, егетләр чарасыздан бу гамәлгә барганмы – кем белсен хәзер... Әмма факт шул: 25 июнь фетнәсе барышында Камил Якуб һәм аның белән килгән бер кызылармияче үтерелә.

Фетнә тиз бастырыла, «провокаторлар» да табыла. Мондый чуалышны көтмәгән большевиклар Якубның үлеменә үч итми калмый. Милли һәм дини эшлеклеләр корбанга корбан булып китә. Казан мөхтәсибе Габдулла Апанаев шушы вакыйга сәбәпле атып үтерелә.

Җир йөзендә 25 ел гына яшәп өлгергән Камил Якубның гомере шулай өзелә. 1924 елда Казанның бер урамына аның исеме бирелә, озак еллар буена дәүләт типографиясе дә Камил Якуб исемен йөртә. Җәсәде исә хәзерге Горький паркы эчендәге мемориалда җирләнә.

Камил Якубның тууына 130 ел булды. Бүген исемен белгән кеше бармы икән? Совет чорында каһарманнар арасында йөртелгән бу шәхеснең тарихта урыны нинди? Бу хакта әле уйланасы бар. Шунысы тәгаен аңлашыла: ул, һичшиксез, милләт тарихындагы бер олуг фаҗиганең корбаны. Инкыйлаб вакыйгалары татар балаларын капма-каршы лагерьларга бүлә, кан коярга һәм хаксызга һәлак булырга мәҗбүр итә. Камил Якуб шул хәлләрнең шаһите, катнашучысы һәм символыдыр да, мөгаен.



Татарча «Марсельеза». 1917 елгы листовка. Татарстан Милли музее фотосы.

Камил Якуб (уртада) мөселман коммунистлары белән. Мәскәү, 1919 ел. Татарстан Милли музее фотосы.

ЯШӘҮ МӘГЪНӘСЕН БЕЛСӘК, ҮЗГӘРЕР ИДЕКМЕ?

Луиза Янсуар

Бу юлы соңгы елларда китап сөючеләрне үзенчәлекле романнары белән генә түгел, ә лекцияләре, авторлык курслары һәм блогы белән дә җәлеп иткән яңа бер авторга тукталырга булдык.

Мин Мәскәүдә тудым. Шушында ук үстем дә: иске үзәкнең яшерен бер районында, май аенда сирень чәчәккә күмелеп утыра торган бер тыкрыкта. Француз мәктәбенә чын күңелдән рәхмәтлемен, һәм менә нәрсәләр өчен: франкофон җаным, француз мәдәнияте белән бәйле бар нәрсәгә гашыйклыгым (географиядән алып ризыкка кадәр), Париждагы уку елларым һәм каникулларым.

Беренче язу тәҗрибәләрем – балачактан. 13 яшемдә ике хикәя яздым, алар соңыннан «Ялангач көндәлек» («Голый дневник») үсмер җыентыгына керде («Фамильная Библиотека» нәшрияты, 2013 ел).

«Мәгънә камерасы» («Камера смысла») фәнни-фантастик романы – минем икенче китабым, ул 2020 елда бәйсез проект буларак нәшер ителде.

Хәзер яңа романым дөньяга чыгарга җыена.

Язудан тыш, лекцияләр укыйм. Җете тормыш белән яшәгән, илһамландырырга сәләтле булган шәхесләрнең тормыш тарихларын туплыйм һәм теркем. Лекцияләр биография һәм хисләр буйлап мавыктыргыч сәяхәткә әверелә.

Мин – филолог һәм психология магистры һәм, күрәмсең, тормышка булган кызыксынуым да, китапларым белән лекцияләрем дә шушы ике һөнәрем кисешендә туа.

Ольга Хейфиц сайтындагы кереш сүз

Фото: olgakheyfits.ru, livelib.ru, goodfon.ru

КУМИРЛАР БЕЛӘН АЛЛАЛАР, ЯКИ БАЛАЧАК УЕННАРЫ

Ольга Хейфиц, «Бала алласы» («Детский бог»)
«Эксмо» нәшрияты, 2023

2023 елның декабрендә басылып чыккан әлеге роман Россиянең хәзерге көн проза иҗат итүче авторлары исемлегендә барлык платформаларда, кушымталарда тәкъдим ителде. Аны күрми калу мөмкин түгел иде. Шулай итеп, өченче романы белән автор китап сегментында һәм базарында, ниһаять, тиешле урынын яулады, дисәк тә буладыр.

Бу роман балачак һәм үсмерлек еллары идиллиясенә кайту һәм күмелү рухында башланып китә. Шунда ук үзенең гаҗәеп тәмле, хуш исләр, төсләр белән аңкып торган, предметлар дөньясы белән ностальгиягә дучар иткән атмосферасы белән башны әйләндерә. Хейфиц рәссамнарча виртуозлык белән сурәтли, романның һәр битеннән, пумаладан чәчрәгәндәй, акварель, майлы буяулар чәчри, музыкаль тоннар алмашына һәм туктаусыз агыла. Монда барысы да – уч төбендәге кебек, барлык детальләр калку һәм анык, әмма бер үк вакытта барысы да ниндидер әйтеп бетерелмәгән сер белән өретелгән. Син аны менә тотып алам, менә тотып алам, дип талпынасың... – ул барыбер һавада эреп югала.

Валентиновка – дача. Әмма биредәге дачниклар башкалардан, ягъни гади кешеләрдән, аерылып тора: бу затлар, Александр Львович Гирс кебек, Җир кануннары белән идарә итә, адәм гомерләрен коткара.

Хәтерлим, бу туфракка аяк басу белән миндә, бары тик алар сулаган һаваны гына сулап та уңыш белән кул кысышырмын, дигән өмет кабынды.

Маҗараларга әзер идем, ә әтиемнең җитәкчесе Гирс белән очрашуны күңелемдә инде бер йөз мәртәбә җанландырып караганмындыр.

Гирс – врач. Тик ул гади врач кына түгел, ә күренекле кардиолог, атаклы хирург: йөрәкләрне кучереп утыртуы, шунтлавы белән билгеле, гомумән, иң катлаулы һәм сирәк табиблар гына алына торган операцияләр остасы. Аны берөзлексез йә Кремльгә, йә чит илгә чакырып торалар, хәтта Штатларда да булып кайтканы бар, диләр.

Ул миңа Җир йөзендәге сирәк токымлы алыплардан булып күренә, аның хуплавын һәм симпатиясен яулап алыр өчен мин әллә ни бирергә әзер. Менә хәзер дә, дачага якынлашкан саен, эчемнән генә, дулкынлана-дулкынлана, репетиция ясап барам: «Танышуыбызга бик шатмын, Филипп...»

Ике катлы йортны, типик совет дачасын, коньякта сирень куаклары басып алган булса, төньягында куе үлән «яулаган» иде. Инде ничә ел узса да, мин Виктория Гирс һәм аның гаиләсе белән танышу мизгелен бүгенгедәй хәтерлим... Мин ул җәйне һәм ул йортны шулкадәр еш искә төшерәм ки, әйтерсең, анда тулы бер гомерем узган.

1995 елның гомерлеккә эз калдырган җәеннән һәм чит тормышның матур, ымсындыргыч, кабатланмас могҗизасыннан башланып киткән бу бәян башыннан ук бераз сискәндерә, шөбһәләндерә. Юкка гына Хейфиц стилистик яктан һәм кәеф буенча илһамчылары дип Бунин белән Набоковны атамый. Гирс һәм аның гаиләсенә баштанаяк гашыйк булган, күренекле хирург образын алла дәрәҗәсенә күтәргән, ә үз этисе белән әнисен алар янында үтә гади, игътибар итәрлек тә түгел дип исәпләгән Филиппның кайчан да булса бер чынбарлык белән бәрелешәсе көн кебек ачык. Хыялларының чәлпәрәмә киләчәге дә... Без еш кына кумирлар артында ни торганын күз алдына да китермибез бит, ә белеп алгач, тормышның асты-өскә килгәндәй була.

Һәм менә җәйнең бер көнендә Филипп үзенең бу гаиләгә һәм Викага тиң булмавын белсә дә, ике яшүсмер арасында күзгә күренмәс җепләр сузыла – бу хис торган саен ныгый, икесенең дә уртак яшерен серенә әверелә. Әмма Виканың башка серләре дә барлыгын Филипп үсмер йөрәге белән сизенә... Шулай да сорарга, төпченергә базмый. Искиткеч профессор Гирсның искиткеч хатыны Полинаның да еш кына кеше күзе күрмәгәндә сервантка шешә белән бокал яшергәнен күрмәмешкә салыша ул, өйдәге идәннәрнең төннәрен йә таң алдыннан шикле сыкрап алуын да, кайсыбер иртәләрдә Виканың да, Полинаның да күзләре ялкынсынып кызарган булуын да...

Психолог буларак, Хейфиц хисләрне тышкы детальләр артына яшереп, йә булмаса гамәлләрнең логикасына, йә мантыйк-

сызлыгына төреп бирә. Шулай ук яшь-яшь ике геройның алдагы тормышының капма-каршылыгы аша да бик мөһим проблемага алып чыга – безнең асылыбызга салынган мөмкинлекләр белән үз тырышлыгыбыздан кала, эти-әниләрдән нинди эмоциональ нигез алуыбыз да хәл итә язмышны. Үзебезгә ышанырга өйрәткәннәрме алар безне, яратуларын тойганбызмы без аларның? Ә ярату чикләрне узса, куркыту, көч куллану, җәберләү, олыларның үз эчке фаҗигаләрен яшерү булып әверелсә нишләргә?

Дөнья без уйларыбызда тудырган чынбарлыкка әллә ни охшамаган икән, бигрәк тә – еллар буена оптиканы үзгәртмәсәң. Һәркем үзенекен күрә, һәрберебезнең үз шәхси шашынуы һәм шәхси бәхете.

Мин ярты гомеремне менә шушы чынбарлык сурәте белән уздырдым: анда искиткеч бер кыз һәм аның гаҗәеп гаиләсе бар, һәм мин, әлбәттә, ул гаиләгә лаек түгелмен. Мин бу дөньяны уйлап чыгарган арада Вика кайда яшәгән соң? Куркыныч бер чалыш чынбарлыктамы?

Һәм менә мине ул чынбарлыктан аерып торучы манара җимерелеп төште. Минем умырткаларыма кадәр үтеп кергән һәм еллар буена үсеп тамыр җибәргән нindидер бер структура, нәрсәнеңдер асылы, мин таянып торган мәгънә, ул да җимерелә башлады... Ә бит минем әтием әле балачагымда ук хаклы булган – Гирс, чынлап та, коточкыч зат.

Кайбер хыяллар белән мавыгуларның балачакта гына калуы хәерлерәктер, ди гүя автор. Һәм менә без 36 яшьлек танылып килгән, уңыш дилбегәсен кулларында нык тотып торган хирург Филипп белән очрашабыз. Ул инде күптән теге җәйне дә, аннан соңгы сынауларны да кичкән. Көтмәгәндә-уйламаганда, Виканы аңардан яшереп, аларның очрашуларын тыюларын да, аны шәһәрдән алып китүләрен дә, аралашыр өчен бөтен юлларны ябуларын да кичергән, кичкән... билгеле. Бөтен каршылыкларга йөзе белән торып, кем була алганын эти-әнисенә дә, дөньяга да раслаган. Уңышлы өйләнеп, гаилә корып, баласына тиешле тормыш шартларын, киләчәкне тәэмин итеп, карьерасын шәп фундаментка утыртып куеп...

Дөньяның иң атаклы хирурглары җыелган Европадагы конференциядә олыгаеп һәм йончып, шыксызланып киткән Гирс белән очрашкач, ул кинәт үзен көзгедә күргәндәй була. Шунысы гаҗәп: Гирс аны, әйтерсең берни булмагандай, аркасына кагып, дусларча каршылый да туган көненә йортына чакыра. Ә анда Филиппны Вика һәм балачагының чәрдәкләнгән хатирәләре көтә...

...Ә балачак безнең белән бик сәер уеннар уйнарга мөмкин.

КРИОГЕН ЙОКЫ, ЯКИ БОРЫНГЫ ДӘВЕРГӘ, ДӘРЬЯ ТӨБЕНӘ...

Ольга Хейфиц, «Мәгънә камерасы» («Камера смысла»)

RIDERO сервисында басыла, OZON, Amazon, Литрес, Bookmate платформаларында тәкъдим ителә

Әсәр детектив рухында башланып китә һәм үзенең серле-моңсу атмосферасы белән беренче битләреннән үк җәлеп итә. Әйтерсең, без «светский» журналлардан атаклы һәм уңышка ирешкән кешеләр турындагы колонкаларны гына укып калмыйбыз, ә затлы Париж фатирларына да, гарәп шәехләре сарайларына да, Американың иң мәртәбәле университет кампуслары белән лабораторияләренә дә, хәтта Америка Кушма Штатларының беркем белергә тиеш түгел, оборона хезмәте вәкилләре яшереп саклый торган объектларына да үтеп керәбез. Һәм бу, әйтергә кирәк, үз заманында Дэн Браунның «Код да Винчи» сериясе тудырган эффектка тиң: син бик ышанып та бетмисең шикелле... әмма үтереп ышанасың, «Менә бит ничек икән!» дип тел шартлатасың, сихерләнәсең, баштанаяк бу чынбарлыкка күмеләсең, аннан яшәүнең бөтенләй яңа мәгънәсен табасың килә.

Рус журналисты Ольга Парижга үзенең башка сыймас ачышлары, моңарчы беркем кора алмаганча корылган гаҗәеп карьерасы һәм моңсу шәхси тарихы белән билгеле медицина фәннәре докторы, профессор Платон Вальтер белән интервью алыр өчен махсус килә. Берничә ел элек Вальтерны Нобель премиясенә тәкъдим итәләр, әмма ул, бар дөньяны шаккатырып, һич көтмәгәндә премиядән баш тарта. Көннәрдән бер көнне гаммәви мәгълүмат чараларында акылга сыймаслык хәбәр тарала: профессорның күз карасыдай хатыны – дөньякүләм танылган археолог, интеллектуалка, стиль вә зәвык иясе Анна Стерн яр буенда хәбәрсез югала. Көймәдә аңардан берничә шәхси әйберсе генә кала...

Платон Вальтер белән Анна Стерн мөнәсәбәтләрен бар дөнья «идеаль мәхәббәт тарихы» буларак белә. Аннаның кинәт юкка чыгуы Вальтерның соңгы ачышы белән турыдан-туры бәйләнгән дип фаразлыйлар, һәм бар дөнья аңардан җавап көтә.

Франция, Париж, 2019

Вальтер – берсеннән-берсе кыю, революцион идеяләрне курыкмыйча тормышка да ашырып килгән шәхес. Аның өчен бернинди авторитетлар юк, ул иң кыен мәсьәләләрне дә стандарт булмаган юллар белән хәл итәргә алына.

Ул криобиология һәм крионика өлкәләрендә гаять тирән тикшеренүләр уздырган зат, гәрчә әлеге дисциплиналарны галимгоһәмә дөньясы бүгенгә кадәр фәнни фантастика буларак кабул итсә дә. Ләкин Вальтер крионика өлкәсендә башкарган гигант алга китеш нәтиҗәсендә, без хәзер аңа фантастика итеп кенә карамый башладык. Криоконсервация медицинада күз иярмәс тизлектә популярлык казанды. Профессор Вальтерның фәнни апофеозы – кешене криоген йокыга талдыру. Ул керткән яңалыклар безнең кеше турындагы белемнәребезне үзгәртте.

Ләкин профессор Нобель премиясеннән баш тартты һәм кешелекне криоген анабиоз халәтенә кертеп саклар өчен уйлап тапкан синтезлы криомодуляторга юлны япты. Технологиясен аннан башка беркем дә белми.

Профессорның шәхси тормышы да үтә кызыклы. Ул – дөньякүләм танылган, зур абруйга ия археолог Анна Стернның хәләл җефете. Анна Стерн – борынгы цивилизацияләр белгече, Королеваның борынгы табылдыклар җәмгыяте почетлы әгъзасы. Чыгышы белән рус булган эмигрантка өчен – әйтеп бетергесез дәрәҗә. Өстәвенә, Анна Стерн бик матур. Вальтер белән алар икесе дә – үзгә бер затлар. Кагыйдәләр, традицион юллар белән эш итү тарафдарлары түгел. Аларның очрашулары һәм бер-берсенә гашыйк булулары гына да – гаҗәеп уңыш.

Читтән караганнар өчен бу пар – чын илһам чыганагы. Әмма күптән түгел генә Анна бик сәер шартларда бакыйлыкка күчә, һәм күпләр аның үлеме белән Платон Вальтерның Нобельдән баш тартуы, ачышын яшерүе арасында бәйләнеш бар дип таба.

Һәм менә журналистка Ольга белән бергә Платон Вальтер дөньясына аяк басабыз. Берничә ай дәвамында Вальтер Ольганы Парижның төрле урыннары буйлап йөртә: алар аның фатирында да очрашалар, Пер Лашез зиратында да, тату-салонда да, рестораннарда һ.б. Ә аннары Ольга аларның уллары янына бара – икенче фикерне дә белергә кирәклегенә төшенә.

Хейфиц фикеренчә, «мәгънә камерасы» – ул эпифиз, кеше баш миенең яшерен почмакларында урнашкан һәм бүгенгәчә бик аз өйрәнелгән серле бизе. Аны борын-борыннан юкка гына адәми затларның мистик сәләтләре белән бәйләп карамаганнар. Эзотерикада без бу хакта су буе хезмәтләр укый алабыз, әлеге дә баягы 90 нчы еллар азагы – нуленче еллар башында Россия укучысын тәмам шаштырган Эрнст Мулдашев хезмәтләрендә булуын да хәтерлибез. «Мәгънә камерасы» – Кеше һәм Югары Көч (Аллаһы Тәгалә) очраша, Яшәешнең асылына төшенә торган пространство, дип ассызыклый Хейфиц. Әсәрнең буеннан-буена без бу идеяне шул дәрәҗәдә үзебезгә сеңдерәбез ки, әйтерсең, аны аңыбызга берәү дә салмаган, ул иң баштан ук, беренче аваз салган мәлдә үк баш миенең төпкелләрендә булган.

Әсәрдә ике олуг шәхеснең очрашуы аша төрле караш, фәнни һәм иҗади методологиянең, яшәеш ысулының бәрелеше, шулай да бер-берсе белән яшәргә тырышу омтылышы чагылыш таба. Ахыр чиктә, нәкъ менә шул төп идеягә әверелә дә – ә нәрсә хакына ясыйбыз без бу ачышларны? Кемне шаккатырыр өчен? Кешелекне юкка чыгарырга әзер торган көчләр кулына корал бирү өчен генә түгелме соң? Нәрсә ул – фәнни этика белән тере җаннарга зыян китермәү анты?

– Улым, кулыннан килсә, мине бөтен мөмкин булган гөнаһларда гаепләр иде, хәтта әнисенең үлемендә дә. Һәм ул хаклы: мин җавап тотам бу үлем өчен. Ләкин Анна – акыллы кеше иде, ул бу карарны үзе кабул итте. Авыруының ни икәнен белә торып, дәвалауның эксперименталь икәнен дә бик яхшы аңлап.

– Сез аны ризалаштырдыгызмы?

– Мин аны коткарырга теләдем. Әйе, дәвалану кирәк, дидем. Ул заманча методларга артык ышанмый иде.

– Әмма экспериментка барыбер дә ризалашкан... Нигә?

– Сез миннән көч кулланмадыгызмы дип сорарга телисезме? Юк. Ул мине яратканга ризалашкандыр, дип уйлыйм.

– Гаиләгез хакына исән калырга кирәк дипме?

– Юк, минем экспериментта беренче «доброволец» булырга теләгәнгә.

...Ә аңа кадәр Анна дөнья океаны төбенә төшеп, атлантлар цивилизациясенә юлыккан, цивилизациянең әле дә исән булуына инанган галим була. Дәрья төбеннән чыккан гына вакытта безнең ни дәрәҗәдә көчле, кодрәтле булуыбызга инанып кайткан галим.

Һәм менә иренең эксперименты инде иң кульминацион ноктасына җиткән төннәрнең берсендә, таңга таба, ул аны уята да серен чишә. «Нәрсә?! Авырайдыңмы? – дип куркынып уяна аның сулышының һәр секундын тыңларга өйрәнгән Платон. «Юк, – дип пышылдый таң әңгерендә күзләреннән әллә нинди үзгә бер яктылык бөркелеп торган Анна. – Бар да тәртиптә. Әмма безнең вакытыбыз аз калып бара. Әйдә, мин сиңа күрсәтәм...»



«Татарстан» журналы үз битләрендә яшь прозаикларның кечкенә күләмдәге әсәрләрен бастыра башлады. Без бу авторларның исемнәрен бик ишетеп-белеп бетермәскә дә мөмкин. Бу – табигый. Араларында әле вакытлы матбугат битләрендә тәүге басылучылары да булачак. Димәк, үзенә күрә сынау, укучы алдында җавап тоту дигән сүз.

Бу кызлар белән егетләрнең заманыбызга, бүгенге көн вакыйгаларына, вазгыятенә үз карашлары, мөнәсәбәтләре бар. Үтә җитди, кискен иҗтимагый темаларга да мөрәҗәгать итә алар, мәңгелек сорауларга да җавап эзли, нечкә хиссияткә бирелеп, парча, нәсер кебек жанрларда да үзләрен сынап карый, юмористик рухта да иҗат итәргә омтылыш ясый.

Бүген без сезгә тагын бер яшь авторның ике хикәясен тәкъдим итәбез. Әйдәгез, укып карыйк.

Ләйсән Абдрахманова

Автор турында белешмә:

2004 елның 12 октябрендә Кайбыч районы Борындык авылында туган. Казан дәүләт медицина университетында белем ала. «Глаголица» (2020) һәм «Сәләткә нур булган йолдызлар» (2022) бәйгеләрендә Гран-при иясе, «Илһам» бәйгесендә (2019–2022) – 1 һәм 2 урыннар, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе инициативасы белән игълан ителгән татар телендәге әдәби әсәрләр бәйгесендә (2022) 3 урын һ.б.

Тамчы тавышын, музыка тыңларга, хыялланырга ярата.

Фото: автордан алынды, Марк Клионский, В.И. Куделькин иллюстрацияләре

ВИРУС

(Хикәя)

«Сәлам! Без синең белән аралаша алабызмы ул? Син каршы килмәссеңме?»

...Әлеге СМСны сиңа җибәрүемә мең кат үкендем. Шундый каты тиргәдем, гаепләдем үземне. Бу шундый юләрлек! Син җавап бирерсең, аралашырбыз, дуслашырбыз дип уйлаганмандыр инде. Сабый да булганмын... Эх... Әлеге аралашуның мөмкин түгеллеген белә торып, сиңа СМС яздым бит, ә... Ялгыштым! Кем әйтмешли, нинди чебен тешләде икән соң мине ул көнне?! Каян килгән диген шундый кыюлык, үз-үзеңә ышану хисе?! Син миңа ошыйсың, дияр дип көттем микән? Шундый оят! Синең йөзеңә күтәрелеп карарга да кыюлыгым җитмәячәк бит моннан соң... Ялгыштым, шундый хаталандым... Моңа кадәр айлар буе читтән торып яратканны ник кенә башка түзә алмадым икән?! Эх!.. Шушы өч җөмлә!.. Өзелеп-өзелеп җавап көткән һәм дә иң үкендергән өч җөмлә...

Әлбәттә, син җавап бирдең... Дусларча... Тик әлеге СМСны җавапсыз гына калдырсаң, әйбәтрәк булган булыр иде... Без аралаштык. Дөресрәге, син аралаштың: ниләрдер яздың шунда. Ә мин ни дип җавап бирергә дә белмәдем, клавиатура буйлап йөгереп йөргән бармакларым калтырый, сиңа җавап язарга курка иде...

Ике айдан артык инде син дип яшим. Ошыйсың. Ошыйсың гына түгел, яратам бугай мин сине. Берни дә өмет итмичә, җавапсыз яратам. Үземне үзем аңлый алмыйм: сине күрү дә, синнән читләшү дә авыр бирелә миңа. Синең белән аралашырга омтылуны иң зур хатам дип саныйм. Әмма сиңа язмау, онытырга тырышу теләге төшенкелеккә китерә. Синең башкаларга карата булган игътибарлы мөнәсәбәтең, ягымлы карашың, ә кайчагында алар белән шаяруың мине бик нык җәберли. Тик шул ук вакытта, елмаюың һәм шат күңелле булуың мине бәхетле итә, гәрчә бу елмаюлы карашлар башкаларга төбәлгән булса да... Синең үзеңә карата булган кырыслыгың; егылсаң да, сикереп торуың; бик нык авыртса да, күз яше аша «бары да яхшы» диюең; тәвәккәллегең һәм максатчанлыгың сокландыра. Көчсезләрне яклап чыгуың ихтирам уята. Син идеаль түгел, аңа ерак әле, тик шулай да мин барыбер яратам сине. Синең хаталарың да, урынсыз әйтелгән сүзләрең дә мине кыерсытмый. Кайчагында бездән – кызлардан көлүең дә мине читкә тайпылдырмый. Ник шулай соң? Мин аңламыйм, нигә шулай яратам?.. Ничек кенә сәер тоелса да, мин сине генә уйлап яшим. Син үзең дә белмисең әле, әмма ике йөрәк бергә тибә... Ничек шулай килеп чыкты соң бу, белмим. Үз-үземә куйган «беркайчан да гашыйк булмыйм» дигән программада «сбой» булды, ахрысы... Вирус...

...Мин сине яратам, ә син минем кем икәнемне дә белмисең. Хәер, исемне беләсең. Беләсеңдер дип ышанып калам инде... Ә бәлки, исемемне дә белмисеңдер әле, Азалия исемле кызның мин икәнен дә аңламыйсыңдыр, «ВКонтакте»дагы ниндидер бер таныш дип кенә саныйсыңдыр...

...Беркөнне мин мәктәп автобусына соңга калдым. Төннәр буе телефонда утыру үзенекен итә, иртән тору бик авыр. Ә син миннән дә соңрак ятасың. Кайчан карама, син һәрвакыт онлайн. Кем белән язышасың икән? Әллә инде, минем кебек, кемдер язар диеп көтүеңме? Юк, син көтмисең, сиңа болай да язалардыр, язучылар бик күптер... Сиңа да иртәләрен тору авыр биреләме? Йоклап калмас өчен, ничә тапкыр будильнигың шалтырый икән?.. Мин генә түгел, син дә соң килдең ул көнне. Тәңгәллектер инде бу, туры килү генәдер. Синең, мине көткән төсле, мәктәп ишегалында басып торуыңны күргәч, бөтен гәүдәмне калтырау биләп алды. Әмма: «Сине түгел, Русланны көтә ул, тиле!» – дип тиргәп, үземне урыныма утырттым да, тиз-тиз атлап, сиңа игътибар бирми генә, яныңнан үтеп киттем. Арттан: «Сәлам!» – дигән тавыш кына ишетелеп калды. Монысына инде борылып та карамадым. «Руслан белән сөйләшәдер, ярар», – дидем...

Сөйләсәң кеше ышанмас: ике айдан бирле автобус ишеген ябарга өйрәнә алмыйм. Илнар абыйның: «Катырак яп инде аны! Син яба алмаган саен, мин төшеп ябарга тиешме?» – дигән сүзләреннән арыдым, һаман-һаман башкаларның көлемсерәп куюларын күрү дә уңайсыз. Балаларның бөтенесе дә диярлек беренче рейска чыга, икенчегә кеше аз кала. Шуңа күрә мин дә

иртәрәк чыга башладым. Иртәрәк чыкканда, ишекне ябучы табыла. Тик тора-бара, шәхси сәбәпләр аркасында, беренче рейска өлгерми башладым. Ике-өч көн азапланганмындыр. Ә беркөнне, аны син яптың. Син гадәттә артта утыра идең. Сәер, тик син бу юлы алда идең. «Әйдә, кер, Азалия. Үзем ябам», – дидең син. Шулчак безнең күз карашларыбыз очрашты. Мин тиз генә, берни дә булмагандай, аска карадым да: «Рәхмәт», – диеп, урыныма барып утырдым. Ә битләр шундый кызыша, салкын куллар белән аларны суыту да нәтиҗәсез, эчтәге ялкынны ул гына сүндерә алмый иде. Мин төгәл беләм: син аны Илнар абый орышмасын диеп кенә яптың, әмма мин барыбер куандым! Чөнки син ике айга беренче тапкыр миңа исем белән эндәштең!

Бу хәлдән соң безнең күз карашларыбыз бүтән очрашмады. Син дә миңа исем белән башка эндәшмәдең. Мин дә сине еракта гына күзәттем, ә син минем һәрчак янында булуымны сизмәдең дә кебек…

Сез һәр тәнәфес саен безнең кабинет каршысында теннис уйныйсыз. Теннис өстәлләре башка җирдә дә бар бит, ә син безнекенә киләсең. Беләсеңме, мин сине яратуым өчен үз-үземне тиргим, онытырга тырышам. Әмма класстан чыккан саен, сине күрәм. Кайчагында: «Туйдырмадымы әле?! Булды инде, китегез. Башка җирдә уйнагыз!» – дияселәр килә… Мин яратам сине, тик шул ук вакытта күрә алмыйм…

Сез уйнаганда, төз атлап, сиңа карамый гына яныгыздан узып китәргә өйрәнәм. Әкренләп синнән арынырга тырышам. Килеп чыкты дигәндә генә, син тагын барын да бозасың. Хәтерлисеңме, мин узып китә башлагач кына, син: «Азалия, теннис шаригын алып бир әле», – дидең. Булмады инде, тагын синең алда җиңелдем!

Мин сине дә, үземне аңламыйм. Бу ярату, синең арттан күзәтү кирәкме миңа? Нигә «китәм», «онытам» дигәндә генә, син мине тагын тотып каласың? Нигә минем игътибарымны җәлеп итәргә тырышасың? «ВК»да онлайн булганда, миңа язган буласың. Синең СМСны бетерүеңә карап кына, уведомлениеләр килми дигән сүз түгел бит әле. Нигә минем белән шулай шаярасың?.. Минем белән сөйләшкән буласың, ашханәгә барганда, баскычлардан алданрак төшеп, миңа ишек ачасың? Мин сине онытырга тырышканда гына, миңа игътибар күрсәтәсең? Нәрсә бу? Уйларга да куркам: миндә галлюцинацияме, мин юләрләнәмме… Әллә инде?..

«Мәхәббәт вирусы»н йоктыруыма өч ай булды. Урамда инде ноябрь. Кар ява. Быел ул нигәдер иртә ятты. Шимбә көн иде. Гадәттә, ул көнне һәр класста 4 дәрес, ә автобусны көтү ай-һай озак. Без ул көнне кар атыш уйнадык. Син дә, мин дә, башкалар да. Мин бәхетле идем: сабый бала төсле күбәләк-күбәләк кар яуганга шатланам, юешләнеп беткәнче карда ауныйм. Сәер, тик шулай да рәхәт. Автобусның озак килми торуы сизелмәде дә… Ишекне ябарга туры килмәсен өчен, мин тиз генә урыныма кереп утырдым. Автобус кузгала башлады. Шулчак, «Айнур юк бит» дип, автобусны туктаттылар. Ишектән бик «важный» кыяфәт белән син (кирәкле кишер яфрагы!) килеп кердең. Әмма һәрвакыттагыча артка түгел, минем янга килеп утырдың…

Менә инде син 3 көн рәттән автобуста минем белән янәшә утырып йөрисең. Мин моңа куанырга да, кәефсезләнергә дә белмим. Бергә утырып йөрибез, әмма икебез дә – колакчыннардан… Сиңа да, миңа да бу аралашу кирәкми бугай инде…

…Бүген мин бик арыдым: контроль эшләр, авыр дәресләр. Автобуска көч-хәл белән кереп утырдым да, гадәттәгечә, башымны тәрәзәгә терәдем. Янда – син. Күңелдә ниндидер тынычлыкмы, битарафлыкмы шунда, белмим. Үзем дә сизмичә йоклап киткәнмен. Ә уянганда исә, минем башым синең иңбашында иде. Ә синеке, әллә ялгышып (?), әллә инде яратып (!), минекенә терәлгән…

БУЛМАС ИНДЕ...

(Хикәя)

– Абый, тор инде әйдә! Әйдә, кайтырга кирәк сиңа. Суык бит тышта, буран чыгарга тора. Болай ятарга ярамый, өшүең ихтимал. Кулларың да сап-салкын булган, битләрең кызарган, иреннәрең күгәргән – туңып беткәнсеңдер. Тор, әйдә, тор...

Авылның икенче башында торучы бу абыйны яхшы беләм мин. Хәер... Ике көннең берендә урам уртасында егылып яткан, яныңа килеп булмаслык аңкып йөргән, аракы ала-ала бурычка батып беткән Фәрит абыйны авылдагы бөтен кеше белә. Һәр иртәдә, кайчан карама, кибет юлында ул. Бүген дә кайтыр юлында егылып ятуыдыр...

– Фәрит абый, тор инде...

Ярты гәүдәсе белән карга чумып беткән, үзен үзе аңларлык хәлдә булмаган олы гәүдәле ирне күтәрү бер дә җиңел түгел икән. Култык астыннан элэктерергә тырышам, тик җирнең тарту көченә бөтен барлыгы белән буйсынган исерек мине дә үзе белән җиргә таба өстери. Йөрәкне ачу били башлый...

Үз тормышын үзе җимергән кеше бит ул! Менә дигән гаиләсе, елкылдап торган өр-яңа машинасы, яраткан эше – гомумән, бөтен кеше сокланырлык бәхете бар иде аның. Һәрбер кызны үзенә каратырлык киң җилкәле, төз гәүдәле чибәр егет булган бит ул элек. Армиядә хезмәт итеп кайткан... Югары белемле... Акыллы... Шундый олы киләчәк көткән бит аны! Ничек, бер чиертү белән, бөтен тормышының астын өскә китереп була ул?!

Өстерәп торгызып булмавын аңлагач, аркасыннан этеп торгызырга булдым. Шайтан алгыры... Итек балтырларына кар тулды. Кай арада тула да, кай арада аякны өшетергә өлгерә диген син аны. Ә Фәрит абыйның хәтта муенына да кар тулган. Суыктан күшеккән, ахрысы: кар эреми, шул килеш тора. Көч-хәл белән утыртып куелган Фәрит абый неваляшка сыман чайкала, әйтерсең лә кайсы якка аварга икәнен сайлый. Юк инде, сине утырту өчен күпме тырыштым, егылмыйсың! Җитәр!

Җитәрлек егылган, абынган инде ул бу тормышта. Башта, исерек килеш рульгә утырып, машинаны чәлпәрәмә китерерлек авария ясавы, «права»сын алдыруы... Шул хәсрәтеннән бөтен акчасын аракыга әрәм итүе, гаиләдә тынычлыкның бетүе... Аннары хатыны Сәрия апага кул күтәрүләре... Балаларны, әниләре белән бергә, өйдән куып чыгарулары... Нәтиҗәдә – аерылышу...

Сәрия апаны да гаепләп булмый, озак түзгән ул шушы бәндәгә. Кечкенә булсам да, Сәрия апаның, ире куып чыгаргач, безгә килеп утыруларын, әнинең: «Түз, җаным, җайланыр», - дигән сүзләрен яхшы хәтерлим.

Берәү булса эчүеннән туктар, балалары өчен, аларның киләчәге өчен яшәр иде, ул кадәр үк аракыга береккән булмас иде. Кайчагында аңа: «Фәрит абый, син бит үзгәрә аласың. «Башка эчмим!» – дип, аракыны түгү шулай авырмыни?! Үз балаларыңның нәфрәтле карашларын тою җиңелрәкме әллә сиңа?! Ишелеп беткән йортта яшәү сине канәгатьләндерәме?! Ә, гомумән, яшәүме соң бу?» – дип кычкырасым килә...

Әллә исерек йокысы бик көчле, әллә ярымаңсыз хәлдә – белмим. Бу кадәр селкетүгә икенче берәү уяныр иде. Ә Фәрит абый: «Кит, тимә», – дип, авыз эченнән мыгырданудан узмады. Ачуым җилкәләргә авыр таш булып утырды да куллар буйлап бармакларга таба йөгерде. Ә бармаклар үзләре дә сизмичә йодрыкка төйнәлде.

– Ир кеше түгел син, Фәрит абый, чүпрәк кисәге!

...Әмма мин аны башкалар кебек ташлап китә алмыйм. Фәрит абый миңа этием кебек якын...

Балачакта бергә үскән, бер парта артында утырган ике шук малай... Бергә мәктәпне тәмамлаган, бергә армиягә киткән ике дус... Бер-берсенә һәрвакыт терәк, һәрчак ышаныч булган бит алар. Әтием Фәрит абыйны аракы сазлыгыннан тартып чыгарырга тырышучы, авыр вакытларында төпле киңәшләрен бирүче, кайчагында хәтта кесәсендәге акчаны актык тиененә кадәр Фәрит абыйның проблемаларын хәл итү өчен тотып бетерүче кеше иде. Шуңа да, әтием исән чакта, Фәрит абый гел бездә иде. Эчеп килгән булса да, әти белән сөйләшеп утыра, тынычланып өенә кайтып китә, урам буйлап соранып йөрми иде ул. Хәтерлим әле: әтием Фәрит абыйны эшкә дә урнаштырган иде. Шул вакытта ул ике ай буе эчмәде. Аракысыз да тормыш барлыгын үз күзләре белән күреп, моннан соң башка эчмәячәгенә инанып, яңача яши башлаган иде...

Ике ел элек яман шеш авыруыннан әтием үлеп китте. Анда бу авыруның барлыгы өйдәге бер кешегә дә сер түгел иде. Әтием

үзе дәваланырга теләмәде. Сәбәбе – авыру дүртенче стадиягә җитеп исән калу мөмкинлеге меңгә бер булудадыр, бәлки. «Беркемнең дә гомере мәңгелек түгел, күпме бирелгән, шул хәтле яшибез инде», – дия иде ул. Әтием үлгәч, Фәрит абый яңадан эчүгә сабышты... Шуңа да мин Фәрит абыйны калдырып китә алмыйм.

...Тырыша торгач, аягына бастырдым «кар чүмәләсен». Хәзер ярым этеп, ярым өстерәп алып кайтып җиткерәсе генә кала... Авылның икенче башына кадәр барып, Фәрит абыйны өенә озатам. Нигәдер шулай дөресрәк, әтием шулай тели кебек тоела...

Кайта-кайта, йодрыкка җыелган ачу да язылды, әмма аның урынына бөтен күңелемне әрнү биләп алды. Фәрит абыйның хәлен берничек тә үзгәртә алмавымнан тамакка төер тыгылды.

Мин Фәрит абыйны әрли дә, тирги дә алмыйм шул. Моны әти дә булдыра алмый иде... Белмим, мин нигәдер һаман да аны үзгәрер дип көтәм. Сәер инде, Фәрит абыйны һаман да гаиләсе белән кавыштырырга омтылам. Сәрия апа да, мине күргән саен: «Һаман да эчәме? Нихәл ул?» – дип сорый. Кечкенә Айдар белән Ләйлә дә этиләрен юксына...

– Фәрит абый, нигә эчәсең? Әйдә, яңа тормыш башла әле... Син бит начар кеше түгел. Әти дә куанып ятар иде. Сиңа бит әле 41 яшь кенә, ә синең кыяфәтең хәзердән үк бабайларныкы кебек. Фәрит абый, әле соң түгел! Мин яныңда булырмын, әни дә булышыр. Яңа эшең дә булыр, йортны төзекләндерербез. Син теләсәң, бары да булыр...

Шактый шулай сөйләнеп кайттым. Бераздан Фәрит абый, мине бүлдереп, әллә аңлап, әллә инде башка әйтер сүзе юклыктанмы, күп эчүдән эчкә киткән ишетелер-ишетелмәс тавыш белән: «Булмас инде», – дип куйды...

...Икенче көнне, бөтен дөньяны акка күмеп, күбәләк-күбәләк кар яуды. Җир өстендәге бөтен каралыкны агартып, Табигать кешеләрне аклыкка, сафлыкка чакыра, тормышларны өр-яңадан, чиста биттән башларга өнди кебек иде. Ап-ак кар өстендә ярылып яткан яңа сукмакларга карап бара торгач, мин Фәрит абыйны күрми калганмын: әллә ул кибеткә бармаган, әллә инде минем генә игътибарым җитеп бетмәгән, белмим. Җаным түзмәде: укудан соң өйгә кайтмыйча, Фәрит абый торган якка, авылның аргы башына йөгердем. Капка төбендә бер аяк эзе дә юк иде. Мин тиз генә, өйгә керергә омтылып, тупсасыннан каерылып төшкән чолан ишеген тартып җибәрдем. Ә анда... бусагада... ул... Ул җансыз иде...

– Син бит миңа да, этигә дә: «Эчеп үлмим мин», – дип сүз биргән идең... Нишләдең син, Фәрит абый?!! Нишләдең?!!

***

...Мин һаман да Фәрит абыйның юклыгына иялəшә алмыйм, мәктәптән кайтканда, ул торган урамны әйләнәм. Тик аның капка төбендә хәзер эт эзләреннән кала башка бер эз дә күренми: иске сукмак кар астында калган, ә яңасы салынмаган... Йорты да менә ишеләммен ишеләм дип тора. Аңа керү мөмкин түгел инде хәзер. Авариядән соң ярaксыз хәлгә килгән машина да тимер-томырга тапшырылмыйча калды. Табигать тә бу металл өемен кар белән күмеп агарта алмаган. Ә бит миңа Фәрит абый: «Мин айныгач тапшырырбыз аны, Камил. Чакырырмын әле сине, яме», – дигән иде... Булмас инде...

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

Реклама 16+

Татарстан авыллары

ТОРНАЛАР ТӨШКӘН ҖИРДӘ

ТОРНАЯЗ

Фото: Лилиана Вәлитова

Язгы сәфәрләрне яратам: табигать уянганын шунда күрәсең. Юл читендәге карлар эреп челтәр хасил иткән була, ара-тирә кара җирләр дә күренеп ала... Ләкин быелгы март үзгәрәк – кар күп булу сәбәпле, әле кыш дилбегәсен бирергә җыенмый.

Биектау районының Торнаяз авылына барган көнне дә урамда егерме өч градус суык күрсәтә иде. Әмма күк йөзе чалт аяз – март кояшы барыбер җылы, рәхәт. Әнә шулай яз сулышын тоярга дип Торнаязга килеп кердек.

Руфия Фазылова

«ХӘЛӘЛ ҖЕФЕТЕМНЕҢ ИСЕМЕ ОНЫТЫЛМАСЫН, ДИДЕМ...»

Торнаяз Дөбъязга орынып тора, ике генә чакрым. Кайчандыр башлангыч мәктәбе, мәчете, кибете, клубы булган Торнаязда бүген бер генә социаль объект та калмаган. Юк, аны бөтенләй юкка чыгу янаган авыллар исәбенә дә кертеп булмый: 27 хуҗалык бар, 82 кеше яши. Әле дистә ел элек кеше яши торган йортлар саны уннан артык кына булган. Күргәнебезчә, бүген йортлар саны бермә-бер арткан. Узган ел гына өч йорт салынган. Тора-бара бәлки әле мәчете, клубы да булыр. Юлы, газы, суы кергән, тормыш итәр өчен барысы да бар.

Социаль объект юк, дидем дә уйга калдым: музей бар бит. Дөрес, әле рәсми статус алмаган. Ләкин ул кайбер чын музейларны да уздыра. Эш шунда ки, 2011 елда Торнаязга бик зыялы

1

Узган ел ул үзләре яшәгән йортта музей ачкан. Анда рәссам Хәйдәр Сәйбатталовның шәхси әйберләре һәм дистәләгән картинасы урын алган.

2

Рәхмәт йөзеннән, Ифира Сәйбатталова рәссам җәмәгатенең исемен мәңгеләштерергә ниятләгән.

гаилә – Сәйбатталовлар күченеп кайта. Гаилә башлыгы Хәйдәр Гозәер улы – Бөек Ватан сугышы ветераны, рәссам, ә аның җәмәгате Ифира ханым – берничә тел белгән укытучы. Төрле чит илләрдә булган, зур дәүләт җитәкчеләре белән аралашкан бу гаиләне Торнаяз кешеләре беренче күрүдә ярата. Ир белән хатын үзләре дә, йорт эзләп Татарстанның төрле районнары буенча йөреп чыкканнан соң, нәкъ менә шушы авылда төпләнергә уйлый бит.

– Мәрхүм җәмәгатем авылның табигатен һәм шушы агач йортны бер күрүдә яратты, – диде Ифира Сәйбатталова. – Сатулашып та тормыйча, 2011 елда әлеге йортны алдык. Бер елдан соң аңа агачтан янкорма салдык. Хәйдәр гомер буе күп эшләде, монда кайткач та туктамады. Ул ясаган портретлар Санкт-Петербург, Мәскәүнең зур музейларында саклана.

Ирле-хатынлы Сәйбатталовлар тумышлары белән икесе дә Татарстаннан түгел. Шулай да татарчалары бер дигән, шуңа да картлык көннәрен нәкъ менә татарлар арасында үткәрергә теләгәннәр. Җан тартмаса, кан тарта бит...

– Хәйдәр Казахстанның Кустанай шәһәрендә туган, мин исә – Үзбәкстанда, – дип дәвам итте Ифира апа. – Дөрес, анда озак яшәмәгәнбез. Әтине сугышка алгач, әни безне кире туган ягына – Башкортстанга алып кайткан. Әнинең апасы үз гаиләсенә сыендырган. Аннан алар безгә бер бәләкәй генә мунча сатып алып бирде, сугыш беткәнче шунда яшәдек. Әни бик күп хәсрәтләр кичергән кеше иде – әти-әнисен кулак дип атып үтергәннәр, үзе дә кулак баласы буларак нужа шулпасын күп эчкән. Әни бик еш авырды, шулай да безгә белем бирергә тырышты.

Ифира апа 1976 елга кадәр Уфада яши, татарча укып, урта мәктәпне тәмамлый. Белем ала, кияүгә чыга. Бер-бер артлы улы белән кызы туа. Тик беренче ире белән гаилә тормышы барып чыкмый. Утыз алты яшендә янә бәхетен сынап карарга була – Хәйдәр Сәйбатталов белән гаилә коралар. Хәйдәр абыйның да икенче никахы була.

– Без өйләнешкәндә Хәйдәргә илле дүрт яшь иде, – дип дәвам итте Ифира апа. – Кырык өч ел яшәдек. Кайсы илдә генә булмадык, кем белән генә аралашмадык. Хәйдәр күкләр тарафыннан бүләк булгандыр. Ике баламны да үзенеке итеп кабул итте. 2018 елда 95 яшендә вафат булды. Үләренә бер атна калганда да әле рәсем ясады. Бер-беребезне аңлап, бик бәхетле яшәдек.

Әнә шул рәхәттә узган елларга рәхмәт йөзеннән, Ифира апа рәссам җәмәгатенең исемен мәңгеләштерергә ниятләгән. Узган ел ул үзләре яшәгән йортта музей ачкан. Анда рәссам Хәйдәр Сәйбатталовның шәхси әйберләре һәм дистәләгән картинасы урын алган.

– 1993 елда Финляндиянең Миккели шәһәре мэры Хәйдәрне эшкә чакырды, – диде Ифира апа. – Унөч ел Финляндиядә яшәдек. Мин тиз арада фин телен өйрәндем, Хәйдәрне төрле очрашуларга озатып йөрдем. Миккели шәһәре мэры вафат булгач, янә Россиягә кайтырга карар кылдык. Әлеге дә баягы, татарлар арасында яшисе килде. Бүген максатым да – үзебезнең

татар балаларын белемлерәк итү, рәсем сәнгатен күреп өйрәнсеннәр, дим. Хәйдәр нигездә портретлар ясый иде, мин аларның берникадәрен туплап, китаплар да чыгардым. Андый исем югалырга тиеш түгел.

Ифира апа үзе дә рәсем ясый, авыл балалары еш кына аның янына килә икән. Ул малай-кызларга рәсем сәнгате серләрен өйрәтә. Хәер, Ифира ханымнан бик күп нәрсәгә өйрәнергә була: зыялылык, белем, хәтта гәүдәне төз тотарга да...

«ӨЧ БУЫН ЯШИБЕЗ»

Ифира Сәйбатталовага кереп рәсем дәресе алучы балалар күршедә генә яши. Бертуган Миләүшә, Раил, Айрат Сәмигуллиннар талантлы булып үсә. Дүртенче сыйныфта укучы Раил оста итеп гармунда да уйный, җырлый, аһәңле итеп азан да әйтә. Балалар музей ачылышында да чыгыш ясаган. Кызганыч, Сәмигуллиннар белән танышып булмады, Миләүшә белән Раил мәктәптә, Айрат бакчада иде. Ә менә балаларның дәү әниләре Фирадия апа белән таныштык. Ул улы Рамил, килене Гөлназ, оныклары белән бер йортта гомер итә.

– Их, балалар кайтып җитмәде, җырлап та, сөйләп тә күрсәтерләр иде, – дип өзгәләнде Фирадия апа. – Алайса шәһәр балаларын гына талантлы дип күрсәтәләр. Мөмкинлекләр булса, авылныкылар да сәләтләрен үстерер иде. Әнә, оныгым Раил сентябрьдә генә Дөбъяз музыка мәктәбенә йөри башлады. Берничә ай эчендә нинди көйләр уйнарга өйрәнде!

Фирадия апа Торнаяз авылында туып-үскән. Әле аның балачагында авылда җитмеш йорт саналган. Башлангыч мәктәп тә булган, аны 1964 елда тәмамлаган һәм бишенчегә Дөбъяз урта мәктәбенә киткән.

– Җиде елдан, ягъни 1971 елда башлангыч мәктәпне клуб итеп үзгәрттеләр, тик 2001 елда ул да сүтелде, – диде Фирадия апа. – Мин әле анда клуб мөдире булып та эшләдем. Кечкенә авыл булсак та, барлык бәйрәмнәрне билгеләп уза идек, бик күңелле яшәдек. Аннары мине Дөбъяз авылы мәдәният йортына җитәкче итеп алдылар, ә Торнаязда җәмәгатем Мансур эшләп калды. Тик берничә елдан клубны яптылар. «Йөз кешесе булмаган авылларга клуб каралмаган», – дип аңлаттылар.

«ТУГАН АВЫЛ ЯКЫН БУЛА»

Торнаязның иң өлкән кешесе белән дә таныштык – Камил абый Бикмуллин. Илле елга якын Казан заводларында токарь булып эшләгән тырыш кеше ул. Апрель аенда туксан яшен тутыра. Өч тапкыр гаилә корган, тик ни аяныч, өч хатыны да мәрхүм булган. Бүген ике катлы йортта ялгызы яши. Дөрес, атна саен Казаннан улы кайтып йөри, кызы да әзне суытмый.

3
– Клуб мөдире булып та эшләдем. Кечкенә авыл булсак та, барлык бәйрәмнәрне билгеләп уза идек, – ди Фирадия Сәмигуллина.

4
Торнаязның иң өлкән кешесе – Камил Бикмуллин.

5
– Бу йортны улым төзетте, – ди Камил абый.

Камил абый унбиш яшендә Казанга чыгып киткән. Ләкин туган авылы белән араны беркайчан ерагайтмаган. Шуның өчен дә Торнаяз турында шактый кызыклы мәгълүматлар белән уртаклашты:

– Әнием Торнаязга 1933 елда килен булып төшкән, ул чакта авылда 106 йорт булган. Әни шулай сөйли иде. Гаҗәп: авыл урамы-урамы белән юкка чыкты. Мин белгән йортларның берсе дә калмады дисәм була. Кайсының нигезләре генә торып калды. Әйе, алар урынына яңа йортлар да салынды. Менә бу йортны да улым төзетте. Бик рәхмәтле аңа. Беренче катта – аш бүлмәсе, ә йокларга икенче катка менәм. Баскычтан көненә әллә ничә менеп төшәм, Аллаһка шөкер, дип йөрим әле.

Камил Бикмуллин башлангыч мәктәптә Торнаязда укыган. Аннан исә яшьтәшләре белән Дөбъяз мәктәбенә киткән. Әтиләре сугышта булганга, ун яшеннән колхоз эшенә чыккан.

– Торнаязда колхоз 1931 елны оешкан, аның исеме «Яңа юл» иде, – дип хатирәләре белән уртаклашты Камил абый. – Әле без үскәндә авылда ике тегермән иде. Иген тарттырырга күрше авыллардан да килделәр. Авылда умартачылар күп иде. Колхоз үзе дә умарталар тотты. Кош-корт үрчетте, яшелчә үстерде. Кыскасы, эшсез тотмады.

1960 нчы еллар азагында, күрше берничә колхозны берләштереп, совхоз оеша. Шул чорда халыкның тормышы күзгә күренеп үзгәрә: эшләгән өчен әйбәт кенә хезмәт хакы ала башлыйлар. Хәтта инкубаторда чеби-бәбкәләр дә чыгаралар.

Тик үзгәртеп кору җилләре Торнаязга да кагыла – 2000 нче еллар башында совхоз таркала. Нәкъ шул чорда авылдан шактый яшьләр китә.

6
– Трактор белән ризыкны сыерларның алларына бушатабыз да, робот тарата, – ди Ленар Латыйпов.

7
Бүген Латыйповларны районда гына түгел, бөтен Татарстанда беләләр.

8
Сыерны да робот сава, көненә ике түгел, өч-дүрт тапкыр.

«УРТАК ТЕЛ ТАПТЫК»

Берәүләр китсә, берәүләр Торнаязга күченеп килгән. Латыйповлар башта Дөбъязда яши, сигез ел элек исә Торнаязга күченәләр. Ике йөз баш сыерга исәпләнгән ферма салалар. Бүген аларны районда гына түгел, бөтен Татарстанда беләләр. Дистә ел элек республиканың иң күп мал асраучы гаилә фермасы булып танылсалар, соңрак исә роботлар белән эшләүче иң беренче КФХ булып шаккатыралар.

Роботлар ярдәмендә сыер сауганны күргән кешеләр чынлап та гаҗәпләнә икән. Монда робот барысын да эшли: сыерның күпме ашаганын, күпме сөт биргәнен күрсәтә, кайчан бозаулыйсын, авырулары турында да әйтә. Һәр сөтлебикәнең муенында махсус чип бар, менә шул бар мәгълүматны җиткереп тора. Сыерны да робот сава, көненә ике түгел, өч-дүрт тапкыр. Саву аппараты шулай көйләнгән: сыер килеп баса, робот башта сөтлебикәнең җиленен юа, аннары сава. Экранда бу малкайның күпме сөт биргәне күрсәтелеп тора. Эш беткәч, саву аппараты җиленнән үзе алына, һәм сыер чыгып китә. Чират буенча икенчесе килә. Һәм ул тәүлек буе шулай: ягъни сыерлар төнлә дә килеп җиленнәрен бушатып китә. Гаҗәп бит.

– Иң рәхәте – кул хезмәте юк, – диде Ленар Латыйпов. – Трактор белән ризыкны сыерларның алларына бушатабыз да, робот тарата. Тиресне дә җыймыйбыз, шулай ук автомат көйләнгән. Бик җайлы инде.

Ирле-хатынлы Минсинә һәм Ленар Латыйповлар икесе дә Казан дәүләт ветеринария академиясен тәмамлаган. Студент чагында ук өйләнешеп гаилә корганнар. Дүрт балалары бар. Инде кызлары белән улларының

6

үз гаиләләре бар. Кырык биш яшьләрендә дәү әни, дәү әти булганнар.

Без барганда фермада уллары Гомәр белән киленнәре Диләрә дә эшләп йөри иде. Әти-әниләре шикелле үк, алар да Казан дәүләт ветеринария институтында белем ала икән, быел дүртенче курсны тәмамлыйлар. Узган җәйдә гаилә корганнар. Кулга диплом алгач, авылга кайтырга җыеналар.

– Диләрәбез Казан кызы, – дип шаккатырды Минсинә Латыйпова. – Шулай булса да, сыерын да сава, бөтен эшне белә.

– Ә сыер саварга кайчан өйрәндең? – дим Диләрәгә.

– Монда кайткач. Ветеринария институтына кергәндә, мин йорт хайваннары, песиләр, этләр белән эшләрмен, дип уйлаган идем. Гомәр белән очраша башлагач, ул мине үзләренә алып кайтты. Шунда мин сыерларга гашыйк булдым. Авылны бик яратам. Фермада рәхәтләнеп эшләп йөрибез.

Латыйповларның 320 гектар җире бар. Ике йөз баш мөгезле эре терлеккә җитәрлек иген, печәнне үзләре үстерәләр. Бөтен төр техникалары да бар. Сезон вакытында читтән дә кешеләр яллыйлар, ә нигездә аталы-уллы Латыйповлар кыр эшләрен үзләре башкара икән.

Дәүләт биргән ике миллион сум гранттан башлаган бу үҗәт кешеләргә чын мәгънәсендә сокланып кайттык. Нәселле сыерлар алу өчен заманында хәтта Казандагы йортларын да сатканнар. Кайчандыр зур кредитлар белән яшәгән Латыйповларның бүген банкка әҗәтләре юк. Тырышлык, бер-береңне аңлау, кыюлык – фермерлар уңышының серен шунда күрә.

...Кечкенә авылларның нindидер бер серле рухы була. Торнаяз бигрәк тә үзенчәлекле: исеменнән башлап урнашу урынына кадәр. Тау итәгенә утырган төзек сала ул. Атамалары гына ни тора: Бики аланы, Алмагач тавы, Хәсим елгасы, Ачык әби болыны, Олы урта болыны, Корт бакчасы, Шәпи кыяклыгы печәнлеге, Өн елгасы болыны, Түгәрәк болын, Каенлык бае һәм Ачык әби болыннары...



Монда җәй көне кошлар хор булып сайрый икән. Шуның өчен Торнаязга торналар кайткач, янә бер килергә дип уйлаштык. Җиләккә. Казаннан егерме дүрт чакрымда гына болынтаулар куенында утырган авылда күз ачып йомганчы бер чиләк тула икән. Кыскасы, Торнаяз аланында очрашканга кадәр!

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Торнаяз якынча өч йөз ел элек барлыкка килгән дип санала. Авыл искиткеч матур урында урнашкан: таулар, урманнар, дүрт күл. Ул күлләрнең берсенә әле дә торналар килгәли. Авылның исемен менә шуның белән бәйләүчеләр дә бар.

Авыл тарихы белән бәйле икенче легенда бар. Торнаяз авылы урынында элек вак агачлар, куаклар үскән. Шул урынга ике гаилә күченеп килгән, берсе – Алаттан, икенчесе Туктамыштан. Шулай итеп авыл төзи башлаганнар. Аларны күреп, бу җирләргә башкалар да килеп төпләнгән. Урыны матур, суы бар. Авылга исем кушарга кирәк булган. Шуннан берсе: «Тырна, яз», – дигән. Икенчесе шулай дип язып та куйган. Торнаяз исеме менә шулай килеп чыккан дигән риваять бар. Авылда яшәүче бабайлар менә шулай сөйли иде.

Әле дә басуда бер карама агачы үсеп утыра. Ул бик карт инде. Аны авыл оешкан чакта ук булган дип сөйлиләр. Шуның өчен дә кисмәгәннәр.

Торнаязда гел татарлар гына яшәгән.

(Айгөл Хәйруллина, Дөбъяз урта мәктәбенең татар теле укытучысы)

АЛАБАРЫСТА КУНАКТА (6+)

Гаилә елында «Казан Кремле» музей-тыюлыгы тәкъдим иткән программаларның берсе – татар халкы тарихы белән танышырга ярдәм итә торган кызыклы квест. Уен бөтен гаилә әгъзаларының катнашуын күздә тота, шуңа күрә анда балалар да, өлкәннәр дә катнаша ала. Квестта күңелсезләнергә вакыт калмый: уен барышында сез төрки-татар дөньясының мавыктыргыч елъязмасы белән танышачаксыз. Мәсәлән, Алабарыс мәчегә нәсел агачы – шәҗәрәсен төзергә ярдәм итеп, бик күп кызыклы мәгълүмат алачаксыз.

30 март, 16.00 сәг.

Татарстан Республикасы һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музее, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

СӘХНӘ АРТЫ СЕРЛӘРЕ (6+)

Спектакльгә әзерлекне башка тамашачыларга кадәр иртәрәк күрү тормышка ашмаслык хыял түгел. Опера һәм балет театры сезне үз спектакльләренең ачык репетицияләренә чакыра. Гадәттә халык күзеннән яшерелгән бөтен нәрсәне диярлек карау мөмкинлеге бу. Сез гадәти киемнәр киеп репетицияләр үткәрүче артистларны күрерсез, режиссер һәм «сәхнә арты» хезмәткәрләренең эшен күзәтерсез, аларның хезмәте гадәттә ят күзләрдән яшерелә. Ә кунакның театр дөньясына чумуы тулырак булсын өчен, һәр репетиция алдыннан спектакль турында лекция үткәрелә. Проект яшьләргә исәпләнгән, ул шулай дип атала да: «Театр – яшьләргә».

Ачык репетицияләр

26 март, 17:30 сәг. «Искатели жемчуга», ике күренешле опера

8 апрель, 17:30 сәг. «Анюта», ике күренешле балет

М.Җәлил исем. Татар дәүләт академия опера һәм балет театры, Казан, Ирек мәйданы, 2

ТЕАТР УЛ МУЗЫКАЛЬ ДРАМА ДА... (6+)

Камал театры артистлары һәм чакырылган кунаклар тамашачыны менә нәкъ шуңа инандырмакчы. Иң яхшы номерлар, иң моңлы җырлар, күренекле җырчылар, күп сюрпризлар көтә, дип вәгъдә итә оештыручылар.

Концертта Эльмира Кәлимуллина, Эльмир Низамов, Анастасия Макарова, Карина Җиһаншина, Булат Хисмәтов һәм Валерий Коротков чыгыш ясаячак. Баш дирижер һәм сәнгать җитәкчесе – Данияр Соколов. Кичәне ТР халык артисты Фәнис Җиһанша алып бара.

22 март, 18:30 сәг.

С.Сәйдәшев исем. Дәүләт Зур концертлар залы. Казан, Ирек мәйданы.

афиша

Фото: kazan-kremlin.ru, gbkz-rt.ru, tinchurinteatr.ru, puppet-show.ru,

ЯШЬЛӘР ҖЫРЫ... (6+)

Хәзерге яшьләр нәрсә белән яши, нинди кыйммәт һәм принципларны үз итә? Ittifaq төркеме җырлары яңгыраган «Флешка, рэп һәм мәхәббәт» хип-хоперасындагы вакыйгалар Казан районнарының берсендә бара. Монда Афәринов криптовалюта, таткоиннар белән эш итә, аларны флешкада саклый һәм Дубайда бай тормыш турында хыялланa. Моңнулинның да танылган һәм бай буласы килә, шуңа гади генә көй яза, шулай ук аны флешкада саклый. Ә Башбаштаков үзенең беренче мәхәббәтен очрата.

«Флешка, рэп һәм мәхәббәт» хип-хоперасы социаль челтәрләрдә алга сөрелгән «витрина» тормышыннан көлә. Җиңел акча эшләү һәм табыш алу максатыннан гына буш популярлык яулау омтылышы белән янган зумерлар буыны вәкилләре кая барып чыгар? Флешка, рэп яки мәхәббәт – моның кайсы мөһимрәк?

20 март, 18:30 сәг.
30 март, 13.00 сәг., 17:00 сәг. К.Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Казан, Горький ур., 13

ӨЧ ИПТӘШ ИҖАТЫ (6+)

Василий Соловьёв-Седой, Борис Мокроусов, Алексей Фатьянов... Аларның җырлары халык җырларына әверелә. Ә күренекле композиторларны һәм шагыйрьне уртак иҗат кына бәйләми. Фронтовиклар, иҗат кешеләре – аларның дуслыгы күпләргә үрнәк була. Әлеге эчкерсез дуслык аларның үзләреннән дә озаграк яши, җырларында һәм тамашачы йөрәгендә яшәвен дәвам итә. «Өч иптәш» концерты әлеге искиткеч дуслыкка багышланган. Тамашаны яраткан авторларыбызның оныклары алып барачак. Җырларны ТР Дәүләт халык уен кораллары оркестры (сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры – Россиянең халык артисты Анатолий Шутиков) һәм халыкара һәм бөтенроссия конкурслары лауреатлары Юлия Җиһаншина (Казан), Алина Атласова (Санкт-Петербург), Ольга Голицина (Мәскәү), Сергей Петрищев (Мәскәү), Борис Дьяков (Мәскәү) башкарачак.

30 март, 18:00 сәг.
Г.Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе, Казан, Павлюхин ур.,73

ШИГЪРИ СПЕКТАКЛЬ (12+)

21 март – Бөтендөнья шигърият көнендә Кариев театры «театраль дәрес» форматындагы «Анна Ахматова: вакыт кайтавазы» тамашасын тәкъдим итә. Тамашачылар 45 минут дәвамында, Анна Ахматова шигырьләре ритмына кушылып, артистлар белән бергәләп, шагыйрәнең иҗатында чагылыш тапкан катлаулы тормыш юлын кичәчәк. Анна Андреевнаның шигырьләре татар телендә яңгыраячак. Аның шигырьләрен бүгенге көн татар шагыйрьләре Илсөяр Ихсанова, Рәмис Аймәт, Луиза Янсуар, Йолдыз Миңнуллина, Лилия Гыйбадуллина, Фәнил Гыйләҗев тәрҗемә иткән.

– «Театраль дәресләр» мәктәп укучылары өчен әзерләнде. Танылган шәхесләрнең «катып калган» һәйкәлләр яки дәреслектәге портретлар гына түгел, ә тере кешеләр икәнлеген күрсәтәсебез килде, – дип уртаклашты тамашаның сценарий авторы Луиза Янсуар.

21 март, 13:00 сәг.
Кариев исем. Казан яшь тамашачы театры, Казан, Петербург ур., 55 Б

КУРЧАК, ҖАН ӨР! (16+)

«Әкият» курчак театрында куелган спектальнең сюжеты бер дә курчаклар дөньясына карамый кебек. Вагыйгалар үзәгендә – 1921–1922 елларда Идел буенда барган коточкыч ачлык. Халык авылы-авылы белән кырыла, үлем гадәти хәлгә әверелә. «Адәмнәр» әсәрендә «ачлык» төшенчә генә түгел, яман персонаж да. Бер гаилә үрнәгендә Галимҗан Ибраһимов ач кешенең кешелеклелектән чыгуын, адәми зат булудан туктавын, рухи яктан үлүен бик нечкә итеп, адымлап сурәтләп бирә.

«Адәмнәр» курчак театрында үзенчәлекле яңгыраш тапкан. Кешелеклелектән чыккан адәм җансыз курчак кебек. Курчакка «җан өрү» өчен, аның артында һәрвакыт тере кеше торырга тиеш.

22 март, 19:00 сәг.
«Әкият» Татар дәүләт курчак театры, Кече зал
Казан, Петербург ур., 57

ай кәефе: сокланыгыч

МАТУРЛЫК ДӨНЬЯСЫНДА

Бу сыйныфка килеп керүгә, үзеңне күргәзмәләр залында кебек хис итәсең. Пөхтә итеп диварларга эленгән картиналар сыйныф бүлмәсенә нур өсти кебек. Казан шәһәре 144 нче урта мәктәбенең татар теле кабинетларының берсе әнә шулай үзенчәлекле итеп бизәлгән. Биредә эшләүче татар теле укытучылары белән аралашып алдык.

– Татарстан рәссамнарының иҗатына багышланган күргәзмәләр проекты узган елда башланып китте, – дип аңлатты безгә Айсылу Корманова. – Рәссамнар белән алдан сөйләшәбез, алар картиналарын мәктәпкә алып килә. Без сыйныф диварларына матурлап эләбез.

Күргәзмәдәге картиналар никадәр еш алышына дип тә кызыксындык.

– Һәр күргәзмә аерым бер рәссам иҗатына багышланган, картиналар 2–3 ай саен алышынып тора. Әлегә балаларны дүрт рәссам иҗаты белән таныштырдык. Күргәзмәне ачканда, автор белән очрашу оештырабыз. Рәссам үзе турында сөйли, балаларның сорауларына җавап бирә, аралашу бик кызык һәм файдалы үтә, – диде Ирина Макарова.

– Укучылар гына түгел, рәссамнар үзләре дә бу очрашудан канатланып чыга, – дип сүзгә кушылды проект авторларыннан берсе Рәмзия Мөслимова – Балаларның ихлас кызыксынуын күрә бит алар. Ай дәвамында төрле сыйныфлар өчен экскурсияләр үткәрәбез. Коллегаларыбыз да керә. Укучыларыбызда эстетик зәвык тәрбияләргә омтылабыз, үзебезнең республикада яшәп иҗат итүче рәссамнар турында күбрәк белсеннәр, дип тырышабыз. Һәрхәлдә, сәнгатьне, матурлыкны яраткан балалар усал булып үсмәсләр.

Без дә ихлас күңелдән шуңа ышанабыз. Сезгә дә әлеге күргәзмәләрне чагылдырган фотопроект тәкъдим итәбез.

Мөдәррис Минһаҗев

Фото: Лилиана Вәлитова

Равил Заһидуллин


Руслан Ибраһимов

Равил Заһидуллин


Руслан Ибраһимов


Салават Нигъмәтов


Салават Нигъмәтов


Мөдәррис Минһаҗев

АЙГӨЛ УСМАНОВА КЕЙТЕРИНГЫ ЯРДӘМЕНДӘ ИФТАР УЗДЫР!

Мәшәкатьсез генә матур һәм мул өстәл. Хәләл ризык

Аш тактасына зәвыклап тезелгән ризык

Чара узган көндә дә заказлар кабул итәбез

Казан, Б. Урманче ур., 1
8 (843) 203-45-00
8 (937) 154-00-16

kazan.aigul-usmanova.ru
aigul.usmanova_kazan
aigul.usmanova1

*Айгуль Усманова
Реклама. ИП Усманов Линар Марселевич